
PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2016 НОЯБРЬ № 11

# СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

## ӘНИ БУЛУ ҖИҢЕЛМЕ

*ачуланунның да җае бар*

## АМЕРИКА ӘКИЯТЕ

*кунакка сый – карабодай*

## ГӨЛНАЗ СӘФӘРОВА СЫЙЛЫЙ:

*керәнле манты*

Дилүзә ХӘБИЕВА:

## – ХАТЫН-КЫЗГА ӘНИ БУЛУ КИЛЕШӘ!



PRESSA.RU



БЕРГӘ ЧАКТА... Бу мизгелләр күп тә түгелдер, бәлки — атналарны тыгызлаган бетмәс-төкәнмәс эш, мәшәкать ыгы-зыгысында гаилә белән үткәргән бәхетле минутлар һаман сирәгәя, кыскара барадыр. Әмма аларның һәрберсе кадерле, һәркайсы безгә тормышның ямен-тәмен тоеп яшәрлек көч, җан җылысы бирәдер. Бу тансык вакытны һәркем үзенчә үткәрә – алар мәгънәле, күңелле, онытылмас якты булсын өчен әллә ни кирәкми дә кебек...

# #«ХӘЕРЛЕ ИРТӘ!»






## МИҢНЕХАНОВлар гаиләсе

**Күпләр хәтерлидер: Татарстан җитәкчесе Рөстәм Миңнеханов социаль челтәрдәге үз битендә әнисе белән бергә төшкән фотосын урнаштырган иде. Вәсига апага 85 яшь тулган көн! Өч улы да котларга кайткан!.. Казан—Саба арасын Рөстәм Миңнеханов хәзер дә еш үтә. Әнисе белән аралашудан Илбашы үзенә бетмәс егәр, сабырлык, зирәклек, җылылык алып китә. Әлбәттә инде, әни янында балачак истәлекләре дә яңара. Чаңгыларны тактадан үзләре ясап, «Карпат» түбәсеннән — авыл янындагы таудан түбәнгә җилдерүләр. Әти-әнисенең Рөстәмгә «Чайка» фотоаппараты бүләк итүе. 8 нче сыйныфтан соң 15 чакрымдагы Саба урта мәктәбенә йөреп укулар. Урман хуҗалыгы директоры Нургали абыйның УАЗик машинасы булса да, Рөстәм мәктәпкә башкалар белән бергә бөркәүле машинага утырып йөри...**
**Без Президентның инстаграмын карап барырга яратабыз. Рөстәм Нургалиевич «Хәерле иртә!» дип, ватандашларына хәерле көн тели, ил-көн вакыйгаларына мөнәсәбәтен сиздерә, күрешкәнаралашкан кешеләрен күрсәтеп, безне дә теге яисә бу вакыйгага үз фикеребезне белдерергә өйрәтә. Ачыклык, хәбәрдарлык үрнәген дә беренче булып ул күрсәтте! Булачак хатыны Гөлсинә Әхәт кызы белән ул Арчада эшләгәндә таныша. Гөлсинә ханым ел саен ире — Президент Рөстәм Нургали улы белән бергә республиканың иң яхшы гаиләләрен хөрмәтләү тантанасында катнаша.**
















Ә сез БЕРГӘ ЧАКТА ниләр эшлисез, сезнең гаиләнә нинди эш-гамәлләр, үзенчәлекле бәйрәмнәр, берәүдә дә кабатланмый торган, әмма башкаларга да үрнәк булырдай матур йолалар берләштерә? Яңа фотопроектыбыз шундый мизгелләрне яктыртуга багышланган.

*Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!*



© «Сөембикә» 2016

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.




**Директор-баш мөхәррир**
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

**Редколлегия:**
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

**Редакциянең гомуми телефоны** 222-09-77
**Директор урынбасары**
Рәмзия Кашапова 222-09-78
**Баш мөхәррир урынбасары**
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
**Җаваплы сәркатип**
Лариса Маликова

**Сайт мөхәррирләре:**
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

**Дизайн-макет:**
«ASAFIN GROUP»
**Верстка:**
Лариса Маликова

**Тышлыкта:**
Дилүзә Хәбиева
Фото: Алинә Батыргәрәева

**Бүлек мөхәррирләре:**
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
**Фотокорреспондент**
Ксения Богданова
**Корректор**
Фирдәвес Исмәгыйлева
**Гамәли хезмәткәрләр:**
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225x290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 11.11.2016 ел.
Заказ М-2935.
Тираж 5603.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»




ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в ПАО «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU

# 27 НОЯБРЬ — ӘНИЛӘР КӨНЕ



«Тукайга багышлау». Фәридә Хасьянова эше.



## ШАГЫЙРЬНЕҢ 105 ЕЛЛЫГЫНА

Сибгат ХӘКИМ

# *Клиндерләр эзлим*

*Нәрсә салыйм икән әнкәйгә мин –*
*Аны, димен, чиксез сөендергән?*
*Хат ахырында гына әйтеп куя:*
*«Оныта күрмә, улым, клиндерләр...»*

*Картайды нык, тешләре дә төшкән,*
*Колакка да хәзер ул саграк...*
*Нигә инде шунда сорамаска*
*Берәр тәмле нәрсә, йомшаграк?*

*Кешеләрдән миңа бик уңайсыз,*
*Сине баккан ич ул, киендергән.*
*Зурдан кубып, имеш, күчтәнәчкә*
*Клиндерләр җибәр, клиндерләр?!*

*Ерактан ук барыбер күреп торам*
*Клиндерне чәйдә җебеткәнен.*
*Уйлыймы ул арыш, бодай үскән*
*Басуларда озын юл үткәнен?*

*Бу дөньяда бары мин генә шул,*
*Мин генә шул аның көен белгән.*
*Буранмы ул, яңгырмы ул тышта –*
*Клиндерләр эзлим, клиндерләр...*

PRESSA.RU



## БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА







8
БЕЗГӘ УР МЕНӘСЕ!..
Р. Гасыймова

## ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





12
НИК ТУДЫРДЫМ КӨНЕНӘ...
М. Авзалова



20
«МИН ҮЗЕМ КАДӘР ӘЛЕ – КИЗӘНМӘ!»
Л. Гәрәева



«БАЛАМНЫ ХАРАП ИТТЕЛӘР...»
М. Кашапова
16

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫ






26
«ШӘМСИЯ ЧИШМӘСЕ»
Г. Сафиуллина

# ЭЧТӘЛЕК


МӘДӘНИ ТОРМЫШ 


30 АРТИСТКА АЛСУ
А. Юнысова

ЯШӘЕШ 


42 СӨННЕҢ ҮЗЕ КЕБЕК...
Р. Миңнуллин


48 «АМЕРИКА ӘКИЯТЕ»
А. Фәттахова

ШУЛАЙ УК: 

36 МИН ЯРАТАМ СИНЕ...
М. Кәбиров

46 МИН ӘТИГӘ КИРӘКМИМ...
Альбина

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 


60 КӨЯЗКӘЙЛӘР БИШМӘТЕ

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

АТА КЕШЕ – АТА КАЗ.
ФИКЕР

«ТЫҢЛАГЫЗ, ТАЛЛИН СӨЙЛИ».
МИЛЛӘТТӘШ

ПРИНЦЕССАДАН – КӨЛСЫЛУГА.
ЯЗМЫШ

ШЕФ-ПОВАР ИЛЬЯ ФРОЛОВТАН –
ЯҢА ЕЛ ТОРТЫ




PRESSA.RU

# Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



*Ничек көттек бу көнне, Әни! Синең исән-сау, сәламәт булып, балаларың-оныкларың арасында, кадер-хөрмәттә олы юбилееңны – 90 яшеңне үткәрү үзе зур бәхет бит ул!*

Кадерле әниебез Әмирова Асияләнең туган көне – 10 октябрь – без балалары өчен кечкенәдән календарьның кызыл көне булды!

Алтын көздә, бакчадагы эшмәшәкатьләр төгәлләнүгә, туган авылга, әни янына ашкынып кайтабыз! Ямьле Актанышбашыбыз, Агыйделебез, үзебезнең урам, үз өебез, туганнардай якын күргән күршеләр, күр, ничек сөенгәннәр! Әйтерсең, бар дөнья сине туган көнең белән котлый кебек! Авылдашларның: «Асиянекеләр кайткан!», «Әсләм абый белән Асия апа балалары» дигән сүзләре сиңа карата хөрмәт билгесе ул, әни. Мактау да, соклану да, рәхмәтләр дә – барысы да сыйган шул гади генә сүзләргә!

Әни! Син безгә гомер буе сабырлык, тыйнаклык, зирәклек, намуслылык, тырышлык, ярдәмчеллек, юмартлык өлгесе булдың! Хәзер инде үзебез турында да шулай мактап сөйлиләр. Бөтен әйбәт якларыңны безгә күчергәнсең, балачактан сеңдергәнсең, безне чын кеше итеп тәрбияләгәнсең...

Юл буе балачак хатирәләрен искә төшереп кайттык менә. Синең белән бәйле вакыйгалар, кинофильм кадрлары кебек, күз алдыннан үтә. Менә син, озын толымлы, җыйнак гәүдәле Гыйлемҗан кызы, барлык сугыш чоры балалары белән беррәттән, йөгерә-йөгерә кырда эшләп йөрисең. 1945 елда, 19 яшең дә тулыр-тулмас, сине күмер чыгарырга җир читенә – Кемеровага җибәрәләр. Анда әсир немецлар белән бергә эшләүләрегез, эшчеләрнең шул немецларның котелокларын урлаулары, синең дә ул котелокка кызыгуларың... Үзүзеңә каршы килеп булса да, кыяркыймас шул котелокны алуың... Савытын югалткан немецны жәлләп йөрәгең әрнүләр... Намусыңа хилафлык китермичә, котелокны хуҗасына кире илтеп тоттырулары... Туган авылга кайткач, авылның иң чибәр, булдыклы егете Әсләм белән очрашып-кавышуларыгыз... Үрнәк матур гаилә булып, безне, өч баланы кадерләп үстергән рәхәт чаклар! Синең тәмле ашларың, бәлешләрең... Бер генә көн дә колхоз эшеннән калмыйча тырышып хезмәт итүләрең... Барысы да истә, йөрәктә, әни!

Кызганыч, әтиебез Әсләм 63 яшендә үк вафат булды. Кулыннан килмәгән эше юк иде. Ул ясаган тәрәзә йөзлекләре әле дә авылның өйләрен бизәп, матурлап тора.

Килен – кайнана туфрагыннан диюләре дә хак икән! Нурсиябез безнең өчен килен кебек тә түгел, сеңлебез ул. Күр, ничек кадерли үзеңне! Энебез Әдһәмгә, хатыны Нурсиягә, балаларына рәхмәт!

Әни! Бәйрәмең котлы булсын! Безне укытып, олы тормыш юлына чыгарып җибәргәнең өчен сиңа бик рәхмәтлебез! Безне сөендереп, исәнлек-иминлеккә кинәнеп әле тагын озак еллар рәхәт яшә! Авырма! Яхшылыкларың үзеңә меңе белән кайтсын!

*Кызларың Фәйрүзә ЗАРИПОВА,*
*Гөлфирә ӘБҮДӘРОВА.*
*Казан.*

*Быелгы җәй бигрәкләр дә ямьле булды. Өемә эштән гел ашкынып кайтам. Юк, бакчам ямьле булганы, анда мул булып җимешләр, яшелчәләр өлгергәне өчен генә дә түгел.*

Минем өемдә бу җәйдә ак күбәләк яши. Тиз генә китмәсә ярар иде, дип кенә торам. Бу Ак күбәләк дигәнем – Сания түткәм. Түткәм дип әйткәч, күпсанлы иясез апалардан аерымлап куйган кебек була. Ә минем аны чынлап та аерымлап куясым килә. Сания апамны – әниемнең җиде туганы арасыннан уртанчысын бөтен нәсел-нәсәбебез белән яратабыз. Әнинең кыз туганнары болай да бик якын була бит ул. Күрәсең, ике арадагы җылылык, якынлык балаларга, оныкларга да күчә торгандыр. Сания апабыз кечкенәдән әнә шул җан җылысы белән аерылып торган. Шуңа күрәдер, бер туганыбызның баласы чирләп йөдәткәч, авылыбыз Аланны (Биектау районы) ни яратса да, шул баланы карарга дип, Казанга килә ул. Өй саен кереп, эшләмичә өйдә торучылар исемлеген ала башлагач кына, бала караудан туктап, Ак Ком урамындагы тегү фабрикасына эшкә урнаша. Беренче көнне үк нормасын арттырып үти. Шуннан бирле гел алдынгы эшче саналып, пенсиягә чыкканчы киемсалым тегә.

Әй аның ул эшкә уңганлыклары! Казаннан авылга ялга кайтканда да ул бөтенебезнең аягына матур-матур чүәк-оекбашлар бәйләп алып кайта торган иде. Аның шул гадәте гомер буена дәвам итте. Югыйсә бер минем гаиләмдә генә дә унөч пар аяк иде бит. Ә сеңлемнекендә, энемнекендә...

Безнең аяклар икедән дүрт, дүрттән сигез булганчы, ягъни без сеңелләр башлы-күзле, үз тормышлы булганчы барыбыз да Сания апа янына килеп сыена, ул пешергән ашларны бүлеп ашый торган идек. Нәсел-нәсәпкә бөтен киемне ул текте. Тора-бара, җизни белән иркен өй салып чыккач та, аларның капка төбеннән мосафир машиналар өзелмәде. Аның киң күңеллелеген бер хикәят итеп сөйләрлек. Самавырын кайнатып, коймагын сикертеп чәй эчереп чыгаруы гына җитмәгән, һәр кунагына күчтәнәчен алдан ук тутырып, хәстәрләп куя торган иде. Егермешәр кукәйме ул, бер кәрзин алмамы – әзер иде. Сания апага да муллык күктән төшмәгәндер. Югыйсә пенсиягә чыккач та 40 нчы заводта эшләп йөрмәгән булыр иде. Ул үзе елмаер да бер генә җөмлә әйтеп куяр: «Ходайдан сорагыз. Муллыкны бирүче ул». Кырык елдан артык биш вакыт намазын калдырмаган тутам догалары белән әби-бабаларыбызның, картының рухын яктыртып яши. Минем намазга басуымны да бик хуплаган иде ул. «Муллалар, укымышлы кешеләр нәселеннән бит без. Инде без дә намазлы булмасак...» – дигән иде ул. Аның белән янәшә басып намаз укулары үзе бер рәхәт.

Сания апабыз безне шатландыруның яңадан-яңа юлларын таба. Җәй хозурыннан, аның эссе килүеннән юанып, әнә, алмадан как коеп йөри, помидор-кыярларны кышка яба, үләннәр җыеп киптерә. Ул да түгел, сарык йонын юып-киптереп, йомшак түшәк сырып куя. Ә бит аңа хәзер 86 яшь. Арыдым дигән сүзне һич әйтмәс, авыртынам дип зарланмас. Югыйсә моннан 10 еллап элек үк инде, өченче операциясен ясатканда хирург: «Бу әбине ник аптыратып йөртәсез? Көне санаулы бит инде», – дигән иде. Ә ул – ак яулыклы, ак күлмәкле Күбәләгем минем – яши әле. Яши генә күрсен!

*Равилә ШӘЙДУЛЛИНА.*
*Казан.*



*Озак еллардан бирле яратып укыган журналым аша чорыбызның бер фидакаре – Әлфия Лотфулла кызына кайнар сәламнәремне җиткерәсем килә. Ул да бик яратып укый «Сөембикә»не, сәламнәремне, шат, күрми калмас.*

Сентябрь ае – елның иң мул ае. Әллә шуңадырмы, бу айда туган кешеләр көчле рухлы, белемгә омтылышлы була. Оренбург өлкәсенең Абдулин районы, Абдрахман авылында туып-үскән, гомере буе шушы авылда яшәп, 40 елын балаларга белем бирүгә багышлаган, аның 18 елын мәктәп директоры булып эшләгән Сәйфуллина Әлфия дә нәкъ шундый кеше.

Гомер мизгелләрен санасаң, алар бихисап. Һәркайсы үзенчә кадерле, үзенчә күңелгә якын. Балалык елларында ул ата-ана назына коенып үсә. Сугыш һәм хезмәт ветераны Лотфулла абый балаларын җилсалкыннардан аралап, сөю назына урап, кызларын – «кызыкам» дип, бердәнбер улын «улыкам» дип, иркәләп үстерә. Әниләре авылның бер уңганы – балаларын эш белән тәрбияли. Бу гаилә авылда гына түгел, өлкәбездә дә билгеле гаилә. Аларны, югары белемле биш бала үстергән гаилә, дип, Оренбург өлкәсенең Мактау китабына да керттеләр. Сугыш чоры кешеләре, үзләре укый алмагач, балаларын гел белемгә өнди: татар халык әкиятләре, шигырьләр сөйләп, эшләгәндә җырлар җырлап, туган якка, телгә мәхәббәт уяталар. Әлфия инде 5 яшендә хәреф таный, авыл китапханәсенә язылып, мәктәпкә барганчы ук андагы китапларны укып бетерә. Мәктәпне уңышлы тәмамлаган кызны шунда ук эшкә дә калдыралар. Укыткан остазлары – Роза Кадыйрова, Нурия Юмагулова, Зәйтүнә Рәүфкулова кебек чын мөгаллимә буласы килә аның.

Кырык ел эчендә күпме бала тәрбияләгән, күпме дәфтәр тикшергән, күпме кичәләр үткәргән – аларның исәбе дә, саны да юк. Иң мөһиме: илгә ул тәрбияләп биргән кешеләр! Әлфия Лотфулла кызының укучылары арасында абруйлы авыл эшчәннәре, нефтьчеләр, төзүчеләр, мәдәният хезмәткәрләре... кемнәр генә юк. Алар белән горурланып яши Әлфия Сәйфуллина. Аның эшен хәзер кызлары дәвам итә: Алсулары – тарих фәннәре кандидаты, Альбина – техник фәннәр кандидаты, Гөлнурлары – юрист.

Менә шулай, эшен, балаларын, тормышны яратып яши безнең хезмәт ветераны исеменә лаек булган Әлфия апабыз.

Абдрахман мәктәбенең барлык укучылары исеменнән яраткан укытучыбызны юбилее белән чын күңелебездән котлыйбыз. Синең безгә биргән күңел җылың, дөньяга карашың, акыллы киңәшләрең санап бетергесез, бәясез. Син безне яшәргә, кешеләрне, туган телне яратырга өйрәттең.

Кызганычка, мактаулы Абдрахман мәктәбе бер ел элек ябылды, авыл зыялылары да илдәге оптимизациягә каршы торып, мәктәпне ябылудан саклап кала алмады. Шулай да кайчан булса да тагын бер мәктәбебездә яңадан кыңгырау чыңлар дигән өмет белән яшибез.

*Гөлфия ШАКИРОВА.*
*Түбән Варта шәһәре.*

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**
**Сездән хатлар көтеп калабыз.**
**Безнең адрес: Казан,**
**Декабристлар урамы, 2.**
**e-mail: ssuum@yandex.ru**

PRESSA.RU

# БЕЗГӘ ҮР МЕНӘСЕ!..



Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС Идарәсе

Ризидә ГАСЫЙМОВА

БЫЕЛ РОССИЯДӘ ТӘҮГЕ ТАПКЫР «ЕЛ ГАИЛӘСЕ» БӘЙГЕСЕ ИГЪЛАН ИТЕЛДЕ. 77 РЕГИОННЫҢ 286 ГАИЛӘСЕ АРАСЫНДА ЧАЛЛЫДА ЯШӘҮЧЕ ДИЛҮЗӘ ҺӘМ РУСЛАН ХӘБИЕВЛӘР ГАИЛӘСЕ ДӘ БАР.

Дилүзә... Аны беренче мәртәбә күрүем хәтердә. Болын кадәр өй (килеп керүгә, нишләптер, шәһәр фатиры икәне онытылды), бертуктамый чыр-чу килгән бала-чага һәм озын ефәк күлмәк кигән сылу гәүдәле, нечкә билле Дилүзә. Ниндидер фильм төшерергә җыенганнар да, безне бу өч баланы Дилүзәнеке дип ышандырырга тырышалар, диярсең. Ә безнең ышанасы килми!

Әнисе Зиләрә апа Дилүзәнең нинди эш-мәшәкатьләр белән йөргәнен сөйли башласа, шаккатып тыңлыйм. Дилүзә авыру балаларга ярдәм итү өчен хәйрия концерты оештырганмы? Дилүзә Казанда «Нечкәбил» бәйгесендә катнашырга җыенамы? Дилүзәләр, «Чулман кызлары» триосы белән Чаллы татар драма театры бинасында концерт куячакларммы? Дилүзә бер авыру баланы Мәскәүгә операциягә алып киткәнме? Дилүзәләр Пермьгә «Идел буе» округының «Уңышлы гаилә» бәйгесендә катнашырга барачакмы? Алла ярдәм бирсен инде үзегезгә, Зиләрә апа! Чөнки беләм, бу бәйге-чаралардан әни кеше – Зиләрә Имаметдинова да, Дилүзәнең кыз туганы – Зилия дә (Dance-show «Axel» бию төркеме җитәкчесе) читтә калмаячак, Дилүзәнең ире Руслан, сәхнә кешесе булмаса да, хатынының бетмәс-төкәнмәс идеяләренә барыбер ияләчәк. Балалар турында әйтеп тә торасы юк. Бертуган энеләре, Казанның Яшь тамашачы рус театрының баш режиссеры Туфан Имаметдиновның да, хатыны Лилияне ияртеп, теләктәшлек йөзеннән килеп җитүе мөмкин әле. Дилүзә белән Руслан «Россиянең иң яхшы гаиләсе» бәйгесендә «Гаилә – традицияләр сакчысы» номинациясендә катнашалар икән, монда шушы берничә буынны бәйләп торган бердәмлек тә, туганнар арасындагы искитмәле мөнәсәбәт тә, һәм, әлбәттә, безнең гомуми милли традицияләр дә чагылыш тапкандыр.

Барысы да «Нечкәбил»дән башланган. Узган 2015 елда Дилүзә республикакүләм «Нечкәбил» бәйгесендә катнашырга ниятләгән. Гомумән, бәйгеләр турында сүз алып барганда, еш кына: «Иң мөһиме – катнашу» дигәннәрен ишетергә туры килә – тик Дилүзә болай дип гомердә дә әйтмәячәк. «Бәйгедә катнашасыңмы – җиңәргә кирәк!» – диячәк ул. Җиңү өчен, әлбәттә, җиңәрлек итеп әзерләнергә кирәк. Менә шунда башлана инде, кем әйтмешли, йокысыз төннәр. Дилүзә үзе – Чаллының «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты солисты, «Чулман кызлары» өчлеге җырчысы, нәфис сүз остасы, кыскасы, һөнәрләре җитәрлек. Әмма «Нечкәбил» җыр яки нәфис сүз бәйгесе генә түгел шул. Монда син гаиләңне дә җәлеп итәргә, уңганбулган заманча хатын-кыз (!) булуыңны дәлилләргә тиеш. Әйткәнемчә, мәдәнияттән ерак торган Русланны сәхнәгә чыгарга үгетләү өчен генә дә, сәхнәгә чыгарлык итеп әзерләү өчен генә дә күпме көч һәм... дөресен әйткәндә хатын-кыз зирәклеге кирәк. Ә бу тамашаларга балаларны да катнаштыру өчен... Ярый олы уллары Эрнест – зур егет, 14 яшьтә, Зилия апасы җитәкләгән бию төркеменә йөри, шәһәркүләм «Татар малае» бәйгеләрендә катнашып, призлы урыннар алып килә. Кыскасы, сәхнәгә чыгарга әзер. Калганнары әле кечкенәрәк бит – Искәндәргә нибары – 7, Ясминәгә 4 яшь. Әмма, шуңа карамастан, чыгышны бөтен гаилә катнаширлык итеп әзерлиләр. Тамашаны тулысы белән гаилә традицияләренә бәйлиләр. Дилүзә (дөресрәге, Дилүзәләр) бүген ни өчен сәхнәдә? Чөнки этиләре – мәрхүм Риф абый Имаметдинов (гомерен шулай ук мәдәниятка багышлаган кеше, һөнәре буенча режиссер, нәфис сүз остасы, кайчандыр Чаллыда бик популяр булган «Автозаводчы» клубы директоры, шәһәр мәдәният-сәнгать идарәсендә, Чаллы телевидениесендә баш белгеч булып эшләгән) аларга мәдәният юлыннан барырга киңәш биреп, нәсыйхәт әйтеп калдырган.

...«Нечкәбил»дә Дилүзә җиңү яулый. Хәер, ул үзе бу турыда сөйләгәндә: «Бердәмлек җиңде», – диячәк, чөнки Дилүзә оештырган тамашада аның гаиләсеннән, туганнарыннан тыш, күпсанлы дуслары – Чаллының иҗат коллективлары да катнаша. Әйтик, «Болгар» ансамбле оркестры, «Земляничка» балалар бию ансамбле, «Axel» бию төркеме... Дилүзәнең эш урынында – «Чишмә» халыклар дуслыгы йортында һәм шәһәр мәдәният идарәсендә аңа ихлас күңелдән уңышлар теләп торалар. «Нечкәбил»дән соң тынычланырга да өлгермиләр, Татарстанның ЗАГС Идарәсеннән шалтыратып, Хәбиевләргә Пермь өлкәсендә узачак «Уңышлы гаилә» дип аталган бәйгедә катнашырга тәкъдим итәләр. Жюри әгъзаларының берсе – актриса, телевизион тапшырулар алып баручы Яна Поплавская аларның чыгышын югары бәяләп:

– Татарстан башкалар да омтылырга тиешле дәрәҗәне күрсәтте, – ди.

*Татарстаннан килгән бердәнбер гаилә Пермьдә дә сынатмый.*

Социаль мәсьәләләр, дигәннән... Дилүзәне мин, беренче тапкыр, хәйрия концертлары оештыручы, «Җылы куллар» инициатив төркеме лидеры буларак беләм идем. Чаллыдан һәм Түбән Камадан бер төркем татар-рус артистларын бергә туплап, сәхнәсен-залын-тамашачысын табып, бик җиренә җиткереп оештыралар иде алар әлеге концертларны. (Бервакыт концертны танылган актриса, үзе дә хәйрияче Чулпан Хаматованың тамашачыларга видеомөрәҗәгате белән дә башлап җибәргәннәр иде – монысы ул чакта Мәскәүдә Милләтләр театрында режиссер булып эшләгән Туфан идеясе булгандыр.) Тик моның белән генә эшләрен беткәнгә санамыйлар. Җыелган акчаның адресатына – ярдәмгә мохтаҗ авыру балага барып җитүенә дә, иң

PRESSA.RU





■ Дилүзә «Чулман кызлары» проектын, беренче чиратта, үзләре өчен хобби дип саный. Аның хобби булуы кимчелекме? «Киресенчә, өстенлек, – ди Дилүзә. – Бу концертлар, оештырганда, акча эшләүне максат итеп куймаска мөмкинлек бирә чөнки».



мөһиме – аның файдага тотылуына да ирешәләр! Шушы хәйрия акчасына бервакыт Артур исемле яшүсмерне Мәскәүгә операциягә алып киткән иде бит инде Дилүзә. Кеше баласын мондый сәфәргә алып бару өчен күпме батырлык кирәк? Үз балаларың да сине зарыгып көтеп торуын исәпкә алсак, күпме сабырлык... Рәхмәт хатынын һәрчак аңларга тырышкан Русланга. Ничек кенә булмасын, Ходайга шөкер, аларның тырышлыклары бушка китми, операция уңышлы чыга...

*Дилүзә бу дөньяга балкыр өчен туган кебек...*

Дилүзә ярдәм иткән кешеләр уртак танышларыбыз арасында тагын да бар әле. Тик Дилүзә бу турыда сөйләшә башлауга, мине шып туктата:

– Кирәкми, – ди. – Бу турыда сөйләшмибез, яме! Татар телендә нинди мәкаль бар әле? Яхшылык эшлә дә суга сал, диләрме?

Дилүзә белән сөйләшкәндә мин үземнең дә гел дөрес үк яшәмәвемә инанып утырам әле: бүген ул әнә инглиз теле өйрәнә, рәсем түгәрәгенә йөри. Мин: «Олылар өчен бар микән ул шундый түгәрәкләр?» – дип уйлап-хыялланып йөргән арада, Дилүзә инде картина да язып өлгергән. Руслан исә мотоцикллар, дөресрәге, байкерлык хәрәкәте белән мавыга башлаган. Уртак кызыксынулары исә – һәртөрле психологик тренинглар. Тренингларның исемнәренә генә игътибар итегез: «Үзгәрешләр чоры», «Мөмкин булмастай эш тә мөмкин». Балаларга да (яхшы мәгънәдә) бер тынгы юк. Эрнест, әйткәнемчә, биюче; Искәндәр белән Ясминә рәсем түгәрәгенә йөргәннәр, бүген «Хәзинә» дип аталган мөселман балалар түгәрәгендә шөгыльләнәләр икән. «Ничек кинәт кенә мөселман түгәрәге?» – дияргә ашыкмагыз. Беренчедән, әбиләре тәрбиясе дә тәэсир итми калмыйдыр – Зиләрә апа күптән намазда. Икенчедән, бу урында Дилүзә белән Русланның мәхәббәт тарихын да сөйләми булмый. Дилүзәнең беренче ире чуаш милләтеннән була. Гаиләләре таркалгач, Дилүзәнең булачак тормыш иптәшенә таләпләре дә үзгәрә – ул һичшиксез татар, һәм һичшиксез мөселман булырга тиеш. Ә аны яратып йөрүче егет – Руслан, кирәк бит, керәшен татары! Дилүзә өчен, мәхәббәт хакына, ислам динен кабул итә Руслан. Бүген инде ул биш вакыт намаз укый. Сүз уңаеннан... Язмышы башта хаталырак язылса да, Дилүзәнең күңелендә бүген һичнинди үкенеч юк.

Тәрбия дигәннән. Бу бит әле үзе бер зур тема! Дилүзәнең яратып сөйләшә торган темасы.

– Без әнидән тормышка җиңелрәк карарга өйрәнеп үстек, – дип сөйли Дилүзә. – Уңай мәгънәдә – җиңел! Вазаны төшереп ватабызмы, гөл савытын аударабызмы, өчле алып кайтабызмы – әни борчылганын сиздерми иде: «Әйдә, ярар, баш бәласе түгел!» – ди дә, ансат кына «үтә дә китә». Безнең балалар да шулай – иреклерәк булып үсә. Алар обойга рәсем ясый, өйдә роликта йөри... Аннары, балалар белән күбрәк сөйләшергә тырышабыз. Мин синең әниең, син әле бала гына дип түгел, тиң күреп...

Тормышка җиңелрәк карау, дигәннән, Зиләрә апаның тәрбиясе, чыннан да, диссертация язарлык тәрбия бит аның. Ялгыш төшереп ватылган вазага игътибар бирмәскә мөмкин әле ул (әйе, ул бит әйбер генә!), ә менә балаларның гомерен бушка сарыф итүгәме? Кечкенәдән үзенекеләрне җитәкләп һәртөрле түгәрәкләргә йөртә башлый Зиләрә апа. Һәртөрле диюем дә әле очраклы түгел. Бу да үзенчә бер методика. Бала төрле яклап үсәргә – җырлый да, бии дә, шигырь дә сөйли белергә, өстәвенә, әле музыка коралында да уйнарга тиеш.



■ Авырулар белән аралашып яшәү күп нәрсәне аңларга булыша аңа. Баксаң, бу язмыш сынавын да төрлечә кичерәләр икән бит кешеләр! Кемдер барыбер дөньяга, кешеләргә үпкә сакламый, өмет белән, ачык күңел белән яшәвен дәвам итә, икенчеләр гел моң-зарга күмелә, үз хәленнән хәтта ничектер файдалана ук башлый. Кагыйдә буларак, оптимистлар тизрәк савыга. Аннары, көтмәгәндә чирләп киту үзе дә төшенкелеккә бирелү бәласе түгел микән? Бар бит ул тормыштан гел канәгатьсез кешеләр. Йә акча җитми, йә игътибар җитми, дип, үзен бәхетсезгә санап яшәүчеләр. Аларга, мөгаен, тормыштан ямь эзли белү, ягъни хәрәкәт итү җитмидер. Хәрәкәттә – бәрәкәт!

Үз балаларына да шул ук таләпне куя ул, өстәмә белем бирү педагогы буларак, үз төркемендә шөгыльләнүче балаларга да. Улы – Туфаны турында әнә нәрсә сөйли:

– Үземнең җыр түгәрәгенә дүрт ел йөрде, – ди. – Шул вакыт эчендә берәр мәртәбә җырлап караса икән...

Нәрсәсе кызык: 5-6 нчы сыйныфларда укыганда көтмәгәндә җырлый башлый Туфан. Һәм башта шул түгәрәктә өйрәнгән җырларын башкара. Төп геройларыбыздан читкәрәк китү булса да, әйтим: Туфан Мәскәүдә ГИТИСка укырга кергәндә кабул итү комиссиясен җиде телдә (шул исәптән татарча да) җырлап шаккаттыра. Имаметдиновлар гаиләсенең тагын бер кызыклы хатирәсе – тальянчы Зиләрә апа, өйләнешкәч, Риф абыйны да тальянда уйнарга өйрәтә. Алар тагын бер тальян сатып алырга дип тальян ясау остасына баралар һәм бөтен гаиләгә җитәрлек итеп, берьюлы биш тальян алып кайталар.

Дилүзә белән без әле һаман балачак истәлекләреннән арына алмыйбыз. Бервакыт әнисе белән нәфис сүз бәйгесенә барганда, егылып, аягын авырттыра кыз. Тик бу аларны ярты юлда туктаткандыр дисезме? Сынганмы-сынмаганмы, дип куркышып алалар да, берни булмагандай юлларын дәвам итәләр. Дилүзә бик матур чыгыш ясый ул көнне һәм, әлбәттә, беренче урынны ала. Менә шушы була инде максатчан төстә җиңүче тәрбияләү үрнәге.

Мәктәпне тәмамлагач та, кызларга нинди һөнәр сайларга дип баш ватарга туры килми. Ничектер үзеннән-үзе аңлашыла бу. Дилүзә дә, Зилия дә Мәскәү мәдәният университетын тәмамлыйлар. Зилия Имаметдинова оештырган бию ансамбле быел инде 15 еллыгын билгеләп үтә.

Дилүзәгә акча мөнәсәбәтләре, дөресрәге, гаилә бюджетын ничек тотулары турында сорау бирмәсәм, мин, әлбәттә, хатын-кыз да булмас идем. «Русланның күпме акча эшләгәнен белмим, – дип җавап бирә ул миңа, бик әһәмиятсез нәрсәләр турында сүз баргандай. – Хәер, ул да минекен белми. Һәм кызыксынмыйбыз да. Руслан гаиләнең бөтен чыгымнарын күтәрә, минем акчаны күбрәк сәяхәтләргә тотабыз. Без бөтен гаилә белән сәяхәт итәргә яратабыз. Болай сәүдә үзәкләрендә йөрүне өнәп бетермәсәк тә, чит илгә баргач, һәр халыкның милли киемнәрен, сувенирларын җыеп кайтабыз...»

Дилүзәнең гаиләсенә һәм рәсми эшенә кагылышы булмаган тагын бер мавыгуы – «Чулман кызлары» триосы. Чаллы татар драма театрының атказанган артистлары Чулпан Садыйкова, Энҗе Шиһаповадан һәм Дилүзәдән торган бу өч кешелек иҗади төркем 2005 елда оеша.

*Килен-кияүләр дә Дилүзәләрнең шушы тынгысыз яшәү рәвешен үз итеп бетергән.*

Ансамбль бүген дә яши, алар шәһәркүләм концертларда даими чыгыш ясыйлар. Төркем һәрвакыт Илгиз Закиров, Лилия Тарханова, Зөләйха Минһаҗева кебек, Чаллы авторларының җырларын башкара. Һәм «Чулман кызлары» концерт-тамашаны, һичшиксез, нинди дә булса сюжетка кора. Үзенчәлекле татарча мюзикл килеп чыга.

Россиянең традицияләрне саклаучы гаиләсе, чыннан да, Хәбиевләр кебек – эшлекле, кызыксынучан, милли йөрәкле һәм бердәм булырга тиештер. Күпмилләтле илебездә безнең – татарның кадерләп саклар кыйммәтләре, дөрестән дә, күбрәк бит ул. Ул буыннан-буынга күчеп килгән милли һәм дини йолалар, ул татар мәдәнияте, һәм хәтта – туган тел...

PRESSA.RU







Фото: Камилә Димөхәммәтова

# НИК ТУДЫРДЫМ КӨНЕНӘ...

## ГОМЕР ИТҮ БЕР ЗАМАНДА ДА ҖИҢЕЛ БУЛМАГАН. ХӘЗЕР ДӘ АВЫР УЛ. ОЗАККА СУЗЫЛГАН КРИЗИС ЧОРЫН КҮП БАЛАЛЫ ГАИЛӘЛӘР НИЧЕК КИЧЕРӘ ИКӘН?

Мәдинә АВЗАЛОВА

Ул «күп балалы гаилә» дип сөйләми, зур гаилә ди. Мин аның ни өчен болай әйтүен яхшы аңлыйм. Күп балалы гаиләләргә карата фикер төрлечә бит. Кемдер: «О-о, биш бала...» – дип хәйран калганга салынып да, эчтән генә «фәкыйрьлек үрчетәләр», – дип куяр. Кемдер тәрбия йөгенә кереп баткан әти белән әнине жәлләр. Ничек карап бетерергә, ә иң мөһиме: ничек җиткерергә, әйтик, биш-алты балага?! Ашатуэчертү, киендерү генә түгел, җәмгыять өчен кирәкле, файдалы гражданнар да үстерү бит ата-ананың бурычы. Җәмгыять өчен булгач, җәмгыять үзе дә – дәүләтебез, хөкүмәтебез дә үстерешергә тиеш булып чыга алайса.

«Ул», дигәнем, хөкүмәтебезгә, законнар кабул итүче депутатларыбызга әледән-әле зур гаиләләр проблемаларын искә төшереп, аларга җитди ярдәм кирәклеген искәртеп торучы «Татарстанның күп балалы гаиләләре» иҗтимагый оешмасы рәисе Артем Кузнецов була. Аның зур гаиләләрне борчый торган мәсьәләләрне тирәннән «сөрүе» бер дә гаҗәп түгел. Үзе дә бит ул өч бала атасы. Шуңа күрә аның әйткән һәр сүзе йөрәккә ук булып кадала. Ул мондый гаиләләргә карата чыгарылган шактый законнарның эшләмәве, дәүләт ярдәменең бик чикле булуы, бу мәсьәләгә карата һәр төбәкнең үз законын булдыруы хакында тетрәнеп сөйли. Соңгысына ачыклык кертүне кирәк табам: мисалга,

Россия Президентының күп балалы гаиләләрдәге балаларны мәктәпләрдә бушлай ашату турындагы Указы бүген төрле регионда төрлечә эшли. Безнең Казан шәһәрендә ул гаиләсе аз мөлкәтлеләр, ягъни керемнәре яшәү минимумыннан түбән булучы гаиләләр өчен генә каралган. Чаллы шәһәрендә, мәсәлән, биш балалы гаиләләргә генә мондый ташлама каралган. Күрәсең, бай шәһәрнең мөмкинлеге шулай гына.

Әйткәнемчә, бу мәсьәләгә караш төрле регионда төрлечә. Әлеге дә баягы, мөмкинлекләрдән, кешенең хәленә керергә тырышып, бу проблемаларны тирән аңлап, ягъни... Кайбер төбәкләрдә хәтта биш бала булуга да карамыйлар, социаль хезмәткәрләр өчен хатынның ул балаларны бер ирдән табуы мөһимрәк. Ростов-на-Дону шәһәрендә, мәсәлән, биш балалы гаиләнең субсидиясен кисканнәр. Имеш, балалар – ике атадан. Көлке бит, бер уйласаң. Аннан башка да авыр хәлдә яшәүче гаиләләрне кысрыклау, тиешлесен дә бирми калдыру өчен мең төрле сылтау табу өчен ниләр генә уйлап чыгармыйлар.

Ирсез биш бала тәрбияләүче ананың, ипи алырлык та акчасы калмагач, кредит алуын, аны түли алмагач, үз-үзенә кул салуын ишетеп, озак вакытлар үземә урын таба алмый йөргән идем. Нигә ярдәм сорамаган, социаль яклау хезмәткәрләре янына бармаган? Баксаң, моның да хикмәте бар икән. Ана мәнфәгатьләрен якларга алынган Артем Кузнецов бу хәлне бик гади һәм үтемле итеп аңлата. Ул сөйләгәннәрдән башлар әйләнеп китә. Имәндә икән чикләвек. «Минем хәлем авыр», – дип ярдәм сорап барсаң, – ди ул, – иганәчелек һәм попечительлек бүлеге хезмәткәрләре шундук өеңә килә һәм сорау ала башлый. Закон буенча һәр балага аерым өстәл, караватт, йокы һәм уен бүлмәләре булырга тиеш. Уйлап карагыз, әйтик, гаиләдә җиде бала, ди. Нәрсә, хәзер һәркайсына аерым булсын дип, җиде өстәл алып куяргамы? Еш кына андый гаиләләр бәләкәй фатирларда яши. Бу – күп балалы гаиләләрнең иң зур проблемасы. Әйдә, караватлар аерым да булсын, ди... Хезмәткәрләр фатир бусагасын атлап керүгә үк суыткычка барып ябыша. Андагы ризыкны барлый да: «Балаларның ашарына да юк», – дип бәйләнә башлый. Нәтиҗәсе нинди? Әйе, мондый визитның нәтиҗәсе һәрвакыт бер: баланы социаль приютларга, балалар йортларына алып китү. Аларга да бит үзләренең эшен ничек тә булса күрсәтергә кирәк. Шуңа да без авыр хәлдә калган гаиләләр турында кычкырып йөрмибез. Ә кулдан килгәнчә, матди ярдәм күрсәтәбез».

– Лениногорск районында тугызынчы баласын тапканда ана кеше вафат була, – дип дәвам итә әңгәмәдәшем. – Әтиләре тугыз бала белән ялгызы кала. Ни әби-бабалары, ни туганнары юк. Нишләргә тиеш ул мондый хәлдә? Әлбәттә, аңа декрет ялы бирделәр. Ләкин тугыз баланы карарга да кирәк бит әле. Аның үз хәле – хәл. Әти кеше зарланып йөри алмый, эчендәгесен чыгарып селки башласа, янә газизләреннән мәхрүм калу куркынычы бар. Ә ул моны теләми. Без булышып торабыз. Аның белән гел элемтәдә хәзер.

Ул хәйрия рәвешендә кергән, грантлар отып алынган акчаны шундый гаиләләргә сарыф итүләре турында сөйли. Азык-төлек, киемсалым, тормыш өчен башка кирәк-яраклар – барысы, барысы да шушы оешма аша таратыла. Игелек кылырга, ярдәм кулы сузарга әзер торучылар бар бит ул, бар! Әнә «Ак Барс» холдингы вәкилләре мохтаҗларның исемлеген үзләре соратып алган. Азга да бәхетле, рәхмәтле булган мондый гаиләләр өчен аның өч кило ите дә әллә ни булып күренә.

«Аллаһы Тәгалә адәм баласын мәрхәмәттән яздырмасын. Без бит һәрчак шулай дип ялварабыз», – җиде бала анасы Разия ханым шулай ди. Яшәүләре ничекме? «Шөкер, – ди ул, – үзебез теләп тапкан балалар бит. Кемгәдер салынып утырулар, кемнәндер ярдәм көтүләр турында уйламыйбыз. Абзар тулы мал-туар, эшлибез, табабыз. Балаларның үскән берсе кул астына керә бара. Дәүләт ярдәме, дисезме? Ай саен бирелә торган бала акчасы, субсидияләр, ташламалар турында әйтсәң генә инде... Алары да юк дәрәҗәсендә. Дөрес, аз керемле гаиләләргә (без аңа кермибез) елына бер мәртәбә 6 мең сум биреп баралар. Күпмени инде ул?!»

Авыл җирендә тормыш башкачарак шул. Шуңа да гомерләрен

## ДӘҮЛӘТ ЯРДӘМЕ

Өч һәм аннан да күбрәк баласы булган (тәрбиягә алган балаларны да кертеп) гаиләләргә, балага 18 яшь тулганчы, Татарстан Республикасының «Халыкны адреслы социаль яклау турында»гы закон нигезендә, түбәндәге ярдәм күрсәтелә:

- торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә 30 процент субсидия;
- балага (6 яшенә җиткәнче) дару сатып алу өчен субсидия. 2016 елны бу сумма 114 сум тәшкил иткән;
- мәктәптә һәм һөнәри белем бирү уку йортларында укучы балаларга ай саен юлда йөрү өчен субсидия. 2016 елны ул 258 сум булган.

Әлеге социаль ярдәм гаиләнең керемен исәпкә алмыйча гына түләнә.

Гаилә керемен исәпкә алып бирелә торган социаль ярдәм дә бар. Керемнәре яшәү минимумыннан түбән булган балалы гаиләләргә, баласы 16 яшькәчә, ай саен пособие бирелеп барыла (укучы балага исә укуын тәмамлаганчыга кадәр).

Ата-анага матди ярдәм максатында (опекуннарга, уллыкка-кызлыкка алучыларга, тәрбиягә алучыларга):

- беренче балага – мәктәп һәм балалар бакчасы өчен 20 процент күләмендә;
- икенче балага – 50 процент;
- өч һәм аннан да күбрәк балага күрсәтелгән суммадан 70 процент ташлама ясала.

Әлеге компенсация керемнәрне исәпкә алмыйча билгеләнә.

Моннан тыш, бакчага йөрүче бала өчен дә, әгәр гаиләнең кереме кеше санынан алганда 20 мең сумнан артмаса, өстәмә компенсация каралган.

PRESSA.RU



ишектән керсәң – түр, дигәндәй, бәләкәй фатирларда уздырган күп балалы гаиләләр әкренләп авыл җирләренә каерыла башладылар.

*Республикада 30 мең тирәсе күп балалы гаилә бар – кабул ителгән законнар гамәлдә булырга һәм нәтиҗәле эшләргә тиеш.*

– Миңа да шундый үтенеч белән киләләр, – ди бу хакта сүз чыккач, оешма җитәкчесе. – Җитди проблема бу. Биш һәм аннан күбрәк баласы булган гаиләләргә торак сертификаты бирелергә тиеш. Бүгенге көндә республикада фатирга чиратта 900 гаилә тора. Елына 25–30 гаиләне тәэмин итәрлек кенә акча бүлеп бирелә. Димәк, чиратта торучылар яңа фатирга 30 елдан соң гына күчә алачак. Торак йортлар күп төзелә ул. Әмма зур гаиләләр өчен кабул ителгән торак программасы эшләми.

Күп балалы әниләрнең үзәгенә үткән тагын бер борчу – аларны эшкә алмыйлар. Бер-бер артлы балалары авырып китсә, туктаусыз больничныйда утыра башласа... Җитәкче шул турыда кайгыра, гаиләнең ачлы-туклы яшәвендә эше юк аның. Чара калмагач, әниләрнең кайберсе подъездлар җыештыра, кайберсе базарга сатарга чыга. Соңгы вакытта хөкүмәтебез тарафыннан кертелгән иң отышлы яңалык – мондый әниләргә өйдә торып эшләү мөмкинлеге тудырыла башлады.

Бала туулар арта, демография уңай үзгәрешләр кичерә, дип куанабыз. Ә менә бу җәһәттән Артем Кузнецовның фикере башкачарак. Аның әйтүенә караганда, без – «демографик чокырда». Нәрсә дигәнне аңлата бу? «Яңа туган балалар арасында татар, рус исемнәре көннән-көн сирәгрәк яңгырый. Илне көньяк халкы басып алды. Аларның хатын-кызлары бала таба, ә безнекеләр, өйләнешүгә ел да тулмый – аерылыша. Безнең республикада биш гаиләнең дүртесе таркалса, Ленинград өлкәсендә яңа өйләнешкән парларның хәтта ки 88 проценты аерылыша. Бер караганда, күрсәткеч бар да, юк та.

Әлбәттә, беренче урында бала мәнфәгатьләре торырга, гаилә кыйммәтләре өстенлек итәргә тиеш, акча түгел. Зур гаилә – ул зур дәүләт. Кызганыч, моны аңлап кына бетермибез. Бу проблемага җитдирәк караганда, күпме файдалы эшләр майтарырга булыр иде. Ни өчен, мәсәлән, мондый гаиләләргә процентсыз ссудалар бирмәскә, ни өчен бала таба-таба авызларында тешләре калмаган әниләргә бушлай теш куйдыру мөмкинлеге тудырмаска, ни өчен әлеге дә баягы торак йортлар салуга акчаны елына, әйтик, 140-150 миллион сум итеп түгел, ә 500 миллион билгеләмәскә?! Ни өчен Ана капиталын кулга тотып карарлык, кирәгенә файдаланырлык итмәскә? Ни өчен аны икенче баладан соң туган баланың һәркайсына бирмәскә?

Сораулар күп. Һәм без бу сорауларны Татарстан Дәүләт Советы депутатларына да юллыйбыз. «Күп балалы гаилә дигәндә күз алдыгызга нәрсә килеп баса?» дигән сорауга бер депутатның: «Хәерчелек һәм ачлык», – дип ычкындыруы күп нәрсә турында сөйли.

Бәлкем, әңгәмәдәшем әйткәнчә, зур гаиләләргә социаль статус алуга ирешү турында сөйләшә башларга кирәктер безгә. Аларны «хәерчелек һәм ачлык» хәлендә калдырмаска, «ник тудырдым?» көненә төшермәскә... Ахыр чиктә, кабатлап әйтәм, зур гаиләнең язмышы – ул бит әле ил язмышы да...

## ХӘЙРИЯ




«Синең файдага» – «В твою пользу» Хәйрия фонды – Республикабыздагы иң үзенчәлекле проектларның берсе. «Безнең төп эшчәнлек – сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендәге иҗтимагый һәм социаль әһәмиятле проектларны тормышка ашырырга булышу», – ди фондның генераль директоры Дарина Табакова. 2010 елдан гамәлдә булып, төрле яшьтәге кешеләргә ярдәм итүче фонд биш төрле программа белән эшли.

«Сабый чак» – аз керемле гаиләләрдә туган нарасыйларга; «Балачак» – инвалид балаларны терноклөндерүгә; «Яшьлек» программасы – балалар йортларына, мәктәп-интернатларга матди ярдәм күрсәтүгә; «Өлгергәнлек» – күп балалы һәм аз керемле гаиләдәгеләргә, балалар йортларында тәрбияләнеп, олылар дөньясына аяк баскан яшьләргә; «Картлык» – пенсиядәге кешеләргә һәм картлар йортларына ярдәм күрсәтүгә тәгаенләнгән программалар.

«Сабый чак» программасына нигезләнеп, 2016 елда Казанда «Сабый тартмасы» дип аталган социаль проект булдырылды. Авыр хәлдә калган гаиләләргә бирелүче әлеге тартмага сабыйга алты айлык булганчы кирәкле әйберләр салынган. Фонд шундый бер мең тартма әзерләгән. Горький исемендәге үзәк ял паркында ачылган «бәби бүлмәсе» дә әлеге проектның дәвамы.

Фондның эшчәнлеге болар белән генә чикләнми. Хәйрия максатында оештырылган күңел ачу программалары, спорт чаралары, шәһәребезнең 5 нче сыйныф укучылары арасында үткәрелгән «Игелек дәресләре»... Игелекнең чиге юк аның.

Ярдәм итәргә теләүчеләр булса, фондның рәсми сайты – http://vtpfond.ru/ Фонд үзе Казан шәһәренең Галиәсгар Камал урамындагы 41 нче йортта урнашкан. Телефоннары: +7 800-500-78-10.

# АБОРТЛАР: ТӨРЛЕ ЯКТАН КАРЫЙК!

**«За жизнь» Гомумроссия иҗтимагый хәрәкәтенең һәм «Православные добровольцы» хәрәкәтенең абортларны тыя торган закон чыгарырга кирәк дигән мөрәҗәгате тирәсендә бәхәсләр куерганнан-куера бара. Мондый чикләүләрне (тыю түгел, ә чикләү) Сталин чорында да кертеп караганнар. Ә менә Ленин андый законны әле 1920 елда ук юкка чыгарган. Дөрес, Патриарх Кирилл имзасы торган Мөрәҗәгатьнең ни белән бетәсе билгесез. Дәүләт Думасына барып җитәрме, халык илчеләре хөкеменә куелырмы ул, уртак фикергә килә алырлармы алар? Бик четерекле, һәркемнең бары үзенә генә кагыла торган мәсьәлә ич бу! Һәр ил әлеге проблеманы дини карашлардан һәм демографик вазгыятьтән чыгып хәл итә: әйтик, Чили һәм Доминикан Республикаларында ул бөтенләй тыелган. Аргентина, Израиль, Перу кебек илләрдә, мәсәлән, көчләнгән хатын-кыз авырга уза калса, аны төшертү рөхсәт ителә. Мәгълүматларга караганда, безнең илдә 1 миллион 900 мең бала туса, 700 мең аборт ясала. Мәгълүм ки, табиблар, һәрхәлдә, ана белән бала сәламәтлегеннән чыгып эш итә.**

**Әлбәттә, бу — мөһим мәсьәлә. Ул илнең демографик хәленә генә кагылмый, ул — һәр гаиләнең хәл-хәятенә кагыла. Шуңа күрә аны бер кизәнүдә гамәлгә кертеп булмый. Әгәр дә без абортларны тыйсак, медицинада яңа мафия барлыкка киләчәк, яшертен (криминаль) бала төшертүләр һәм шуның аркасында үлемнәр дә артачак. Тыяргамы, тыймаскамы абортларны?**

**Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы:**

– Әлбәттә, тыярга... Бу бит кеше үтерү белән бер. Ә кеше үтерү – җинаять. Бала яралган икән, димәк, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы булган, дигән сүз. Ана буласы хатын карынындагы яралгыны Аллаһ бүләге итеп кабул итәргә тиеш. Тормышлар авыр, дип тә әйтергә мөмкиннәр. Бусы да дөрес түгел. Үзең турында гына уйларга ярамый. Бала үз ризыгы белән туа. Аллаһы Тәгалә – туендыручы. Әгәр дә инде аның тууы ананың сәламәтлегенә зыян китерәчәк, дисәләр, ул чагында уйлап карарга була. Тик бусы да бары ата-ана эше, моны алар гына хәл итә ала.

**Зилә ВӘЛИЕВА, «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы рәисе:**

– Бу – гаять сак килүне таләп итә торган җитдидән-җитди мәсьәлә. «Әйе», «Юк», дип кырт кисеп кенә булмый монда. «Ярамый» дигән кисәтүләр бар инде ул. Минемчә, иң мөһиме: гаиләдә бәхетсез балалар булмасын. Ата-ана назына тилмергән бала матди яктан авыр тормышлы гаиләләрдә генә түгел, бик мул-бай тормышлы гаиләләрдә дә булырга мөмкин. Ә бит, бер уйласаң, балага бәхетле булу өчен бик аз кирәк: сөеп-сөелеп үскән баладан да бәхетле кеше бармы икән?!

Бала тудыру – җаваплы эш. Бу һәр яктан шулай. Ата-ана нинди адымга баруын бала әле карында ятканда ук тоярга тиеш. Хатын-кыз төрле хәлләргә юлыга: кайберсе эчә башлый, кайберсе наркоманга өйләнә. Андый хатын-кызның сәламәт бала табуы икеле. Белмим, андыйларга бала табу кирәкме икән? Дөнья булгач, төрле хәлләр була. Хәзер әнә балигъ булмаган яшүсмер кызларны мәсхәрәли башладылар. Ә шуннан соң йөккә узса... Төшертмичә нишләсен ул? Әйткәнемчә, һәр очракны аерым карарга кирәк. Һәрхәлдә, хатын-кыз үзе хәл итәргә тиеш бу мәсьәләне.

**Флюра ИЛДАРХАНОВА, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге директоры:**

– Ир белән хатын гына хәл итә торган гаять дәрәҗәдә нечкә мәсьәлә бу. Өзеп кенә әйтеп булмый. Әйе, балалар кирәк. Чөнки алар – безнең киләчәк. Кызганыч, бүгенге хәлдә без әллә ни майтара алмыйбыз. Чөнки биш никахның дүртесе таркала. Яшь парлар биш-алты ел бергә гаилә булып торганнан соң да бала таба алмыйлар. Дөресрәге, табарга теләмиләр. Хатын-кыз башта фатир ди, аннан – карьера, аннан аның диңгез күрәсе килә. Аннан гына бала исенә төшә. Ул вакытта инде хатын-кыз, ни сәбәптәндер, бала таба алмас хәлгә килгән була, йә ире белән аерылыша. Мондый күңелсез хәлләр булмасын өчен мәктәпләрдә кыз балага – ана, ир балага ата тәрбиясе бирердәй дәресләр кертергә кирәк. Элек бар иде ул: «Гаилә тормышының этикасы һәм психологиясе» дип атала иде. Хәтта укучы балага гаилә нормаларын өйрәтергә алынган шушы фәнне дә алып ташладылар. Чынында, ана тәрбиясе дигән төшенчә – ул мәктәптә дә, гаиләдә дә юк. Кызлар аның ни икәнен белмиләр дә. Без Мөхлисә Бубый һәм Ризаэтдин Фәхретдиннең бу җәһәттән булган фикерләрен җыйнап, дүрт китап итеп чыгардык. «Гаилә һәм тәрбия» дәресләрен шуларга нигезләп алып барганда гына да балаларны бик күп нәрсәгә өйрәтергә була.

**Дилара САФИНА, СССРның сәламәтлек саклау отличнигы, хезмәт ветераны, фельдшер-акушер:**

– Гомерем буе Баулы районының Исергәп һәм Кызылъяр авылларында табиб булып эшләгән кеше буларак, мин бу сорауга: «Һич кенә дә абортларны тыярга ярамый!» – дип әйтәм. Без инде ул «ярамый»ларны бер кичердек. Ул чагында да өйдә качып, бала төшертеп кан эчендә яткан әниләрне хастаханәгә ташулар үзәккә үтте. Криминаль абортлар саны артачак, белербелми төшертергә ярдәмгә алынган «белекле хатыннар» акча эшләячәк. Ярамый. Һич ярамый. Моның ялгыш, кирәкмәс адым булуын тормыш раслап күрсәтте ич инде. Тагын нәрсә кирәк? Мин эшләгән 1500 кешелек авылда ел саен 60 лап бала туа торган иде. Ул чагында өйдә бәбиләү шартлары да инде ташка үлчим: авыру астына җәяргә хәтта клеенкасы да юк иде бит аның. Шуңа инде... Ел да бала тапмас өчен төшертәләр иде. Баланы табарга гына түгел, багарга да кирәк бит аны.

PRESSA.RU





# «БАЛАМНЫ ХАРАП ИТТЕЛӘР...»



Мәдинә КАШАПОВА

## ЕЛ ДӘВАМЫНДА БАРГАН СУД ТА КАЙЧАН ДА БЕР ҮЗЕНЕҢ ХӨКЕМ КАРАРЫН ЧЫГАРЫР.

**Бөтен тирә-якны тетрәндергән җан өшеткеч вакыйга да кайчан да бер онытылыр. Тик менә бу хәлләрнең корбаны булган 14 яшьлек кыз бала өчен генә ул гомерлек фаҗига булып калыр.**

Узган елның кара көзендә аларның кызлары, дәү әнисенә киткән җиреннән, юкка чыга. Башта баланы телефоннан эзлиләр. Әтисенең шалтыратмаган танышы калмый. Инде нишләргә? Төн уртасы җитеп килә, ә бала юк та юк. Кая булыр, кемгә керер? Бер дә алай итми торган иде үзе. Гел әйтеп йөри торган, тыңлаучан бала. Мондый яңгырлы, шыксыз төндә кайда, нишләп йөрер икән ул?

Их-х, белсәләр икән шул чагында кызларының кайдалыгын? Хәер, beләләр соңыннан. Тик эш инде узган була. Күптән узган була. Авылдашлары соңыннан: «Ниндидер машинадан төртеп төшереп калдырдылар», – дип сөйли. Йөзе-чырае китеп, тәмам бетеренеп кайтып кергән баланы кочып алган әнисе бер генә сорау бирә: «Син исәнме?» Бала аны ярты сүзеннән аңлый: «Юк, – ди ул, – мин исән түгел, мине үтерделәр...» Ана шунда гына ни булганын, гаиләгә гомерлек ачы хәсрәт, олы кайгы килүен аңлап ала.

– Кырык көн, кырык төн еладык, – ди ул каһәрле төндә булган вакыйгаларны күңеленнән тергезә башлап. – Сораштыра башлыйбыз, үксеп елый башлый, туктата алмыйбыз. Мондый хәлнең инде беренче генә булмавын ишеткәч, дөньядан китәселәр килде. Ничек сизмәдек, ничек белмәдек, дип әле хәзер дә үземне битәрләүдән туктамыйм.

– Ничек сизмәдең соң? – дим, соравын кабатлап.

Ул югалып-каушап китә. Күрәсең, аңа инде моныңише сорауларны күп биргәннәр.

– Судта да шулай диделәр, – ди ул, үзен гаепле тоюын яшермичә. – Әмма мин, чыннан да, берни сизмәдем. Ул вакытында кайта, гел миңа булыша, әле пәрәмәч пешерә, әле өй җыештыра. Кәефе дә начар күренми. Күрсәтмәде бит бер дә, йөзенә дә чыгармады. Шуңа башыма да китереп карамадым. Соңгысында, озак кайтмый торгач кына, дөнья куптарып эзли башлагач кына ачылды чынбарлык.

Кыз – укуда. «Аның өйдә булмавы хәерлерәк тә әле, – ди әнисе көрсенеп. – Суд белән дә тилмертеп бетерделәр баланы. Чакыралар да, шул пычракны кат-кат чыгарып селкергә, сөйләргә мәҗбүр итәләр. Узган сөйләгәннәрдән бер сүзне төшереп калдырса, яңадан сөйләтәләр. Аннары: «Ятлап килгән ич бу, һаман бер сүзне кабатлый», – дип теңкәгә тияләр.

Әңгәмәбез иплән кенә моннан бер ел элек булган хәлләргә әйләнеп кайта.

### «Әтиеңне үтерәбез, әнегезне яндырабыз...»

– Бөтен бәхетсезлекнең башы – шул егеттә, – ди ханым, җөмләне урта бер җирдән башлап. – Кызымның бер әйткәне дә бар: «Артымнан йөри, яратам, дип әйтә...» Шул чагында кисәттем дә әле: «Иртә сиңа егетләр белән йөрергә, җилкәңә кулын да салдырма, ярамый», – дидем. Ул шундук минем белән ризалашты. Кая инде, 14 яшьтә... бала гына ич әле. Кызыбыз гел яныбызда булды, сорамыйча әллә кая чыгып-китеп йөрмәде. Ул – безнең күз алдында. Әнә... йә күршеләрнең капка төбендә, эскәмиядә кызлар белән көлешә-көлешә сөйләшеп утыра, йә әниләргә кич утырырга бара. Телефон, ул-бу була калса, кесәсендә... Әйтәм ич, тикшереп торыгыз дигән булалар, аннан гына тормый икән ул. Күрәчәгең булмасын...

Ә кызның күрәчәге үзенә дә әле 16 яшь кенә тулган егет кисәге инде күптән хәл итеп куйган була. Судта алты очрак – алты эпизод карала. «Әтиеңне үтерәбез, өегезне яндырабыз», – дип, кызны әледән-әле, мәктәптән кайткандамы, урам буйлап баргандамы, машинага өстерәп кертәләр дә, каядыр алып китәләр. Беренчесендә егет үзе генә була. Соңгысында аңа ике дусты да килеп кушыла.

*Элек мондый җинаять кылган кешенең бөтен нәсел-нәсәбен авылдан куганнар.*

2015 елның октябрь урталары... Кызның мәктәптән кайтканын сагалап тора да, күрше авылга гына барып кайтабыз дип, егет аны машинага төртеп кертә. Барып җиткәч, танышларына алып керә, арттан аның ике дусты иярә. Өйгә кергәч тә кызга чишенергә боера. «Мин сезне әтигә әйтәм», – ди бала, соңгы өметенә ябышкандай елый башлап. Кызны ирексезләп чишендерәләр, эшлисе кабахәтлекләрен эшләгәч, егет әйтә: «Әйдә, үтерәбез, әтигә әйтәм ди бит», – ди. Каяндыр пычак тартып чыгара. Шул чагында арадан берсе туктатып калмаса, ул имансыз көчләү генә түгел, ә бәлки кеше үтерүгә дә барып җитәр иде. Куркыныч

### БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ



Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясенең җаваплы секретаре Илсөяр ГАРИФУЛЛИНА

– Кызганыч, мондый хәлләр әледән-әле кабатланып тора. Ирләр бик йөгәнсезләнде хәзер. Җавап бирүдән дә, суд каршына басудан да курыкмыйлар. Ир-ат белеп торырга тиеш: балигъ булмаган балага кул тидерү, бигрәк тә көчләүләр иң зур җинаятьләрнең берсе ул. Һәм алар моның өчен иң каты җаваплылыкка тартылырга тиеш.

Безне әти-әниләр: «Үз-үзеңне сакла!» – дип үстерделәр. Безгә гел: «Итагатьле булырга, кеше арасында үзеңне матур тотарга кирәк», – дип тукып тордылар. Аллаһы Тәгалә саклнганны саклармын дигән. Чыны да шулай бит. Кыз балага моның мәгънәсен яхшылап, сеңдереп аңлатырга кирәк. Аннары балага гаиләдә генә түгел, мәктәптә дә әхлакый тәрбия җитеп бетми. Безгә әнә шул хакта җитди уйланырга вакыт.

Фото интернеттан алынды

PRESSA.RU



*БЕЛГЕЧ КИҢӘШЕ*



Психологик ярдәм оештыру бүлекчәсе мөдире, психолог Ирэна БОБРОВА

– Сексуаль көчләүгә тарыган бала зур психологик тетрәнү кичерә. Ул хәтта иң якыннарына да сагаеп, куркып, икеләнеп карый. Үзен көчсез, ярдәмчесез итеп тою аны читләшергә, үз эченә бикләнергә мәҗбүр итә. Бала беркемгә ышанмый, бигрәк тә өлкәннәргә. Җәберзолым корбаннары иң элек өлкәннәрдән куркалар, алардан шикләнәләр. Алардан ярдәм сорауны күз алдына да китермиләр. Еш кына андый баланың тормыш шигаре: «Беркемгә ышанма, бернәрсәгә өметләнмә, беркемнән бернәрсә сорама»дан гыйбарәт.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, бу очракта ата-ананың баласына карата аеруча җылы, ихлас мөнәсәбәте зур роль уйный. Балага һәрвакыт: «Син ялгыз түгел, без сине башка беркемнән дә рәнҗеттермәбез, без сине бик яратабыз...» ише сүзләрне кабатлап торырга кирәк. Бала үзенә карашның үзгәрмәвен, аны элеккечә чын күңелдән яратуларын тойсын. Гаиләдә шундый фаҗига килеп чыга икән: «Мин сиңа ышанам. Бу синең гаеп түгел. Ярый әле миңа сөйләдең. Башка сиңа куркыныч янамас...» дигән сүзләр белән баланы юатыгыз. Бала мондый вакытта үзен гаепле хис итә, ояла. Кайвакыт ата-ана баланы: «Котырткансыңдыр, шуңа ябышкандыр», – дип сүгә. Еш кына бу сүзләрдән соң кыз бала вазгыятьне әти-әнисе күзлегеннән чыгып бәяли башлый. Мин үзем гаепледер, дигән фикергә килә. Ә бу исә баланы стресслардан, тирән һәм авыр кичерешләрдән тартып чыгаруда буй җитмәс киртәләр тудыра.

*Бәлкем, район җирлекләрендәге балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясе әгъзалары кеше арасында күбрәк йөрерләр, балалар белән аралашырлар.*

яшьләр үсә. Кайчак шул хакта уйлана башлыйсың да, ис-акыл китә. Бер карaганда, 16 яшь – бала дисәң, бала түгел, олы кеше дисәң, олы кеше түгел, шундый вакыт... юләр чак. Психологлар әйтүенчә, мондый чорда балага гел күз-колак булырга, ата-ана аннан кул сузымында торырга тиеш! Чөнки үсеш-күчеш чоры балага бик авырдан бирелә. Аның киләчәге – кайсы юлга борылыш ясавы хәл ителә торган чор. Кызганыч, бу хакта күпләр оныта. Нәтиҗәдә, менә шундый хәлләр.

– Чишендергәч, тәрәзәдән ташланмакчы булган, тотып калганнар, – дип сөйли күз яшьләренә буылабуыла әни кеше. – Күпме стресс, кичереш бер балага. Ә суд һаман дәвам итә.

Шулай... Бер генә түгел, берничә мәртәбә кабатланган бу вәхшилекне оныту җиңел булмас аңа. Кыз баланың әле башланып кына килгән тормышы алга таба ничек булыр, язмышы ничек язылыр? Күп нәрсә хәзер әти-әнидән, якын туганнарыннан, әлеге дә баягы авылдашларыннан да тора. Мөселман гаиләләрендә гомергомергә кыз баланы: «Намусыңны сакла!» – дип үстерәләр. Әгәр дә Чечня, Дагстан якларында шушындый хәл килеп чыкса, кызны яклауга бөтен дөнья, бөтен туган-тумача күтәрелер иде. Бер генә мисал: мөселман егетенең яраткан кызына радио аша җыр тапшыруын тыңлаганнан соң, кызның әтисе кызын үтерүе турында ишеткәч, хәйраннар калган идем. Ни өчен үтерә? Радиодан кызның исемен дөньяга хәбәр итеп, аның намусына тап төшергәннәр. Бусы, әлбәттә, кыргыйлык. Әмма сүз кыз баланың намусы хакында бара. Һәркайсыбыз тирәнтен уйланырга, мондый тетрәндергеч хәлләргә битараф калмаска, бернәрсә булмаган кыяфәт чыгарып йөрмәскә тиеш, дип әйтүем.

### «Үз теләге белән», димәкчеләр

Судта кызның мәнфәгатьләрен яклаучы адвокат Гүзәл Төхвәтуллина: «Эш бик сәер алып барыла. «Нигә трубканы алдың, нигә алар белән сөйләштең, ник алар чык дигәч чыктың?» – дигән сораулар бирәләр. Кызны куркытулары хак бит. Шуңа күрә ул беркемгә берни сөйләмәгән, ахыргача түзгән. Судьяның кем ягында булуын сорауның куелышына карап та чамаларга була», – ди. Һәм дөрес әйтә. Судның елга якын баруы үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. «Хөкем карарын да 131 нче маддәдән «үз теләге белән» дигән маддәгә үзгәртмәкчеләр», – ди ул. Күз алдына китерегез: 14 яшьлек кыз бала һәм... әзмәвердәй өч ир-егет, җитмәсә, кызны «үз теләге белән», дип мәсхәрәлиләр.

– Шушы хәлләрне белүгә, шундук прокуратурага гариза яздык. Язарлар, дип уйламаганнар икән. Теге ерткычларның әти-әниләре уйга калды. Бүтән чара калмагач, егетнең әтисе: «Йөреп карасыннар, 18 яшьләре тулгач, өйләнешерләр», – дигән сүзне дә ычкындырды. Әтисе малаеннан: «18 яшемдә өйләнәм», – дип расписка да яздыртты. Шуннан ни дип уйлыйсыз? Бервакыт авылда сүз чыкты, имеш, алар үзләренең «батырлыкларын» видеога төшереп алганнар. Тагын киттек егетнең өенә, тагын: «Видео дөньяга чыккан очракта җаваплылыкны үз өстемә алам», – дигән расписка яздырттык. Хәтта шушындый хәлләрдән соң да һаман да авыл кешесе ишетмәсен, дөньяга фаш булмыйк, дидек. Кызым да шуннан куркып, оялып, дәшми йөргәнгә генә харап булды. Баштан ук сөйләгән булса, бу кадәргә үк барып җитми идек.

«Кызымны шул мөртәткә бирәмме соң?» – ди тәмам кайгыга сабышкан ана. Мин дә аның фикеренә кушылам. Мөмкин булмаган эш икәнен расларга керешәм. Бер-берсенә тирән хисләр белән, яратышып өйләнешкән парлар да еш кына, юктан гына аерылышып куя. Ә биредә... хәтта әйтеп тә торасы килми. Сират күпере кичкән кызны яңадан тәмуг утына тыгу белән бер булыр иде ул.

### «Курыкма, син ялгыз түгел!»

Суд барган арада кызга инде 16 яшь тулган. Ул укуын дәвам итә. Дөрес, үзен берни булмагандай тоту аңа бик авыр. Гомеренә җитәрлек җәрәхәт калдырган бу вакыйга аны төннәрен сискәнеп уянырга мәҗбүр итә. «Дәү әнием, мин йоклый алмыйм», – дип, төн уртасында яныма килеп ята. Кочаклашабыз да, икебез дә шыпырт кына елыйбыз. Курчак булгандыр инде, курчак...» – дип авыр сулый күпне күргән карчык. Һәм яшьлегенең сугыштан соңгы чорларга туры килүе, ачлык-ялангачлыктан башканы күрмәгән халыкның күңелендә һәрчак бары игелек-изгелек булуы турында сөйләп китә. «Эшләмиләр, әзергә-бәзер яшиләр. Шуңа тәртипсез алар», – дип йомгаклый ул сүзен.

Эшсезлек тә, аннары ата-ананың баласы өчен җавап тотмавы да... барысы, барысы да бер зур бәла булып, кире үзләренә әйләнеп кайта. Бумеранг дигән нәрсәне ишеткәнегез бармы? Менә шул инде ул. Башкача әйткәндә, һәркем, һәрнәрсә өчен җавап бирә. Әйтик, бу юлы булмаса, икенче юлы. Бу юлы җаваплылыктан котылу юлларын эзләп табасың икән, киләсе юлы тагын да катырак килеп кабасың. Чөнки кылган җинаяте өчен җәза алмаган кеше алга таба да үзенең җәзасыз калачагына ышана. Һәм шуның белән кармакка килеп эләгә.

– Суд бара, ә коридорда – эскәмияләргә тезелешеп утырган егетләрнең әниләре кәбестә тозлау турында сөйләшәләр. Аларга шуннан да мөһимрәк мәсьәлә юк шикелле, – дип дәвам итә әңгәмәне кызның әнисе. – Ә берсе: «Әгәр дә малайны утыртсалар, бөтен нәселегезне каргыйм. Ә кызыңны дөньядан юк итәм», – дип яный. Курка да калдым: чыннан да, әйткәнен эшләсә...

Каргаса... Каргыш таягы ике яклы. Кылган гамәлләре өчен кемнең һәм ничек итеп җавап бирәсен Аллаһы Тәгалә бер үзе белә. Аннан килеп, «Ни чәчсәң, шуны урырсың» дигән гыйбрәтле мәкальне дә онытмагыз. Тормыш дигәнебез безнең уйларыбыздан, гамәлләребездән гыйбарәт. Әгәр дә уйларыбыз якты икән, ул безгә, һичшиксез, игелек булып әйләнеп кайтачак һәм киләчәк тормышыбызга бары уңыш-бәхет кенә алып киләчәк. Нинди генә четерекле вазгыятьтә дә адәм баласы, хисләренә түгел, акылына таяна. Акылы булган очракта, дип әйтүем. Ә булмаса инде, гафу итәсез, кем әйтмешли, тозлы кәбестә...

Кызның әти-әнисе бу вәхшилек турында, күзләрен чытырдатып йомып, онытырга да риза иде. Тавыш кына зурга китмәсен дә, кеше генә белмәсен. Кая ул? Интернетта бу хакта күпме сүзләр йөрде, күпме гайбәт сөйләнде. Кызның телефонына ул залимнән янап та, ялварып та хәбәрләр килә торды. «Әйбәт кенә йөри-йөри дә, кычкырып елап җибәрә», – ди үзе дә чактан гына елап җибәрүдән тыелып торган дәү әниләре. – Мин аңа әйтәм: «Балам, курыкма, син ялгыз түгел! Без бар, дим».

Ялгыз шул ул. Уйлары, кичерешләре белән ялгыз. Гомумән, мондый хәлдә калган балаларга ярдәмгә бөтен җәмәгатьчелек, иҗтимагый оешмалар, мәктәп, балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясе әгъзалары кушылырга тиеш. Судның хөкем карары чыгарганын көтеп утырмаска. Аннары соң булуы хакында әйтеп тору кирәк микән?! Һәрхәлдә, мин сөйләшкән шушы мәсьәләләр белән шөгыльләнүче муниципаль дәрәҗәдәге оешма вәкилләре шулай дип котылдылар. «Суд карары булсын әле...»

Элек без урта белем бирү мәктәпләрен тәрбия бирү мәктәбе дип тә белә идек. Укучысына барып ирешергә тиешле хәбәрне дә телефон яки интернет аша гына җибәреп яткан, аралашыр өчен вакыт таба алмаган сыйныф җитәкчеләре турында безгә күп сөйлиләр, еш язалар. Кайбер очракта бала әнисе белән түгел, укытучысы, икенче бер якын кешесе белән сөйләшүне, аңа ачылуны кирәгрәк һәм дөресрәк саный. Ел дәвамында кемгә дә булса йөрәгендәгесен, күңелендәгесен ачып салырга курыккан бала ялгыз түгелмени?! Тәрбия мәсьәләсе белем бирү мәсьәләсе шикелле үк мөһим һәм кирәкле. Ике кулың һәм ике аягың кебек кирәкле! Аларны бер-берсеннән аерып карап та булмый.

*Сексуаль җәбер-золым корбаннарында психик тайпылышлар күзәтелергә мөмкин: әйтик, алар кисәк сискәнеп китә, шомлана, кинәт елый башлый, ярсып китә...*

Хәзер уйлыйм: ярый да әле Татарстанда бала мәнфәгатьләре өчен алны-ялны белми көрәшкә ташланырга әзер торучы Бала хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил бар. Яклау эзләп кемгә барып егылыр идең? Кемнән ярдәм сорар идең? Мин боларны тикмәгә әйтмим. Алдагысы кыл өстендә торган (үз теләге белән, димәкчеләр бит) кыз баланың язмышын, бу катлаулы, гаять тә җитди мәсьәләне ачыкларга алынган вәкаләтле вәкил Гүзәл Удачинаның абруйлы сүзе, дәрәҗәсе, аналарча кайгыртуы төшенкелеккә бирелгән гаиләне дә, безне – журналистларны да вазгыятькә башкача карарга мәҗбүр итте.

Тимер рәшәткә артындагы тормыш, тәҗрибә күрсәткәнчә, адәм актыкларын тәртипле булырга өйрәтер, тәүбәгә китерер, дип уйламыйм. Әйткәнемчә, бер генә яман ният белән кылынган гамәл дә җәзасыз калмый. Беркем дә һәм һичнәрсә дә... Җавапны һәркайсыбызга бирәсе... Бу очракта, гомумән дә, каты җәза көтелә. Россия Федерациясе Җинаятьләр кодексының 131 нче маддәсе (3 нче өлеш) нигезендә хөкем ителүчеләрне 8 елдан 15 елгача кадәр ирегеннән мәхрүм итү каралган. Яшүсмерләр, мәктәп балалары ул законнарны яхшы белергә тиеш. Белергә һәм аны санламауның нәрсәгә китерүен ачык күзалларга... Бары шунда гына без алга киткән илләрдәге, әйтик, Австралиядәге кебек хатын-кызны көчләүгә карата мөнәсәбәтне дәүләт проблемасы дәрәҗәсенә күтәреп: «Кискен каршы!» дип, үз фикеребезне ачык һәм тәгаен белдерә алачакбыз.

PRESSA.RU



ЯЗМАМНЫ РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН СҮЗЛӘРЕ БЕЛӘН БАШЛАУ ЮККА ГЫНА ТҮГЕЛ. СҮЗЕБЕЗ БАЛАЛАРГА БАГЫШЛАНАСЫ. ДӨРЕСРӘГЕ, БАЛАНЫ ЧИТ-ЯТ КЕШЕНЕҢ АЧУЛАНУЫНА, ТӘРБИЯЛӘРГӘ МАТАШУЫНА.



# «МИН ҮЗЕМ КАДӘР ӘЛЕ – КИЗӘНМӘ!»

Трамвай буп-буш диярлек. Арттарак берике кеше бар да, алдарак олы гына яшьтәге бер апа утырган. Кызым белән аның артындагы буш урынга утырдык.

«Әни, масына! («р» авазы бездә әлегә – «л», «ш» авазы «с» булып чыга). Кала, һау-һау!» Маэмай күрү шатлыгыннан хәтта урыныннан ук калкынып куя. «Әни, таубус!» Автобусны да утырган җирдән генә сикергәләп, сәламлибез. Бәләкәй аяклары алдагы утыргычка тиеп-тиеп киткәли. Тукталышта әнисен җитәкләп басып калган малай да, светофорлар да, машиналар – барысы да кызымның сәламенә «коенып» кала. Бала бит, шыпырт, дигәнгә дә, аякларын атындырып, алдагы утыргычка бәрергә ярамагына да исе китми. Дөресрәге, китмәгән иде. Теге апа борылып кычкырганчыга кадәр. «Тагын бер типсәң, аягыңны өзәм! Анасы да шуны карап бара, ник бер «замечание» ясасын!» Апа, безне ачуына күмеп, киләсе тукталышта ук төшеп калды. Бала – куркуыннан, ә мин, мондый һөҗүмне көтмәгәнлектән, ни дияргә белми, авыз ачып калдык.

Мондый хәлләр тормышта гел булып тора. Күз алдында баланы ачуланып, куркытып, янап китүчеләргә әни кеше ничек җавап бирергә тиеш соң? Чит баланы ачулану ярый торган гамәлме? Шушы сораулар белән укучыларыбызга инде таныш психолог, биология фәннәре кандидаты, доцент Саҗидә РУСИНОВАга мөрәҗәгать иттек. Аның хөкеме катгый: беркемнең дә баланы ачуланырга хакы юк! Беркемнең дә! Әти-әнисенең дә!

– Бала әле яшәргә генә өйрәнеп килә. Ул әле нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнен дә рәтләп белми. Хокукый яктан карaганда, баланың хокуклары гына бар, ул бернәрсә өчен дә җавап бирми. Җаваплылык ул – ихтыяр көче. Кешенең ихтыяр көче өчен баш миенең маңгай өлеше җаваплы. Ә ул 18-20 яшьләргә генә өлгереп җитә. Бүгенге чор балаларының ул әле тагын да соңрак өлгерәчәк, – ди Саҗидә ханым. – Минем үз оныгымны да кунакка баргач, оялтып, ачуланып ташлаганнары бар. Мин артык нечкә, хисчән кеше түгел, тормышны күргән кеше. Шулай да баламны аны тәрбияләргә хакы булмаган икенче берәүнең ачулануы миңа бер дә ошамады. Безнекеләр – авыл тәрбиясе

алган халык. Казанда да авылдан килеп төпләнүчеләр күп, ә авылда балалар белән кәнфитләнеп тормыйлар. Авыл ул – тар даирә, консерватив кыйммәтләр мохите. Анда биосоциаль канулар. «Кызның анасы – кырык, кырык беренчесе – чыбык», – дигән гыйбарә дә авылда тугандыр. Кешеләр бер-берсе белән якыннан аралашканга, чит кеше тирәлеге дигән чикләр җуела. Күрше малаен тәрбияләшүне авылдашлар үз бурычы дип саный. Балаларны яратмаганнан түгел, ә күрше-күләннең бала-чагасы өчен һәркайсы үзен җаваплы тойганлыктан шулай килеп чыга бу. Моның яхшы ягы да бар, начар ягы да. Яхшы ягы – авылда балалар, әти-әни күрми дип, ни теләсәләр шуны эшләп йөри алмыйлар. Алар күрмәсә, күрше апасы яки күрше абыйсы күрә һәм, тотып колакны бормаса да, һичшиксез әти-әнигә хәбәр итә. Авылда балаларны бөтен мәхәллә белән тәрбиялиләр. Шушы мәхәллә рухын ул шәһәргә килгәч тә саклый: бер белмәгән балага кисәтү ясарга үзен хаклы дип саный. Әмма... ялгыша.

Шәһәрдә бөтенләй башка мохит. Үз әти-әнисеннән гайре берәү дә балага бернинди йогынты ясарга тиеш түгел. Олы кеше үзен яклай ала, ә бала – юк! Ул олы кеше алдында көчсез. Физик көчсезлек турында гына әйтмим әле мин, бала рухи яктан да аңа караганда зәгыйфьрәк бит. Бармагы белән яный-яный ачуланып, ул кеше баланы түбәнсетә. «Син минем алда көчсез, мин сине теләсә нишләтә алам!» – дип әйтү бу. Без, олылар, аңа кечкенәдән үк, өлкәннәр дөньясының аннан өстенрәк булуын күрсәтәбез. Ләкин олылар дөньясы кайвакыт шулкадәр миһербансыз. Бала исә әлегә һәркемгә ачык. Ул олы кешегә ни дәрәҗәдә ышанырга яраганын белми. Менә шуның өчен дә безнең балалар җәбер-золымга тиз бирешүчән. Чит-ят баланы ачуланучы әни кешенең дәрәҗәсен генә төшереп калмый, баланың бәхетле киләчәгенә дә кизәнә. Ничекме? Баланы ачуландылар, ә әнисе аны яклый алмады. Бала бу вакыйганы бераздан онытыр да анысы. Әмма әнисенең аны яклый алмавын ул күңел төпкеленә салып куячак: «Әни мине яклый алмый. Аңа ышанырга, таянырга ярамый. Әни көчсез, үзе бер мескен, моннан соң миңа үземне үзем якларга кирәк булачак», – дигән уй кереп урнашачак анда. Аннан аптырыйбыз, карап торышка шундый яхшы булып тоелганнар да кайчак көтелмәгән җинаятьләр кылып куя. Балачакта тирәнгә кереп калган үпкәләр, агрессия, әнә шулай һич көтмәгәндә бәреп чыга. Ә бит җәмгыятькә әхлакый нормаларны тешен кысып үтәүче кешеләр кирәкми. Безгә һәртөрле агрессиядән азат, иркле кешеләр кирәк. Баланы ачулану, куркыту – рухи көчләү ул. Үзегез беләсез, көчләү берничек тә яхшы тәрбия бирү түгел.

«Нишләргә соң?» – диячәксез. Беренчедән, әти-әниләрнең үзен дә бик яхшылап тәрбияләргә кирәк әле. Акыллы әни яки әти үзен шушы бала урынына куеп карасын. Бер белмәгән олы кеше каты тавыш белән, бармак яный-яный, аны ачуланганда ул үзен ничек хис итәргә тиеш? Ә аның урынында сезнең балагыз булса, аны шулай ачулансалар? Сез моңа ризамы? Мин бер нәрсәне ышандырып әйтә алам: сез кемгәдер зыян саласыз икән, ул кабат үзегезгә әйләнеп кайтачак. Үзегезгә булмаса, балагызга, оныгыгызга. Бу – психологик вирус. Аны таратудан туктарга кирәк.

Сез менә трамвайда барганда авызыгызны ачып калып, дөрес эшләмәгәнсез. Балага юнәлгән агрессияне шунда ук туктатырга тиеш идегез. Мондый вакытта тиз, катгый һәм таләпчән булырга кирәк.

Тормышчан мисаллар дигәннән, бер танышымның кызын кунакка гына килеп-китеп йөрүче әбисе (танышымның кайнанасы) гел ачуланып, тәнкыйтьләп тора. Утыруын да дөрес утырмый, ашавын да дөрес ашамый, чәчен дә тиешле урында тарамаган... Баланы яклап сүз әйтсәң, үпкәләве бар. Бу очракта нишләргә?

*Бумеранг кануны – иң гадел канун. Ул һичшиксез үтәлә. Үз гамәлегез үзегезгә үк әйләнеп кайтачак.*

Саҗидә ханым килен кешенә кайнанасы белән сүзгә килмәскә өнди. Иң яхшысы: ирегез белән сөйләшеп, әби кешегә булган дәгъваларыгызны аның аша әйтү. Сүзне болайрак башларга була: «Әни, ничек дөрес икәнен син балага үзең күрсәт. Үзен ничек тотарга тиешлеген аңлат. Кычкырып, ачуланып, син бит аны үз-үзенә начар итеп күрсәтәсең. Аңа бит моның белән гомер буена яшәргә. Минем балам шулай ук бөтенесеннән дә начарракмыни?» Баланы гел ачуланып, тәнкыйтьләп тору, аның «канатларын кисә», мин – бер булдыксыз, дигән комплекс булдыра. Балага үзен генә ачуланалардыр шикелле, ул бит башкаларның да шелтә алганнарын ишетми. Аннары балаларның бер үзлеге бар: алар кемне ни өчен ачуланганнарына түгел, кемне ни өчен мактаганнарына күбрәк игътибар итә. Тәрбиянең нигезендә ачулану, шелтәләү түгел, мактап үсендерү һәм яхшы үрнәк ята.

Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.

**ФИКЕР**

Барыбызга да яхшы таныш Сәйдә абыстай Аппакова да шушы ук фикердә: «Чит кеше баласын түгел, үз балаңны да ачуланырга ярамый! – ди ул. – Кемнедер ачулану – үзеңне аннан өстен итеп кую була. Ачулану – каз өстенә су койган кебек, коела да бетә, баланың күңелендә калмый. Кирәк сүзне иплә кенә, балам, болай эшләргә ярамый бит, дип, җай белән – җилкәсеннән сөеп кенә аңлатырга кирәк. Өч тапкыр әйтеп тә, барыбер дә тыңламый икән, ул чагында инде ачуланырга да була. Менә мин 1 сентябрьдән 20 сентябрьгә кадәр транспортта яшьләрне вәгазьләп йөрим, балалар, олыларга урын бирегез, дип өйрәтәм. Кайвакыт әбиләр: «Хәзер яшьләр шундый инде, урын бирмиләр», – дип чәчрәп ябыша. «Болай ямьсез итеп сорагач, мин дә бирмәс идем», – дим. Матур итеп – җайлап, ягымлы тавыш белән генә сорарга кирәк».



Аерым шәхесләрнең әлеге мәсьәләгә карата фикерләрен сайтыбыздан укый аласыз.

Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU



# ЯШЬ ЧАК – БЕР ЧАК

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

**Алиягә бервакыт илбашының үзенә «боерык» бирергә туры килә. Аңа гына да түгел, республиканың тагын ике зур җитәкчесенә. Аның белән таныштыруны да, мөгаен, шушы төштән башларга кирәктер.**
**Алия ИСТОМИНА (ФӘРХЕТДИНОВА) – «ТАНЕКО» нефть эшкәртү заводының яшьләр оешмасы җитәкчесе. 3 мең 200 кешелек коллективның яртысыннан артыгы, ягъни 53 (!) проценты яшьләр аларда.**

Алия «ТАНЕКО»га аның нинди завод икәнен дә белми эшкә килә. Үзе шулай ди. Аларны, КХТИның Түбән Кама шәһәрендәге филиалын «кызыл диплом»га тәмамлаган берничә кызны, заводка әңгәмәгә чакыралар. «ТАНЕКО» җитәкчеләре сайлап алган өч яшь белгечнең берсе Алия була. 2008 ел әле бу. Алиянең генә түгел, Түбән Кама халкының да төзелеп кенә ятучы әлеге заводның нәрсә эшләп чыгарачагыннан хәбәрдар булмаган вакыты.

Яшь менеджерны директорларның алмаш сәркатибе итеп билгелиләр. Төзелеш буенча директорның сәркатибе инде ике ел ялсыз эшләгән була: Алияне иң беренче эш көнендә үк аның урынына утырталар. Әйтергә генә җиңел! Йөзә белмәгән кешене елга уртасына ташлау белән бер була инде бу. Әмма Алия йөзеп китә!

– Заводта иң җаваплы юнәлеш төзелеш иде ул чакта. Кая карасаң да – төзиләр... «Чәй китер, алып кит, телефонга җавап бир!» Бу җөмләләр безнең сәркатипләр турында түгел – алар өстендә бөтен документ әйләнеше. Алар – иң беренче ярдәмчеләр. Төзелеш өчен ул чакта директор Хөҗҗәт Рәхимҗанов җаваплы иде. Шактый кырыс җитәкче. Дөрес, аннан соң тагын да кырысраклары белән эшләргә туры килде... Директор: «Миңа фәлән кешене табыгыз», – дигәндә, «аның телефоны менә шушы» дип әйтми бит. Беркемне белмим! Яңа эшкә урнашкан һәр яшь кешегә остаз беркетелә бездә. Бу традиция хәзер дә дәвам итә. Бер остазның берничә шәкерте дә булырга мөмкин. Минем дә бар иде андый «коткаручым»: документларны контрольдә тоту бүлегенең әйдәп баручы белгече Лилия Исхакова яныма утырып барысын да аңлатты. Мин шул чакта чыныктым...

Завод Алиянең күз алдында төзелә. Сәркатипләр протокол вазыйфаларын да башкара – хөкүмәт делегацияләрен, илбашларын – Дмитрий Медведевны, Владимир Путинны кабул итү чараларында да катнашырга туры килә. Ниһаять, иң беренче зур объект –

азот станциясе сафка тапшырыла. Республика өчен генә түгел, илкүләм әһәмиятле вакыйгага әйләнә ул!

– **Иң беренче установканың эшли башлавын игълан итү миңа насыйп булды!** Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, «Татнефть»нең генераль директоры Наил Маһанов белән «Камаглавстрой»ның ул чактагы җитәкчесе Валерий Самилов установка төймәсенә басты. Мин команда биреп тордым. Ул чакта заводка кагылышлы бер генә терминны да белми идем әле – язып биргән текстны гына укыдым...

«ТАНЕКО» белән бәйле терминнарны күптән аңлый инде Алия. Кадрлар бүлегенә эшкә кучкач, профессиональ ориентация буенча белгеч буларак, мәктәп балалары, студентлар белән завод буйлап экскурсияләрдә бик күп йөрергә туры килә аңа.

– **«ТАНЕКО»да гади эшче булып эшләүне дә бездә – Түбән Кама шәһәрендә яшәүчеләр дәрәҗәгә саный,** – ди Алия. – Завод оешкан чагында генераль директор Хәмзә Баһманов кешеләрне эшкә алганда һәркем белән үзе сөйләшә торган иде: идән юучы, урам себерүчегә кадәр үзе сайлап алды. Безнең концепциягә туры килмәүчеләрне кире борды. Ул чакта югары уку йортын тәмамлап кына килгән шактый яшьләр урнашты безгә. Ә хәзер инженер урынына тәҗрибәсе булмаганнарны алмыйбыз. Ниндидер сәбәп белән ул урын бушый икән (әмма бездә эштән бик сирәк китәләр!), әлеге вазыйфаны башкарырлык хезмәткәрләр үзебездә дә бар. Югары квалификацияле эшче кадрларга гына кытлык кичерәбез. Яшьләр «эшче» дигәч, комбинезон кигән, баштанаяк майга чумган, кулына ачкыч тоткан кешене күз алдына китерә. Экскурсия вакытында күрәләр: бөтен нәрсә дә автоматлаштырылган бездә. Һәркайда чисталык-пөхтәлек. Завод территориясе буш диярлек: эшчеләр оператор бүлмәсендә утыра, технологик процессларны компьютер аша гына күзәтә. Кул хезмәте 10 проценттан артмый: авария булган очракта нәрсәнедер борырга, төзәтергә, ремонтларга туры килсә генә. Югары белем турында диплом алуга, җитәкче булырмын, дип ялгыша яшьләр. Моның өчен түбәннән күтәрелергә кирәк... Тагын бер нәрсә бар: югары квалификацияле эшчеләрнең (технологик җайланмалар операторлары, машинистлар) хезмәт хакы инженер-технологларныкыннан югарырак бездә.

**– Цех башлыкларының күбесе – якынча 80 проценты – хезмәт юлын гап-гади эшче булып башлаган»,** – ди Алия. Эшли-эшли югары белем алу мөмкинлеге тудырылган аларга. Әйбәт укысалар, хәтта укыган өчен дә завод үзе түли!

«ТАНЕКО» – «Татнефть» компанияләре төркеменә керә. Ә анда яшьләр белән эшләүгә зур игътибар бирелә. Яшьләр оешмасы Алияләрдә дә күп тармаклы. Һәр цех, һәр зур төп подразделение яшьләренең үз лидеры. Яшьләр оешмасы мәдәни чаралар, спорт чаралары үткәрү белән генә чикләнми, фәнни-җитештерү юнәлешендә дә актив катнаша. Конференцияләргә, семинарларга яшьләрне алар әзерли.




■ «ТАНЕКО» нефть эшкәртү заводына 2005 елда нигез салына. Татарстан өчен аның нинди әһәмияткә ия булуын аңлау авыр түгел... Төзелеп бетеп, тулы көченә эшли башлагач, ул елына 14 миллион тонна нефтьне эшкәртәчәк, 18 төрдәге продукция эшләп чыгарачак. Әлегә завод Евро-5 дизель ягулыгы, авиа ягулык һәм җитештерү калдыкларыннан кокс чыгара башлады. (Коксны үз ТЭЦларында ягалар – аларда производство калдыклары юк: бернәрсәне ташларга, күмәргә туры килми.)

■ Түбән Кама шәһәре өчен экология мәсьәләсе бик мөһим. «ТАНЕКО» комплексы төзелешенә 200 млрд. сум акча салынган булса, шуның 27 миллиарды су, җир ресурсларын, атмосфераны саклауга юнәлтелгән. Бу яктан алар белән республиканың бер генә предприятиесе дә тиңләшә алмый!

■ «ТАНЕКО» нефть эшкәртү заводы, дөресрәге, шундый заводларны берләштергән комплекс теләсә кемне шаккаттырырлык. Заманча технологияләр, иң яңа җиһазлар аларда. Үзәк оператор бүлмәсе космик очышларны идарә итүче үзәккә охшаган. Мондагы тәртип, чисталык! Әмма заводның иң зур мактанычы – белгечләр. Әйе, белем, укымышлылык, интеллект кара алтыннан кыйммәтрәк йөри монда.



PRESSA.RU



– Әти-әни канаты астыннан чыккан, тормышка яңа аяк баскан яшьләр, беренче чиратта, социаль яктан яклауга мохтаҗ, – дип сөйли Алия. – Бездә социаль ипотека системасы эшли. Ипотекага фатир алган очракта беренче взносны предприятие үзе түли. Татнефтьнең «барлык фатирларның 30 проценты яшьләргә бирелергә тиеш» дигән карары бар. Узган ел яшьләргә генә «ТАНЕКО»да 54 фатир бирелде. Фатир чиратын зур дип әйтә алмыйм: йөз кеше тирәсе. Аңа басу өчен бер ел эшләү җитә. Чират тиз бара, документларны җыеп тапшыргач, бер ел эчендә фатирлы булу мөмкинлеге бар. Фатирны «рассрочка белән түләп» алу системасы да эшли. Гаиләле яшьләргә өй җиһазлары, кирәк-ярак алырга, ремонт ясатырга дүрт елга 150 меңгә кадәр процентсыз ссуда да бирелә. Яңа өйләнешүчеләргә 12 мең сум күләмендә матди ярдәм күрсәтелә. Бала тугач та, 8 мең сум матди ярдәм ала алалар: гаиләдә игезәкләр туса, бу сумма күпкә арта.

*Эшкә алганда һәркем белән иң элек цех башлыгы, аннан психолог сөйләшә.*

**Өйләнешү дигәннән. Ире дә, хатыны да «ТАНЕКО»да эшләгән, дөресрәге, бер-берсен бирегә килгәч тапкан парлар аларда бик күп.**

– Элек яңа оешкан гаиләләрнең һәрберсен отчет-сайлау җыелышларында игълан итә, котлый идек. Хәзер саннар белән генә әйтеп узабыз, чөнки алар күп, санап чыгып кына булмый.

Ел саен ял базасында үткәрелә торган Яшьләр форумына җитәкчеләр аларны: «Бу юлы кайсыларыгыз форумнан соң башлы-күзле булыр?» – дип елмаеп озата икән. Ике көн дәвамында аралашу, бергә тренинглар узу яшьләрне күпкә якынайтканы берәүгә дә сер түгел. Алия үзе дә булачак ире белән шул форумда танышкан. Алты ел очрашып, дуслашып йөреп, быел җәй кавышкан алар.

«ТАНЕКО» заводы Түбән Камадан ун чакрымнар читтә урнашкан. Әмма без Алия белән шәһәр уртасында, заводның «Яшьләр үзәге»ндә сөйләшеп утырабыз.

– Бу үзәгебез күптән бар инде, – ди Алия. – Көндез буш булганга аптырамагыз, кичләрен ул гөрләп тора. Яшьләр комитетының утырышлары биредә уза. Без тугызау: кемдер фәнни юнәлеш, оешманың интеллектуаль ягы, конференцияләр үткәрү белән шөгыльләнә, кемдер спорт һәм туризм, мәдәни чаралар өчен җаваплы. Бер бүлмәдә репетицияләр үтә: «ТАНЕКО» ел саен үткәрә торган «Талантлар эзлибез» дигән бәйгедә без дә катнашабыз. Инде Яңа ел кичәсенә әзерлек башладык. Моңарчы «Инглиз теле клубы» эшләде – укытучыбыз күчеп киткәнгә күрә генә әлегә туктап торабыз, дәресләр бирергә кеше эзлибез... Атнага бер тапкыр завод ашханәсенең шеф-повары Семен Ткаченко безнең өчен мастер-класс үткәрә. Сүз уңаеннан, пешерергә өйрәнергә егетләр күбрәк йөри... Ә Семен шәһәрдәге иң яхшы аш-су осталарының берсе санала.

**Спорт инвентарьларын шушында саклыйбыз. Спорт чаралары күп үтә бездә!** Мин үзем җиңел атлетика буенча спорт мастерына кандидат, мәктәптә дә, институтта укыганда да спорт белән шөгыльләндем. Әмма имгәнү алганнан соң, кызганыч, туктарга туры килде... Безнең команда «Татнефть» үткәргән Спартакиадада быел беренче урынны алды. Зур җиңү ул! Заводта яшьләр өчен ел саен аерым спартакиада оештырабыз, без күбрәк спортның традицион булмаган төрләре – картинг, бильярд, боулинг, пейнтбол буенча ярышабыз. Социаль акцияләрдә дә катнашабыз: күптән түгел начар күрүче балалар йөрүче бакчага китаплар илттек менә. Ветераннарыбыз белән очрашып торабыз. Заводның өч кешедән генә торган чагы турында сөйләгәннәрен тыңлау барыбызга да шундый кызык...

**«Татнефть» яшьләрне интеллектуаль яктан үстерүгә дә зур әһәмият бирә.** Ел саен бездә инглиз телендә «Брейнг-ринг» уза. Узган ел Яшьләр комитеты «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» уены үткәрә башлады. Быел безнең команда бу уенда «Татнефть»тә беренче урынны алды! (Алия быел яз үзе «Татнефть» командасы составында Мәскәүдә, Беренче язгы интеллектуаль кубокта катнашып кайткан. Милли банк журналы «Нефть һәм газ өлкәсендәге иң интеллектуаль компания»не ачыклаган. Аны «Нәрсә? Кайда? Кайчан?» уенының тере легендасы – Борис Бурда үзе алып барган. Нефть, газ темасына гына түгел, мәдәният, спорт һәм тарихка кагылышлы сораулар яңгыраган анда. «Татар теленнән таш «камень» дип тәрҗемә ителә, ә бака – «лягушка». Бу ике сүзне кушып, хайван исемен атагыз» дигән сорау безнекеләр өчен иң җиңеле булган, әлбәттә. Өченче урынны алып кайтканнар!)

**«Яшьләргә хәзер берни кирәкми, диләр. Тик бу сүзләр безнең хакта түгел!»** – ди Алия.

Шундый зур яшьләр оешмасын җитәкләү бер яктан – дәрәҗә, икенче яктан – зур җаваплылык. Ул эшче яшьләр, белгечләр белән дә, җитәкчеләр белән дә уртак тел табып эшли белергә тиеш. Арадашчы дисәң дә була аны. Нинди генә проблемалары булса да, яшьләр иң элек аңа килә, аның белән уртаклаша. «ТАНЕКО»ның генераль директоры Леонид Степанович Алехин яшьләр лидерын еш кабул итә: яңа идеяләрен тыңлый, кирәк җирдә ярдәм итә, булыша. «Генераль директор урынбасары Илшат Сәлахов, профсоюз җитәкчесе Гөлнара Мөҗипова, «Татнефть» кадрлар бүлеге башлыгы урынбасары Ренат Мамин (алар барысы да элегрәк «ТАНЕКО»да яшьләр оешмасы лидеры булган кешеләр! – *Г. Х.* ) нинди генә сорау белән мөрәҗәгать итсәм дә, кире борганнары юк. Ярдәм кулы сузып, хуплап торучылар барында нигә эшләмәскә?!» – ди Алия Истомина.

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

## ҖӘМГЫЯТЬ



■ Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов АКШка визиты кысаларында Америка төрки-татар җәмгыяте вәкилләре белән очрашты. Берлингейм шәһәрендәге (Калифорния штаты) Татар йорты залында үткән очрашуга 50 гә якын кеше килгән иде. «Сезнең мәдәниятка һәм гореф-гадәтләргә карата мөнәсәбәтегез безнең өчен үрнәк булып тора», – дип, Татарстан лидеры диаспора вәкилләренә рәхмәтен җиткерде.

■ «РИА-Рейтинг» экспертлары әзерләгән Россиянең технологик үсеш алган һәм фәнни потенциалга ия төбәкләре исемлегендә Татарстан, Мәскәү һәм Санкт-Петербургтан кала, өченче урынны били. Рейтинг 19 күрсәткеч буенча төзелгән: кеше ресурслары (галимнәр саны һәм аларның яше), матди-техник база – фәнни җиһаз күләме һәм сыйфаты, фәнни-техник эшчәнлек нәтиҗәлелеге – бирелгән патентлар саны һәм инновацион товарлар күләме һәм башкалар исәпкә алынган.

## МӘГАРИФ

■ Тиздән мәктәп расписаниесендә яңа фән – җәмгыятькә файдалы хезмәт дәресе булачак. Балалар мәктәп яны кишәрлегендә эшләргә, класс бүлмәләрен җыештырырга, авыл хуҗалыгы эшләрендә катнашырга тиеш булалар. Федерация Советында һәм Татарстан парламентында әлеге идея бертавыштан хуплау тапты.

■ Казанда студентларны эшче һөнәрләренә өйрәтә башладылар. Берничә ай дәвамында 150 яшь кеше үзенә һөнәр үзләштерә алачак. Аларны штукатур-буяучы, электромонтажчы, арматурачы, бетончы, ташчы һөнәрләренә укытачаклар.

■ Мәскәүдә татар теле өйрәнергә теләүчеләр өчен курслар оештырылды. Дәресләр татар мәдәни үзәгендә уза. Татар теле курслары Дагстан татарлары өчен дә ачылды. Әлеге курсларга йөрү бушлай, яшь ягыннан чикләүләр юк. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы дәреслекләр белән тәэмин итә.

## КОТЛЫЙБЫЗ



■ Казан шәһәренең Яңа Савин районындагы 380 нче балалар бакчасы тәрбиячесе Гүзәл Мөхәммәтҗанова «Россиянең ел тәрбиячесе» бәйгесенең региональ этабында җиңүче булды. Ул Санкт-Петербургта узачак финал чараларында тагын 150 тәрбияче арасында үзен сынаячак.

## СПОРТ



■ Франциянең Жуэ-Ле-Тур шәһәрендә Татарстан җыелма командасы теннисчысы Екатерина Яшина халыкара турнирның парлы разряды финалисты булып, көмеш медаль яулады.

■ 2018 елда 14 июньнән 15 июльгә кадәр узачак футбол буенча Дөнья чемпионатының талисманы Забивака кушаматлы бүре булачак. Ул гомумроссия тавыш бирү юлы белән сайлап алынды.

■ Казанда Татарстан һәм Чехиянең хоккей буенча ветераннар җыелма командалары арасында узган матч 5:2 исәбе белән боз хуҗалары файдасына тәгәлләнде.
ТР командасы капитаны Рөстәм Миңнеханов чехлар капкасына өч алка кертте. Республика җыелма командасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Казан мэры Илсур Метшин, «Ак барс»ның легендар хоккейчылары Морозов, Чупин, Якубов, Зиновьевлар бар иде.



## МӘДӘНИЯТ

■ Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Үзгәреш җиле» фестивале ярдәмендә татар җырының абруен үстерү, милли эстраданы яңа дәрәҗәгә күтәрү идеясен тәкъдим иткән иде. М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында фестиваль аншлаг белән үтте. Заманча аранжировкада 29 татар композициясе башкарылды. Салих Сәйдәшев, Рөстәм Яхин, Җәүдәт Фәйзи җырлары яңача яңгыраш тапты.

■ Әлмәттә Саҗидә Сөләйманова исемендәге премияләрне тапшыру тантанасы узды. Әлфия Хаҗиәхмәтова («Тансык бәхет» һәм «Хәтер җебе» китаплары), Борис Вайнер (балалар өчен шигырьләр җыентыгы), Халисә Ширмән («Ерактагы йолдызым» җыентыгы) быелгы лауреатлар булдылар. Воткинскидан Гөлфия Исхакова; Түбән Камадан Рифкат Имаев; Казаннан Лениза Вәлиева «кызыксындыру бүләге»нә лаек булдылар.

■ Казан Кремленең «Манеж» Күргәзмәләр залында «Тукайга сәяхәт» күргәзмәсе ачылды. Үзенчәлекле экспонатлар арасында шагыйрьнең үз куллары белән язылган алты бит, берничә сирәк фотографиясе, шагыйрьнең кара савыты, түбәтәе, үрелгән юл кәрзине урын алган. Анна Ахматованың Тукай шигырьләрен русчага тәрҗемә иткән кульязмалары шулай ук игътибарга лаек.

PRESSA.RU












# «ШӘМСИЯ ЧИШМӘСЕ»

## ӨСТЕНӘ ИЕЛГӘН ЗИРЕК АГАЧЛАРЫНЫҢ – ЗИРЕК АЛКАЛАРЫНЫҢ ҖЫРЫН ТЫҢЛЫЙ-ТЫҢЛЫЙ АГЫП ЯТУЧЫ БУ ЧИШМӘ НИЛӘР ТУРЫНДА СӨЙЛИ ИКӘН?



**Ана батырлыгы, ана мәрхәмәте, ана шәфкате турындамы? Әллә бала игелеге, олы җанлылыгы, аның яратуы, сагынуы, юксынулары хакындамы?**

Жәйгә чыксак, Казан–Оренбург юлына тузан кунмый бугай хәзер. Күпләр Тоз-Түбәне, аның шифалы күлләрен үз итте: сихәт алып, ял итеп кайтырга бара. Оренбург өлкәсенең Пономаревка районына караган Нәүрүз авылы нәкъ шушы олы юл өстендә урнашкан. Меңгә якын хуҗалыгы булган зур татар авылы ул. Озын юлдан арган күпләрнең биредә туктап хәл җыйганы да бардыр. Мин сөйләячәк чишмә исә шушы авылдан аз гына арырак, буш нигезләре генә калган татар авыллары – Нариман белән Шәфикинга бара торган юл читендә. Сезгә аны табу авыр булмас. «Шәмсия чишмәсенә ничек барасы икән?» – дисәгез, юлны һәркем күрсәтер. «Анага куелган һәйкәлгәме?» – диярләр, оныткан булсагыз, тарихын да сөйләп бирерләр әле.

...Бу вакыйгага инде алтмыш елдан артык вакыт узган. Көзнең, кояш чыкса да, инде җылытмаган, кышка авыша төшкән соңгы көннәренең берсе була. Төшкә ялга кайткан Шәмсия, ниһаять, буш вакыт табылудан файдаланып, абзар сыларга керешә. Аяк астында дүрт яшьлек улы да бөтерелә: туганнарының үзе яшендәге малае белән нидер уйныйлар. Берара балаларның тавышы тынуга игътибар итеп, Шәмсия артка борыла. Малайларның берсе шунда – бакчада, ә икенчесе... «Галимулла кайда?» – дип сорый эченә шом кергән Шәмсия. Улының иптәше коега таба ымлый...

Баласы артыннан шунда ук коега ташлана әни кеше. Унике метр тирәнлектәге кое була ул. Ананың ачыргаланган тавышына тирә-күрше җыела. Башта әнисе кое чиләгенә салган Галимулланы тартып алалар, аннары әллә салкын суга чумудан, әллә куркуыннан калтыранган хатынны. Малай бик тиз аңга килә – йоткан суы чыга: киезгә төренеп ярты сәгать кенә ятып тора да, кабат иптәшләре янына, урамга йөгерә. Ә фермага, сыер саварга ел әйләнәсе резин итекләрдән йөреп инде болай да саулыгын җуйган әнисенә яңа чирләр генә өстәлә. Тагын бер елдан биш баласын ятим итеп дөньялардан китеп тә бара ул. Нибары 44 яшьтә!

Авылдашлары өчен бик озак вакытлар «Шәмсиянең коега төшкән улы» булган Галимулла абый бүген мәрхүм әнисеннән нәкъ чирек гасырга олырак инде. Еллар күз алдыннан әнисенең сурәтен дә күптән җуйган.

– Аннан безгә үги әни килде, – дип сөйли ул. – Юк, юк, начар булмады Мөнирә әниебез. Тик Ходай берәүгә дә үги бала карарга язмасын: кем тапкан – шул үстерсен. Бер кесә бодай өчен төрмәгә утырткан булганнар аны: авырлыкны күп күргән. Башкалар әйберенә кагылмаска, хәләл көч белән яшәргә өйрәтеп үстерде ул безне. Егет булып җиткәч: «Улым, кеше баласының күз яшен ала күрмә, күз яше, рәнҗеш берәүне дә бәхетле итми», – дип кабатлады. Үги дип әйтә дә алмыйм мин аны... 91 яшькәчә безнең тәрбиядә булды, соңгы юлына да Нуридә апаң белән зурлап үзебез озаттык.

Зиратта алар өчесе янәшә: әтиләренең бер ягында Шәмсия әниләре, икенче ягында – Мөнирә әниләре. Балалары күңелендә дә урыннары шулай рәттән.

Югары белем алып туган авылына өлкән агроном булып эшкә кайткан Галине 28 (!) яшендә районның иң артта калган колхозын – «Красный партизан»ны күтәрергә җибәрәләр. Әтисе – авылдашларына йөз илледән артык йорт салып биргән балта остасы Габдулла агай яңа эшенә озатыр алдыннан: «Улым, син анда зур кеше – рәис булып барасың. Синең күзләрең – икәү, халыкныкы – мең. Һәр адымыңны күрәчәкләр, күзәтәчәкләр. Үзең турында гына түгел, безнең хакта, балаларың турында да уйла. Исемеңне бер пычратсаң, сөт белән юсаң да агармый ул», – ди.

Галимулла Хөснуллин эшен... зират тирәләрен тотудан башлый. Җитәкчелек ул чакта аның бу адымын бик аңлап, хуплап та бетерми, ә халык... Халык исә аңа бүген, кырык елдан соң да рәхмәт укый. Бигрәк тә кешесе калмаган ташландык Метеор бистәсенең зираты өчен. Каберлек тирәли утырткан имәннәр, каеннар, миләшләр урман булып күтәрелгәннәр инде хәзер.

## *Батырлыгыңа дан җырлап, Челтери чишмәң, Шәмсия.*

Колхозны өч ел эчендә алдынгылар рәтенә чыгара ул. Аннан икенче хуҗалыкны – «Большевик»ны күтәрергә алына. Иң беренче эш көнендә үк авылның өлкәннәрен – аксакалларны җыя. Алга таба ничек яшәргә, бу баткаклыктан ничек чыгарга – алар белән киңәшә. Киңәшле эш таркалмас, диләр! Бер ел эчендә ике катлы мәктәп салдыра. Төзелештә бөтен авыл катнаша. Гади халык белән уртак тел таба белә Гали, тик менә җитәкчеләр белән... Урып-җыюын төгәлләгән рәиснең комбайннарын икенче колхозга алмакчы булалар. Ә аның әле печән кибәннәрен ферма янына кайтартасы бар. Кыскасы, кешеләрен дә, техникасын да бирми ул. Тыңламый... «Үз теләгем белән китәм» дигән гариза яздырталар. Башбирмәс рәисне беркая эшкә алмаска кушыла. Хәтта мичкә ягучы итеп тә...

– Авыр булды, ләкин намусың чиста икән – сынмыйсың, – ди ул. – Халык каршында гаебем юк иде бит. Берәү дә: «Бер татар килде дә, хуҗалыкны таркатып, бүлдереп китте», – димәде. Колхоз кесәсе белән үземнекен бутамадым!

Авылдашларын – 14 гаиләне җыеп фермер хуҗалыгы төзи ул. Буш җирдән башлыйлар. Иген игәләр, мал тоталар, шайтан таяклары үскән кырда иген амбарлары коралар... Инде һәркайсы аерымаерым үз юлы белән киткәнгә дә берничә ел. Фермер Галимулла Хөснуллин бүген 1200-1500 гектар җирдә иген үстерә, 150-200 баш эре мөгезле мал тота,

PRESSA.RU



250-300 баш сарык үрчетә, 170-200 оя бал кортлары карый. Аның кул астында 8-10 кеше эшли.

– Миңа бер генә түгел, ике тапкыр гомер бүләк иткән кадерле кешем – әнием алдында үземне гел бурычлы санап яшәдем. Аның истәлегенә ниндидер матур бер эш эшлисе килү хыялы күңелдә күптән йөрде. Ниһаять, ул вакыт җитте менә. Эшләр җайга салынды. Өч кызыбызны да үстердек, укыттык, югары белем бирдек. Туйларын ясадык, фатирлы иттек...

Далалы Оренбург якларында чишмәләр бик кадерле. Галимулла абый көтүчеләрдән сораша: «Ташландык берәр чишмә белмисезме?» – ди. Табыла андый чишмә!

– Шундый матур җирдә булып чыкты ул! Тау бите, аста чишмә ага... Озак кына янында карап басып тордым – күз алдымда суы күбәя кебек тоелды...

## *Ял итү өчен моннан да матур урынны тагын кайда табасың!*

Аннан инде эшкә тотына. Чишмә үзе генә түгел, аның бөтен тирә-юне үзгәрә! Чишмәгә төшә торган юлның ике ягына, тау битенә – җиде гектар җиргә 50 мең нарат утырталар, 300 төп яшел чыршы, 50-60 төп зәңгәр чыршы. Тагын юкәләр, каеннар... Барысы да уң килеп тора: агач үсентеләре белән беркадәр ярдәм итүче дә табыла, халык та өмәгә теләп чыга, чыршыларны утыртканның икенче көненә бик әйбәт яңгыр да явып китә. Берничә ел узар да, монда инде урман булыр! Барысы да аның хыялындагыча: «Ананың батырлыгын хәтерләтү өчен төзекләндерелгән Шәмсия чишмәсе» дигән язу да, аның кырыендагы зәңгәр чыршылар да (бер якта ике чыршы – анысы әтисе белән әнисе, икенче якта бишәү – биш бала, биш туган), роза гөлләре... Волейбол уйнар өчен урын, ял итәр өчен дистәгә якын чатыр, бәйрәмнәр үткәрү өчен сәхнә, чишмә өстендә кечкенә күпер... Кечкенә генә җил тегермәне әйләнеп тора, ләкләк «оя корган»... Чишмәдән аз гына астарак күл, анда хәзер балыклар йөзә. Тукай әкиятләре геройлары – монысы да булачак! Чишмә өстенә татар хатын-кызының баш киемен хәтерләткән чатыр корылачак.

– Галимулла һәрвакыт алдан берьеллык план төзеп куя. Аны безгә кычкырып укый, – ди җәмәгате Нуридә апа. – «Быел язмастыр инде», – дип торасың, ә ул аны тагын төзегән!

Чишмәне Рамазан аенда, Коръән укытып, авыз ачтыру мәҗлесе оештырып ачалар. Җәйләрен «Шәмсия чишмәсе» яныннан кеше өзелми хәзер, диләр.

– Дүшәмбе иртән иртүк чишмәгә барам. Халык үзе артыннан җыештырырга өйрәнде инде, анысына сүз юк. Соңга калсаң, чүп чиләкләрен каргалар бушата, шуңа ашыгам. Чишмәгә башка вакытта да еш йөрим. Әнинең хәлен белергә барган кебек тоям үземне... Бик моңлы бу чишмә...

Шагыйрә Шәмсия Җиһангированың әлеге чишмәгә багышлап язган «Шәмсия чишмәсе» дигән җырын тәкъдир итү узган ел – Оренбург өлкәсендә VI Федераль авыл Сабан туе алдыннан авыл Мәдәният йортында узды. Ул көнне фермер, танылган умартачы Галимулла абый Хөснуллинның тагын бер хыялы чынга ашты: Нәүрүздә бал кортына һәйкәл куелды. Россиядә беренче һәйкәл! Бал кортына гына түгел, Нәүрүзнең уҗәт, тырыш, булдыклы халкына да һәйкәл кебек ул...

...Бу якларга юл чыксагыз, Нәүрүздә тукталмыйча узмагыз! Әйткәнемчә, «Шәмсия чишмәсе» авылга бик якын ул – барып күрегез. «Иелеп суын эч әле / Шәмсия чишмәсенең, / Җаның пакьлек, сафлык алыр, / Тәнеңнән китәр чиреӊ», – диелә җырда. Бу юлларда хаклык, һичшиксез, бар! Бабасы матурлаган чишмә янына бер баруында Галимулла абыйның биш оныгының олысы Кәрим әнисенә: «Мин дә үскәч сиңа һәйкәл салырмын, әнием, яме!» – дигән. «Шәмсия чишмәсе» яныннан кузгалганда сезнең балаларның күңелендә нинди уй бөреләнүе дә Ходайга гына мәгълүм...

Гөлнур САФИУЛЛИНА




Хөрмәтле укучыларыбыз!

Мондый тарихлар сездә дә күптер инде: кемнәрдер әниләре хөрмәтенә чишмәләр ача, арада мәчетләр салдыручылар бар, әниләре исемен кушып, аның рухына башка-башка изге гамәлләр кылалар. Әнә шулай тирә-юньдәгеләрне сөендереп яшиләр. Мәсәлән, безнең редакция хезмәткәре Сөмбел Гаффарова да вафат әнисе исемен шулай мәңгеләштерде. «Сөембикә» журналы сайтына әнә шулар турындагы язмаларыгызны юллагыз. Алар яңа елдан «Әнием рухына» дигән сәхифәдә чыга башлаячак. Хатларның иң матурлары журнал битләрендә урын алачак.

«Әнием рухына» килгән язмаларга 2017 елның ноябрендә – Әниләр көнендә йомгак ясалыр.

# ГОМЕРЛӘРДӘН ОЗЫН МӘХӘББӘТ...

«Сөембикә» журналының 7-8 нче саннарында Гөлнур Сафиуллинаның «Яратып туймыйча китәбез» язмасы беркемне дә битараф калдырмагандыр. Язма чынбарлыкка нигезләнеп язылган, бернинди дә уйдырмалар юк. Гаҗәеп тарихка, сокландыргыч язмышка ия булган кешеләр турында үзләре мәңгелеккә арабыздан киткәч кенә беләбез шул. Язманың ике каһарманы да мәгариф һәм мәдәниятебез тарихында лаеклы урын алган кешеләр. Берсе – Башкортстанның халык шагыйре Әнгам Атнабаев, икенчесе – әдәбият галиме, язучы, күренекле мөгаллим Гөлчәчәк Әдһәмова.

Язманы укып чыккач, үземне студент чакларыма кайткандай хис иттем. 60 нчы еллар ахырында Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында Башкортстанда яшәүче татар шагыйре Әнгам Атнабаев белән очрашу булды. Без – студент халкы бу клубта үтә торган «Әдәби җомга»ларның берсен дә калдырмаска тырыша идек. Очрашуда кеше бик күп, шагыйрьнең Казан педагогика институтында укыган сабакташлары да шактый иде. Кичә гөрләп үтте. Кунагыбыз шигырьләрен дә рәхәтләнеп сөйләде, күпсанлы сорауларга да җавап бирде. Шул очрашудан соң безнең сөйләмебезгә афоризм буларак «Өч мөештән тора бу дөнья: үзең яратмаган сине сөя, син яраткан – сине яратмый» юллары кереп урнашты. Бераздан, өермә булып, «Саз» ансамбле башкаруында «Җиз кыңгырау моңнары» (В. Хәбисламов музыкасы) җыры килеп керде. Хәзер уйлыйм: бу җыр шагыйрьнең һәрвакыт мәхәббәте янына ашкынган күңел халәтен чагылдырган икән. Авторның Н. Сабитов музыкасына язылган «Ал яулык», «Язлар булса» җырлары да халык арасында киң таралыш тапты.

Мин үзем университетта укыганда Гәүһәр Камалова җитәкләгән татар театр түгәрәгенә йөрдем. Без анда бик яратып һәм шактый озак Ә. Атнабаевның «Ул кайтты» драмасын куйдык, гастрольләргә дә чыгып кердек хәтта. 80 нче елларда Казанга Уфаның М. Гафури исемендәге драма театры гастрольгә килде. Халык бик яратып йөрде аның спектакльләренә, аеруча «Галия»гә. Бу спектакльдә Ф. Гафаров һәм Н. Ирсаеваларның «Заһир белән Галия җыры» (Р. Хәсәнов көе) Казанны «яулап алды». Ә. Атнабаев иҗат иткән җыр сүзләре һәркемнең күңел түренә кереп урнашты:

Ә мәхәббәт гомерләрдән озын,
Мәңге яна, мәңге җырлана.

Ә Гөлчәчәк апа Әдһәмова белән мин Казанның 35 нче мәктәбенә эшкә килгәч таныштым. Ул чакта бу мәктәптә Милли мәктәпләр институтының филиалы эшли иде. Институт хезмәткәрләре, тел һәм әдәбият галимнәре монда фәнни-методик тикшеренүләр алып баралар: укытучылар һәм студентларга методиканы үзләштерү алымнарын өйрәтәләр, укытучыларның дәресләренә йөриләр. Алар һәр дәресне бөтен яктан анализлыйлар: уңай якларын да, җитешсезлекләрен дә күрсәтәләр. Гөлчәчәк Мирзаһитовна әдәбият дәресләрен өйрәтә иде. Ул кырыс күренә, тавышы да көр, сорауларын да уйлап бирә, җавапны да төгәл таләп итә. Без, дәрескә ул керәсе булса, куркып тора идек. Әдәбият фәне, аны укыту методикасы буенча күп нәрсәләр өйрәндек без аңардан. Галимнең күпсанлы методик ярдәмлек китаплары да һәр укытучының өстәлендә булды. Аның белән һәр очрашу безнең белемебезне арттыра, күңелебезне баета. Ул әдәбият-сәнгатьнең һәр яңалыгыннан хәбәрдар, сумкасы тулы яңа чыккан газета-журналлар була торган иде.

Гөлчәчәк апа белән хезмәттәшлегем 68 нче мәктәпкә күчкәч тә дәвам итте. Бу вакытта ул Казан педагогика көллиятендә әдәбият методикасын укыта иде. Безнең мәктәптә студентларның педагогик практикалары белән җитәкчелек итте. Шәкертләренә таләпчән дә, шул ук вакытта мәрхәмәтле укытучы да, үз өлкәсен яхшы белүче галим булып та кала алды. Шуңа күрә аның көллияттә дә абруе зур иде: олысы да, кечесе дә хөрмәт итте. Көллияттә аның түгәрәк гомер бәйрәмнәрен, эшчәнлегенә багышлап фәнни-методик конференцияләр үткәрделәр. Кайберләрендә миңа да катнашырга туры килде. Практикага килгән студентларын озаткач, без Гөлчәчәк апа белән сөйләшеп утырырга ярата идек. Шундый сөйләшүләрдә Әнгам Атнабаев белән булган мәхәббәт тарихларына да тукталып киткәли, мин исә сорау бирмичә генә тыңлыйм: әгәр сорау бирсәм, ачуланыр дип курка идем. Бервакыт аның килүенә Ә. Атнабаевның шигырьләр җыентыгын әзерләп куйдым һәм аңа бүләк тә иттем. Шул вакыт ул миңа үзендә Атнабайның (ул аны «Атнабай» дип йөртә иде) шактый гына хатлары саклануы, аның гаиләсе белән аралашып яшәве турында әйтте. Мин Гөлчәчәк апага китап язарга киңәш иттем. Атнабайны Сездән дә күп белгән кеше юктыр дигән фикеремне белдердем. Ниһаять, ул тотынды. Телефоннан эшнең ни дәрәҗәдә баруын да хәбәр итә торды. Аны китапны чыгару мәсьәләсе борчый иде. Чөнки гомер бара, исән чакта күреп өлгерерме? Беркөнне дулкынланып китабын тәмамлавы, ләкин әле бастыру-бастырмау эшләренең ачык булмавын белдерде. 2007 елның декабрендә ул мәктәпкә килде һәм миңа култамгасы белән «Язмыш кыравы» исемле китабын бүләк итте. «Язып өлгерә алмам дип ашыктым, күп нәрсәләр әйтелмичә калды», – диде ул. Миңа язган култамгасында шундый юллар бар: «Мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьлегә!.. *(Г. Т.)* – фәнмәгърифәт өлкәсендә зур хезмәт күрсәткән Наҗиягә!» Бу – аның миңа бүләк иткән икенче әдәби китабы. Автор миңа 1987 елда Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Үкенечкә калмасын» китабын да бүләк иткән иде.

«Язмыш кыравы» китабы өчен авторның Казан педагогика көллиятенә һәм аның директоры А. Җәләловага рәхмәте чиксез зур булды. Китап бары тик 100 данә генә чыкса да, Гөлчәчәк апа Әдһәмова үз теләгенә иреште, әйтәсе сүзләрен дөньялыкта әйтеп калдыра алды, Мәхәббәт дигән «бер ялкыны дөнья балкытырлык» олы хиснең чыннан да гомерләрдән озын булуына күпләрне ышандырды.

Наҗия ГЫЙМАДИЕВА.
Казан.

PRESSA.RU



# АРТИСТКА АЛСУ

Асия ЮНЫСОВА

ГАБДУЛЛА КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ЯШЬЛӘР ТЕАТРЫ 30 ЯШЕН ТУТЫРЫП КИЛӘ. АНЫҢ ПРИМАСЫ – АРТИСТКА АЛСУ ШӘМСЕТДИНОВА-ФӘЙЗУЛЛИНА ТЕАТРНЫҢ ЯШЬТӘШЕ ДИСӘҢ ДӘ ЯРЫЙ, БЕР ЕЛДАН БАРЫБЕР ТУЛА БИТ ИНДЕ УЛ 30...

***Һай, матур кыз икән!***

Алма битле бәләкәй оныгын Якуб бабасы тезләрендә сикертә-сикертә такмаклый:

Һай, матур кыз икән,
Кемгә бирербез икән?
Уңган микән егете,
Кемдә икән өмете?

Кызчык чырык-чырык көлә. «Егете», «өмете» дигәннәрне аңламый әле ул. Хәер, җырның ертыгы юк. Алсуга бабасының очындырып сикертүе, дәү әнисе Мәдинәнең чәбәкәй итеп торуы – игътибар үзәгендә булу кызык. Олы Ачасырдан Яшел Үзәнгә кайткач, әти белән әни янында да кичке концертлар булып тора. Инде хәзер әтисе Фәнис гармун уйнаганда әнисе Розалия кушылып җырлый, җырлап арыгач, Алсуны биетәләр. Тагын такмак, тагын чәбәкәй! Алсуның беренче «сәхнәсе» – бабай тезләре, беренче алкышлары – чәбәкәйләр. Бабай белән дәү әни оныкның һәр кыланмышыннан сөенеч алып утырсалар, әнисе күңелендә, мөгаен, чынга ашмый калган хыяллары кымырҗып куя булгандыр. Саннар гармониясенең серен белгән Розалия дә, бәлки, сәхнәгә күтәрелә алган булыр иде дә бит... Һәр җырлый белгән кеше дә артистка булып китә алмый шул. Ә менә кызына юл ачарга тырышыр ул. Аның кызын хөрмәтләп, «Алсу Фәнисевна» дип кенә дәшәрләр.

Әни кеше иң дөрес юлны сайлый. Ике мәктәп яныннан узып китеп, өченчесенә – татар мәктәбенә җәяүләп, озаклап барганда бәләкәй Алсуның карышырга азапланганын алар бүген дә кызык итеп искә алалар. Дөрес, хәзер инде Алсу әти-әнисенә моның өчен бик рәхмәтле. «Рус телле талантлар байтак ул. Татар баласына кеше булу өчен иң туры юл, барыбер дә татар теле аша», – Алсу бу шигарь кебек сүзләрне миңа ошар өчен генә

әйтми. Ире Фәнил белән уллары Әмирханны нәкъ шундый – милли нигезләрдә тәрбиялиләр алар. Әмирханның «кичке китабы» Габдулла Тукай шигырьләре. «Су анасы», «Шүрәле»ләр өйдәге «Тукай сәгате»нең төп каһарманнары.

Кая ашыгам. Әле бит Алсуны Казан сәхнәсенә менәрлек итеп үстереп бетерәсе бар. Әйе, Розалия ханым кызларын тәрбияләү җәһәтеннән (Алсуның әле Дилә исемле сеңлесе дә бар) бер дә японнардан калышмый. Баланың чигү чигәсе киләме – чиксен. Рәсем ясарга яратамы – ясасын, музыкамы – рәхим итсен. Бернинди чикләү, тыю юк. Алсу хәтта спорт гимнастикасы белән дә мавыгып ала. Аннары, – бәхеткәдер бу! – Яшел Үзән шәһәрендә Балалар сәнгать мәктәбе ачыла. Алсу янә бөтен шәһәр аша җәяүләп шул мәктәпкә йөри башлый. «Артист булу иде хыялым. Бу мәктәп мине шул хыялыма якынайтты. Унберенче сыйныфтан соң Казан музыка училищесына килеп эләгүем бик тә табигый килеп чыкты, – дип сөйли Алсу. Аннары мин – дипломлы вокал укытучысы», – дип өстәп куя.

Укытучылары кем соң? Рәисә Закирова, танылган хормейстер Венера Гәрәева, бөтен татар эстрадасы өчен бер ялгызы җаваплы сыман эшләүче фидакарь Клара Хәйретдинова. Менә шул остазлар сине өйрәтергә, тавышыңны куярга кѳтеп утырганда авырдым дип тә, арыдым дип тә дәрес калдырырга ярамый торгандыр шул ул. Клара Әкрам кызы – кырыс укытучы. Аның мәктәбе чыныктыра торган мәктәп! «Унбиш кенә минутка булса да кил. Мин сине ишетергә тиеш!» – ди ул. Шуңа күрә чибәр кызыкай Яшел Үзән белән Казан арасында йөреп тора. Таш яуса да! Көн дә! Ике сәгать бара, ике сәгать кайта. «Электричкадамы?» – дим, куркуымны йөземә чыгарып. Чөнки ярым буш вагоннарда Алсу кебек үзе яшь, үзе чибәр кызларга бәйләнүчеләр табылып торганын беләм. Ә Алсу 18 яшенә зөбәрҗәт күзләреннән яшел очкыннар чәчеп торган матур да, зифа да кыз булып өлгергәндер. Андый кызларга белем эстәү юлында исән-сау калулары бик читен. «Юк. Мин автобуста йөрдем, – ди ул, минем соңарып борчылуыма гаҗәпләнә төшеп. – Шөкер, мине Ходай саклады. Аннары күп вакыт Фәнил озата кайта иде. Ул да музыка училищесында минем белән бергә, Венера Гәрәева классында укыды. «Татар халык көйләре» дигән бүлектә укыдык без». (Фәнил – Теләчедән. Димәк, кай көннәрдә Теләчегә юл Яшел Үзән аша булган икән. Мәхәббәт географик шартлылыкларны белми шул – аның үз юлы.)

Тавышы куелган Алсу Шәмсетдинованың ярты юлда гына тукталып калуын теләми Клара ханым: «Сиңа укырга кирәк. Алда – консерватория!» Югыйсә театр артисткасы булыр өчен училищеда дүрт ел алган белеме дә җиткән булыр иде. Хәер, алай дисәң, кыз бит әле театр җәһәтеннән белемсез калды. Казан консерваториясендә әле кайчан гына «Татар халык көйләре» бүлеге бар иде. Алсу Шәмсетдинова – шул бүлек әзерләгән соңгы кадр! Шулай итеп, кызыкай тугыз ел дәвамында Клара Хәйретдиновада укый.

Сез аны шул белеменнән башы әйләнеп калгандыр дисезме? Кая ул! Дүртенче курста укыганда ул параллель рәвештә Казан химия-технология университетына укырга керә. Түләүлегә. Социаль хезмәткәр, педагог, психолог дигән белгечлекләргә ия булу өчен. Инде язып утырганда уйланам. Консерваториядә татар бүлеге, пединститутта музфак ябылу, сәнгати белем бирүдәге артка чигенешләр аны запас һөнәрләр үзләштерергә этәргәнме икән әллә? Югыйсә аның үзеннән дә бер дигән музыка остазы чыга алган булыр иде.

### *Максатлының юлы бар*

Яңа ел алдыннан Венера Хәсән кызы Гәрәева шалтырата: «Алсу, Яшьләр театрының баш режиссеры Ринат Әюпов җырчы артистларга кастинг үткәрә. Тәвәккәлләмисеңме? Фәнил Фәйзуллин белән дуэт әзерләгез әле. «Хәлил белән Галиябану»ны. Шәп килеп чыгарга тиеш. Ишеткән, ишеткән Венера ханым ике яшь йөрәкнең «дуэтын». «Венера Хәсәновна икенче әнием кебек иде миңа. Ничек инде аның сүзен тыңламыйсың? Киттек Фәнил белән. Бер ай үтте микән, юк микән, Камал театры янынннан автобуста узып барам. Ринат Мирзахәсәнович шалтырата: «Икегезне дә театрга чакырабыз». Фәнил ул вакытта ирем булган иде инде. Ул Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә солист булып китте. Мин Кариев исемендәге Яшьләр театрына килдем. 2009 ел иде бу».

*Театрда сигезенче сезонын башлады Алсу Шәмсетдинова-Фәйзуллина.*

Җырчы кыз үз алдына театр училищесын узганнар дүрт елда өйрәнгәнне ярты елда отып алырга дигән максат куя. («Чынында, аңа бер спектакль җитте, – Ринат Әюпов шулай ди. – Өч диплом янына дүртенчесе кирәкми иде инде аңа».) Кайда – мизансцена, кайда – анфас? Режиссер ымын укый белү генә дә аз. Үзеңнән пластилин ясарга, холкыңны тыярга, партнерыңны тоярга кирәк. Ягъни артист ул син түгел, режиссер сине кем итеп күрсә, шул! Әверелеш кануннары белән яши сәхнә. Әверелә белсәң генә ул сине озакка калдыра. Әйтик, «Гашыйклар утравы»н куйганда режиссер тыйнак Алсудан бераз чытлыклану көтә. Ничек итеп икәнен артистка үзе белергә тиеш. «Изүеңне ача төш», – дияр иде, алай да килешмәс. Ни киңәш итәргә, дип торганда, Алсу хәйләсен үзе таба – матур гына, килешле генә итеп, көлмәк итәген җилфердәтеп, челтәрле балакларын күрсәтеп ала. Кечкенә генә бер деталь, әмма образ ачылып китәргә шул да җитә. Режиссер канәгать.

Репертуардагы спектакльләргә беренче көннән үк кереп киткән яшь артисткага нечкәреп, үз хисләрен анализлап торырга җай булмый.

PRESSA.RU

Кичәге прималар аңардан ялгыш адымнар көтә. «Әллә гомер буе беренче булырмын дисеңме? Дубльгә каласы көннәрең алда әле», дип зәһәрләнеп тә, «Алсу, күр дә тор – онытырлар» дип, дусларча кыланып та пышылдап кала чаршаучыбылдыклар. Пышын-чышыннарны тыңларга вакыты юк Алсуның. Рольләре бөтен барлыгыңны йота торган рольләр: Галиябану («Галиябану»), Сәрвәр («Башмагым»), Зәйтүнә («Зәйтүнәкәй»), Сандугач («Әйт әле, Күбәләк»), Җырбикә («Җиде кыз»)... Барысы да җырлы рольләр. Кайсы театрда бар тагын консерватория белемле артистка! Мондый артистлар булганда башкаланда музыкаль театр ачып җибәрергә дә була! Казан кай шәһәрдән ким әле ул!

*Менә бит ул Тукай Зәйтүнәсе! Үзе яшь, үзе чибәр, үзе кыю, үзе сандугач тавышлы җырчы.*

«Җиде кыз»да (Нәкый Исәнбәт әсәре) уналты җыр җырларга кирәк Алсуга. Тулы бер концерт кадәр бит бу. («Мин ул вакытта җиде айлык авырлы идем әле, җитмәсә»). Халык бу спектакльгә Алсуның чишмәдәй челтер тавышын, тирән аһәңле авазларын тыңларга дип тә килә. Бу тавышы белән Алсу, әлбәттә, җырчы булып киткән суреттә дә югалмас иде. «Зәйтүнәкәй» спектаклендәге Зәйтүнә җырын мин, гомумән, ария сыман кабул иткән идем. «Шагыйрь мәхәббәте» (Резеда Ахиярова музыкасы) операсында Зәйтүнә партиясен җырлау өчен Уфадан җырчы чакырып торасы да булмаган.

Бөек шагыйрьне илһамландыручы роле бик килешкән иде Алсуга. Декрет ялында утырып, сәхнәне бик сагынып кайткан чагы иде театрга. Кайтуына, хәер, бер ел рольләрсез утырганнан соң, тагын бер «илһамчы» роле аныкы булды. Бу юлы ул «Артист» спектаклендә (Г. Кариевның бу пьесасы Р. Зәйдулла эшкәртүендә куела) Габдулла Кариевның сөйгән кызы Мәүлидәне уйнаячак. Узган гасыр башында – Тукайлар, Фатих Әмирханнар заманында да абруйлы татар кызы булып яши белгән булыр иде ул.

Быелның сентябрь аенда Оренбургка «Ак калфак» бәйрәменә баргач, Алсу Шәмсетдинова-Фәйзуллина Оренбург төбәгенең данлы кызы – бөек артист Сәхибҗамал Волжская-Гыйззәтуллина булып яшәп күрсәтте. Аның монологы, аннары «Гөлҗамал»ны бөтен милли күзәнәкләр уянырлык итеп җырлавы андагы кунакларны тетрәндерде. Менә кайчан яулады ул чын алкышларны! «Минем кызым абруйлы була күрсен иде», дип теләкләр теләгән Розалия ханымның йөрәге, анда барып, кызының уңышына шаһит була калган булса, Алсуны бу кадәр зурлауларга ничекләр түзгән булыр иде икән?!

### Һәркемнең үз көзгесе

Узган гасыр башында яшәгән кызларның киенү рәвешләрен, калфакларын, балитәкләрен, ак ефәк шәлләрен бик ярата Алсу. «Әле мин тагын көзгеләрне дә бик яратам. Минем өемдә бөтен җирдә көзге. Кеше үз көзгесен таба белергә тиеш. Минем дә андый көзгем бар. Мин аны үзем белән йөртәм», – дип яшерен серен ача Алсу. – Зәйтүнәкәй күлмәгеннән өйдәге көзгем каршына килеп баскач, 3 яшьлек улым Әмирханның күзләре ничек янганын күрсәгез иде сез... «Әнием, син артисткамы әллә? Син театрда эшлисеңме? – дип сорауларын тезә дә: – Син бик матур», – дип өстәп куя. Нәни егет минем улым. Яңа күлмәгемне бәби чагында ук күреп ала торган иде. Комплиментлар остасы инде менә. Әллә әтисенә охшаган, әллә бабасына. Минем үз әтием дә әниемә гел матур сүзләр әйтеп тора. Бәйрәм саен чәчәк бүләк итә. Фәнил дә бик игътибарлы. Мин үзем дә аның белән гел киңәшләшәм. Тырнагымны нинди төскә буйыйм икән, дип тә сорыйм инде хәтта. Ул да бик җитди кыяфәт белән киңәш бирә. Менә шулай яшибез инде. Гаиләм – әти-әни, ирем, сеңлем Дилә, каенсеңлем Гүзәл, улым – минем дусларым!»

«Менә шундый бәхетле инде мин!» дигәндәй, Алсу тантана белән миңа карап ала. Бәхетле мизгелләр артында посып калган авыр чакларны оныта белгән өчен бәхетледер инде ул. Баламны ярып алдылар, җөем дә төзәлмәгән килеш беренче каттан икенче катка су ташыдым, бер юлы ике институтта укып, ике диплом язып, бала тирбәтеп йокы күрмәдем, шул дәвердә ике спектакльдә уйнадым, дип зарланса да, хәленә кереп тыңлаган булыр идем. Ә ул мине һаман өйләрендәге курайлы, мандолиналы музыкаль кич утырулар, үзе әзерләгән тәмле ризыклар, үзе чиккән чигешләр белән ымсындырып утыра. Алсуның әнисенең генә түгел, бәлки әтисенең дә юраганнары юш килгән түгелме соң? «Кызым, ризыкны бик тәмле әзерлисең, ирең бик бәхетле булыр синең», дигән юрамышын әйтәм.

Бәхет ул, чыннан да, синең яраткан көзгеләрең сине бәхетле итеп чагылдырган чагында гына мөкаммәл була торгандыр.





**БЕР СОЦИОЛОГ ТАНЫШЫМ КЫЗЫК КЫНА ӘЙТЕП КУЙДЫ: «ӘТИСЕ-ӘНИСЕ ТИГЕЗ БУЛГАН ГАИЛӘДӘ ҮСКӘН БАЛА ХӘЗЕР ДВОРЯН БАЛАСЫ КЕБЕК КАБУЛ ИТЕЛӘ».**

Асия
ЮНЫСОВА

# СЫЗЫК

Мин укытучы. Быел менә беренчеләрне кабул итеп алдым. Табигый ки, һәр баланың гаилә хәлен барлап чыктым. Шөкер, бер балам гына ятим икән, әбисе янында үсә. Аңа игътибарлырак булырга туры килер. Ә болай ярым ятимнәр байтак. Әни белән генә үскәннәре күбрәк инде анысы. Хәзерге гаилә кануннары гуманлырак. Сыйныф журналында әти исеме язылырга тиеш графада бер бала турында да сызык тормый. Без үскәндә безнең сыйныфта андый сызыклы кыз бар иде. Якын дустым Гаянә иде ул. Юк, юк, бала-чага, ягъни сыйныфташлар андый нечкәлекләрдән хәбәрдар түгел иде. Аны берәү дә үртәп газапламады. Ул үзе дә әтисезлек кимлеген сизмәде бугай. Чөнки аларның өендә матур легенда яшәде. Имеш, Гаянәнең әнисе вербовка белән Урал якларына эшкә баргач, бер башкорт егетенә кияүгә чыккан булган. Бәбиләр вакыты җиткәч, Татарстанга, әнисе янына кайткан. Имеш, Гаянәнең кара кашлы, кылыч борынлы чибәр әтисе хатынын авылга үзе кайтарып куйган. Утын ярып, йорт тирәсен карап, эшләшеп – авыл кешеләренә күренеп йөргән. Аннары «туган якка кайтып киләм әле», дип киткән дә югалган. Аның алай китеп югалуын авырга алучы булмаган. Гаянәнең әнисе дә, әбисе дә аны гел дә гел рәхмәт белән генә телгә ала торганнар иде.

«Ярый әле, йөземне ак итеп китте». Әнисенең бу сүзләренең серен Гаянә үзе паспорт алганда гына аңлагандай булды. Зифа буйлы, кара кашлы чибәр кызга паспортын тапшырганда милиция капитаны, ничектер, уңайсызланып китте. Алданрак




паспорт алучыларның исемнәре янына әтиләренең исемен дә кушып, документларын тапшырып килде-килде дә, инде Гаянәгә җиткәч, төртелеп калды. Аннары, гаепле кеше сыман, «шулай да була», дип куйды.

«Шулай да була»ны кыз паспортын ачып карагач кына аңлады. «Ярый әле йөземне ак итеп китте» дигән җөмләнең дә сере ачылгандай булды. Димәк, теге башкорт егете Гаянәгә әти түгел, фәкать авылдашлары алдында татар кызы оятлы булмасын өчен озата килгән миһербанлы бер адәм генә булган ул.

Үзе дә аптырый Гаянә – әнисенә бер сорау да бирми. Аларның өендә бер-берләренә сак карау, кадерләү хөкем сөрә иде. Гаиләләре дә башкаларныкыннан үзгәрәк: әби, апа, апаның улы, әнисе белән Гаянә. Бернинди үпкә-кинәгә урын булмый торган гаҗәеп тату гаилә – хатын-кызлар патшалыгы. Бөтенесе берберләре өчен үлеп торалар. Кайдадыр «югалып йөри» торган әтиләрдә бер кешенең дә гаме юк. Нининдер сызык өчен әнисен борчып торсынмы Гаянә? Тик ул бит педучилищеда укып, башлангыч сыйныфлар укытучысы булырга җыена. Аңа укучылары кем дип эндәшер? Авыл мәктәбендәге гадәт буенча, бәлки, «апа» гына диярләр. Ә җитәкчеләре, ә коллегалары кем дип мөрәҗәгать итәрләр икән? Юк, сызыктан ничек тә котылырга кирәк. Бер кыска гына исемгә урын да бар паспорттагы графада.

Нинди исем сайлыйсы соң, кем кызы буласы? Теге каһәр суккан сызык исемдәге бер хәрефнең сызыгы булып китсә, яхшы да бит. Хәсәнме? Юк бармый. Зәки... Бусы да уңай килмәс. Солтан ярамас микән? Күршедә генә Солтан абзый яши. Ул дип уйларлар. Авылда юк кеше кирәк. Шунда энекәшенә әбисенең «әдәп-низам» дип, үгет биреп утырганы колагына чалынды. Низам! Яхшы исем. Гаянә Низамовна! Матур яңгырый бит! Инде менә кара тушь табасы да, паспорттагы калган язулардан аерылмаслык итеп язып куясы. Фәния дусты кеше язуларына охшатып язарга һәвәс.

Икәүләшеп тәвәккәлләделәр. Теге сызык «Н» хәрефенең уртасына кереп кенә утырды. Кызларның «ялган документ» ясаганын соңыннан да, хәтта паспорт алыштырган чакларда да белүче булмады. Гаянә Низамовна абруйлы укытучы булып гомер юлын узды. Әгәр паспортымда һаман әле теге сызык торган булса, дип уйлап куйгалый ул кайчакта. Һәм... ярым ятим укучыларына карата сизгер, миһербанлы булырга тырыша. Әнисе бу дөньядан кичәр вакыты җиткәч, ниндидер бер сере, әйтәсе сүзе барлыгын белгерткәләп караган иде үзе. Әмма Гаянә һаман: «Әйтерсең әле...» дип кичектерә килде. Хәзер аның шул серне беләсе бик килә дә бит... Соң шул инде.

PRESS.RU



Сагынулар нинди төстә икән?
Чит-читләре ап-ак челтәрме?..
Аның шигырьләре ак кәгазьгә чигелә. Җанында җырлы өермә әйләнә. Язмыш кураена гомер бии... Прагадан ул безгә әнә шулай сагынуларын шигырьләргә төреп җибәрә. Күпләр аны 90 нчы елларда хитка әйләнгән «Карама син йолдызларга» (Зөфәр Хәйретдинов көе) дигән җыр сүзләре аша яхшы хәтерлидер. Ул чакта яшьләр, студентлар газетасында эшләгән журналист кыз Дилбәр Исламова үзенчәлекле матур теле, әдәбият-сәнгать темасына язган язмалары белән укучылар күңелен яулаган иде. Ул бүген дә иҗатта: хикәяләр, шигырьләр яза. Гаиләсе белән инде егерме еллап Чехия башкаласында яшәп ята.



Дилбәр ИСЛАМОВА

# САГЫНУЛАР НИНДИ ТӨСТӘ?

### *Ак болыт, кара болыт*

Көләсең, шашып көләсең,
Шатлыктан күңел булып.
Сөенечең уртаклаша
Күктәге ап-ак болыт.

Елыйсың, әрнеп елыйсың,
Кайгыдан җаның тулып.
Хәсрәттән яшьләрен коя
Күктәге кара болыт.

Яшисең, бары яшисең,
Ни булса – барын узып.
Тормыш аклы да каралы –
Ак болыт, кара болыт.

### *Ак кәгазьгә шигырь чигелә*

Шыбыр-шыбыр алма коеламы?
Шыбыр-шыбыр шигырь коела!
Коела да, күңел капчыгында
Гөлчәчәкле бәйләм җыела...

Тып-тып килеп яңгыр сипкәлиме?
Тып-тып килеп юллар сибелә.
Тамчы булып тама төсле хисләр,
Ак кәгазьгә шигырь чигелә...

Дөп-дөп килеп атлар чаба дисәм,
Дөп-дөп килә йөрәк читлектә.
Таң атканчы язып бетер! диеп,
Тәрәзәмә шигырь чиертә...

### *Ак чәчәккә куна ак күбәләк*

Ак чәчәккә ак күбәләк куна,
Канатлары белән кагылып.
Күбәләк тә сагышлана микән,
Күрми торган чакта сагынып?

Сагынулар нинди төстә икән?
Чит-читләре ап-ак челтәрме?
Аргамактай чапкан ашкын гомер
Яшәп туймасаң да бетәрме?

Ак юллардан бер кайтасы иде
Каршыларга Агыйдел таңын...
Ак чәчәккә куна ак күбәләк –
Ак дөньямда яши пакь җаным...

### *Җырлы өермә*

Әйләнә дә башта әйләнә
Һич туктамый торган өермә.
Яңгырый ул, күзем йомсам да,
Тыныч кына карап торсам да.

Нинди җыр ул, каян табылган?
Үткәнгә бит юллар ябылган?
Бик ерактан, яшьлек языннан
Ул иде җыр – шундый танылган...

Туктама, җыр! Зинһар, югалма!
Бер бушанып күңел – еласа...
Әйләнә дә, һаман әйләнә
Җанымдагы җырлы өермә...

### *Көзге яфраклар*

Җил биетә көзге яфракларны,
Чаж-чож урамнардан йөгертә.
Коелдыгыз инде дия-дия,
Борылып каратмыйча тилмертә.

Без дә коелыштык. Таратырга
Ирек куйдык вакыт җиленә...
Кем диңгездә ныклы җилкән булды,
Кемдер чумды сазлык төбенә...

Бөгәрләнеп кипкән яфраклар да
Әрнүләрдән сыкрап елыйдыр...
Язмыш кураена гомер бии,
Әйләнеп тә карап булмыйдыр...

### *Кем тәрәзе ачык?*

Кем тәрәзе ачык? Моң тарала,
Хис сибелә шыксыз урамга.
Пианино тавышы әсир итте,
Туктап калды хәтта буран да.

Кем тәрәзе ачык? Минем күңел
Җиде биккә бикле чагында?
Ялгышлардан яптым ишекләрен,
Үзем генә үзем янында...

Кем тәрәзе ачык? Кем йөрәге
Моңсу җырын җилгә тарата?
Йөзләремнән ага күз яшьләрем,
Кем күңелгә ачкыч ярата?

### Мәтрүшкәләр көе

Сөн буенда үскән мәтрүшкәләр
Кайтуымны минем көтәләр.
Җиләк-бөрлегәнле тау битендә
Талгын җилкәйләре исәләр.

Кушымта:
Кайтырмын мин,
кайтмый түзә алмам,
Ашкыныплар көтәм җәйләрне.
Мәтрүшкәләр моңлы көйгә салган
Сагыш тулы минем хисләрне.

Сөн буеның гади бер кызы мин,
Еракларга язмыш ташлаган.
Кочагыма алам туган якны,
Юктыр минем кебек сагынган!

Сөн буенда үскән мәтрүшкәләр
Киткәч төшләремә керәләр.
Мәтрүшкәләр җырлап үскән көйләр
Сөннең болынына илтәләр.

### Ничек сезнең хәлләрегез?

Ничек сезнең хәлләрегез?
Нәкъ безнеке кебекме?
Болыт артларында кояш
Тора яшен түгепме?

Тик торганнан килә микән
Сезнең дә бер елыйсы?
Әрнүләргә чара тапмый
Бүре кебек улыйсы?

Ничек сезнең хәлләрегез?
Безнеке кебек микән?
Кеп-кечкенә шатлыклар да
Әллә ни кебек микән?

Ничек сезнең хәлләрегез?
Бүгенгә түзәрлекме?
Башка төшкән хәсрәтегез
Үзәкне өзәрлекме?

Ничек сезнең хәлләрегез?
Сорамагыз безнекен...
Безнекенә түзәрлек лә...
Түзәрлекме илнеке?

Башкортстанда яшәп иҗат итүче шагыйрә Нәфисә Хәбибдияровага 15 ноябрьдә 60 яшь тулган булыр иде. Әмма аяусыз үлем аны күптән түгел арабыздан алып китте. Шигырьләре нечкә моң, илаһилык белән аерылып тора.

Нәфисә ХӘБИБДИЯРОВА

### Телем көче

Ана сөте белән кергәндер ул
Телем көче, телем бөеклеге.
«Әннә», диеп телем ачылганда
Тойганмындыр телнең кирәклеген.

Телем көчен, телем бөеклеген,
Телем кадерен, телем сафлыгын
Киләчәккә алып барыр өчен
Бер нур итеп җанда саклыймын.

«Әннә», диеп телем ачылганда,
Ходай миңа үзе көч биргән.
Тел кадерен белсен бу бала, дип,
Җан-чишмәмнән аккан хис биргән.

Хис биргән дә – җаннан агылганда,
Хисләремне төргән нур белән.
Шигыремдә шул нур балкыганга,
Анам теле, сиңа баш иям!

### Сагышка кала

Назлар һәм сөюләр тулы
Мәхәббәттән җырлар туа.
Киң Җиһанда, Кош юлында
Моңлы, зарлы җаннар кала.

Без китәрбез Кош юлыннан –
Җырларда-канатларда.
Җирдәге сөю-моңнарны
Алып йолдызлыкларга.

Язлар үтсә сөю белән,
Күзләрдән сагыш кала.
Сөюләрдән ялкынланып,
Җаннарда моңнар кала.

### Ак каурыйдан моң тама

Ах, югалттым аккошымны –
Язмышымның бүләген.
Ник бәхеткә юрап кына
Теләк тели белмәдем.

Киек кошларның юлына
Күзләрем талды карап.
Йолдызлар гына атылды –
Күренмәде ак канат.

Очты ул хыялым булып
Киек каз юлы буйлап.
Ярый өмет-каурый калды
Сагышларыма урап.

Йолдыз җыеп кош юлыннан
Җыр язар идем аңа.
Күктә йолдызлар атыла –
Ак каурыйдан моң тама...

### Чәчкә бураны

Кузгалды чәчкә бураны,
Очынып җил уйнады.
Таҗларны тезде юлларга,
Күкне, җирне буйлады.

Чәчкә исләре таралды,
Тик күңел ник ямансу?
Күл өсләре ап-ак булган,
Уйга калган агым су.

Мин дә уйга калам кайчак,
Агым суларга карап.
Чәчкә вакытлар бер генә,
Кайтарып булмый кабат.

Чәчкәләр ява чәчемә,
Буран да туктап калды.
Чәчкәле буран чагыма,
Их, кайтып булса тагы!

### Алмаларны кемгә сакладым

Күзләр җиткәнлеген тоймый калдым,
Бәргәләнеп җилләр иссә дә.
Җил капкадан кемне көтәм соң мин,
Килми калганлыгын белсәм дә.

Күзләр җиткәнлеген сизми калдым –
Агачында әле алмалар.
Алмаларны кемгә сакладым соң,
Янган күңелемне алдалап?

Күзләр үткәнлеген күрми калдым,
Кыйгач яңгырлары яуганда.
Керфекләрдә яшьләр икәнлеген
Тоймаганмын тамчы тамганда.

...Инде килсә, кышлар җиткән икән,
Җил капканы күмгән ак карлар.
Шәмнәр булып алмагачта яна
Кышка калган сары алмалар.
...Инде килсә, кышлар җиткән икән.

PRESSA.RU



# МИН ЯРАТАМ СИНЕ...

(Хикәя)



Марат КӘБИРОВ

* * *

– Тиздән мәетне алып чыгалар. Күреп калырга теләүчеләр булса, кирәргә мөмкин...

Ир хәлсез адымнар белән өйгә атлады.

Түр якның уртасына куелган диванда акка төренеп яткан яшь кызны күрүгә, йөрәген нәрсәдер чеметеп алды. Ирнең моңа кадәр дә мәетләрне күргәне бар иде. Йөзләре агарынып, бәләкәйләнебрәк кала, алар инде кешедән бигрәк, балавыздан ясалган курчакны хәтерләтәләр. Әмма бүлмә уртасында яткан кыз үлгән кешегә бөтенләй охшамаган. Йөзендәге җиңелчә алсулык та, тулышкан иреннәрендәге наз да, кыйгач кашларының шаянлыгы да шул килеш. Ә күзләрендәге якты нур ябык керфекләр аша да бөркелеп торган сыман.

Ир бер мәлгә сискәнеп катып калды. Кыз үлмәгәндер, аны акка төреп бүлмә уртасына салган кешеләр ялгышадыр төсле тоелды. Менә-менә керфекләрен күтәрер дә, үзеннән күз алмый торган ирнең сабырлык пәрдәсе ябынган хәсрәтле йөзенә карап, сискәнеп китәр һәм, әлеге хәлнең бары тик ниндидер аңлашылмаучылык кына икәнен исенә төшереп, елмаеп җибәрер:

– Ничек сине ташлап китим инде?!. Юләркәем...

* * *

– Ничек сине ташлап китим инде?!. Юләркәем...

Кыз әйтеп бетергәсез наз белән аңа текәлде дә, елмая биреп, егетнең чәчләреннән сыйпады. Егет бер мәлгә әлеге хәлнең чынлыгына ышанмыйча торды, аннан соң кыюсыз гына елмайды, үзенең шундый уйны якын китерүе өчен оялгандай, керфекләрен җиргә кадады һәм кинәт килгән шатлык ташкыны тәэсирендә, сөйгәнен куенына алды да кысып-кысып кочаклады. Кыз бер каршылык та күрсәтмәде, егетенең куенында эреп бетәргә теләгәндәй бар гәүдәсе белән аңа ягылды. Бары тик сөякләренең метердәп китүен тоеп кына назлы пышылдады:

– Кысма, сантый... Үтерәсең бит... Үте...

Нәкъ шул мәлдә иреннәр бер-берсен табышты да, кызның сүзләре йотылып калды...

Барысы да нәни генә сантыйлыктан башланган иде ул чакта.

Егет күптән түгел генә мотоцикл сатып алган иде. Өр-яңа ук түгел инде дә, әмма атнага якын вакытны сарыф итеп бик күп детальләрен алыштырып куйгач, менә дигән техникага әверелде. Кайбер яшьтәшләре инде җиденче сыйныфтан ук руль артында. Егет аларга беркадәр көнләшеп карый һәм үзенең мотоцикл да йөртә белмәс булып үсүенә бераз гарьләнә дә иде. Ниһаять, максатына иреште. Узган ел бозау көтеп җыйган акчасына әнисенең хезмәт хакын өстәп, югары очтагы Газизҗан абыйның «Минск»иен алып кайттылар. Матайны җыю белән ул авыл читендәге яланга җилдерде. Анда руль тотарга һәм һәртөрле фигуралар ясарга өйрәнгәч, тауга китте. Тауның сөзәк урыннарын да, текә җирләрен дә аркылыга-буйга айкап чыкты. Урман арасында йөрергә дә өйрәнде. Бары тик шулай бер атна чамасы күнеккәннән соң гына сөйгән кызы янына мотоцикл белән барырга булды.

Мотоциклда йөрүнең рәхәт яклары күп инде аның. Кызыңны артка утыртып аласың да теләгән җиреңә җилдерәсең. Яхшырак юлга чыгып арурак тизлектә йөрү тагы да рәхәтрәк. Мондый чакларда сөйгәнең куркудан сиңа чатырдап ябыша. Биленлә аның кысып кочаклаган кулларын, аркаңда назлы күкрәгән тоюдан башлар әйләнеп китә. Йөрәк атылып тибә башлый...

– Әйдә, мине дә өйрәт! – дип елмайды кыз бер көн.

– Әйдә! – егет уйлап та тормады. Кайда басарга, нәрсәне борырга икәнен күрсәтеп бирде дә, кызны руль артына утыртып та куйды. – Дөрес. Хәзер муфтаны җибәр, ә газны ача төш. Молодец!

Мотоцикл баштарак уңга-сулга тарткаланды да төз генә бара башлады...

Беркадәр вакыттан соң кыз ярыйсы ук өйрәнде. Икесенең дә авыз колакта иде. Очрашкан саен егет сөйгәнен руль артына утыртыр булды, ә үзе артка урнашып, аның куш учка сыеп бетә язган биленнән кочаклап, җилгә тузгыган чәчләренә битен куеп иркәләнеп барды.

Көннәрнең берендә алар шулай авыл урамына килеп керделәр. Тыкрыктан борылып бераз баруга ук юл читендә торган сары «Урал» күзгә чагылды, ә бер мизгелдән таягын болгап каршы килүче милиция хезмәткәрен күрделәр. Туктарга кирәк иде, әлбәттә. Әмма кыз бу көтелмәгән хәлдән каушап төштеме, кинәт газны ачты. Һәм алар милиционерның борын төбеннән выжлап узып киттеләр. Егет шундук рульне эләктерде дә газны азайта төшеп, юл читенә борды.

– Курыкма, тынычлан... – диде ул кызнымы, үзенме юатырга тырышып.

– Ул безнең арттан килә! – дип кычкырды кыз. – Тотса – беттек!

Кызның халәте йоктымы, егет газны ачты. Кызның аякларын тизлек педаленнән һәм тормоздан шудырды да идарәне үз кулына алды. Тәртип сакчысы инде үкчәгә басып килә иде. Егет, тизлекне алыштырып, тагын газны ачты. Мотоцикл алга ыргылды. Әмма «Урал» калышырга уйламады да. Бераздан ул сулдан кереп, «Минск» белән тигезләшә башлады. Аз гына алгарак чыктымы, уңга алып кысрыкларга тотыначак. Анда инде туктамыйча чараң калмый.

Һәм бу тиклем кыланганнан соң, милиционер белән сөйләшеп килешү дә мөмкин булмаячак. Ә кулдан алынган мотоциклның номеры да, документлары да юк. Туктасаң, мотоцикл белән хушлашырга туры киләчәк. Ярый, анысы да бер хәл... Тотылсаң, милициягә учетка куярга да күп сорамаслар. Ә руль артында кем? Аның сөйгән кызы!..

Егет газны ачты һәм аз гына алга китүдән файдаланып, рульне сулгарак борды. «Урал» кабат артта калды. Тизлегеңне аз гына киметсәң, ул артыңа килеп бәрелер төсле иде. Тик ул арттан бәрдертергә кыймаячак. Шулай да бу юл «Урал» белән алышу өчен уңайлы түгел. Берәр таррак урын табарга кирәк. Әһә! Тиздән елга буена төшә торган тыкрык булырга тиеш...

Инде тәңгәлләшә башлаган милиционер тыкрыкка кисәк борылу белән тукталып калыр, һичьюгы тизлеген киметер кебек иде. Әмма ул калышмады. Тыкрыкның бердәнбер өстенлеге – ул «Урал»га алга чыгарга ирек бирми. Димәк, аның коймага кысрыклау мөмкинлеге юк. Димәк, ул тота алмаячак. Әмма тыкрыкның озынлыгы...

Кинәт кыз җан ачысы белән кычкырып җибәрде. Тыкрык ахырында уңга да, сулга да кинәт кенә борылып керерлек түгел икән. Шайтан алгыры! Борылам дисәң, ярдан очуыңны көт... Ә алда ике тактаны беркетеп елга аша салынган тар гына басма. Ярдан – ярга... Такталар ныклы булса, чыгарга мөмкин. Һәрхәлдә, бу матай белән кәҗә сукмагыннан да йөреп була...

Егет артка карап алды. «Урал» тизлеген киметә төшкән. Ул инде артта калып килә. Ике-өч метрга... Дүрткә...

– А-а-а!.. Тукта, җаным!.. Бетәбез бит!..

Бәлки тормозга басарга кирәктер?.. Тыкрык буйлап бар тизлеккә җилдергән матай туктарга өлгерерме? Хәер, тизлекне ярыйсы ук киметкәндә, яр буена борылырга мөмкиндер... Ә аннан соң? Тупыйк. Аннан беркая да китеп булмый. Ә борыла алмый калсаң?.. Юк инде, мондый тар арада борылу түгел, туктарга да өлгермисең...

Кинәт егеткә нәрсәдер булды. Ул кызның аякларын тезләре белән ныграк кысты. Ияге белән кызның аркасына басып, аны бензин багына яткыра төште. Һәм газны ачты. Аның өчен дөньяда берни дә юк иде инде. Бары тик коточкыч тизлек белән якынлашучы тар басма гына...

Бер мизгелгә такта дырылдаган тавыш ишетелде. Аяк астында җир убылган кебек тоелды. Ул үзенең ник болай эшләвенә үкенеп куйды. Тик соң иде инде. Хәзер бернәрсәне дә үзгәртеп булмый... Бары тик басма гына ныклы булсын да, кыз гына чәбәләнмәсен...

Кыз чәбәләнмәде дә, кычкырмады да.

Бераздан мотоцикл катканакка килеп керде. Шунда гына сөйгәне бензин багының әле уң, әле сул ягына шуырга тотынды. Аны тотып калу теләге белән ул әле бер, әле икенче беләген катырды. Нәтиҗәдә, газны ташларга мәҗбүр булды, ә мотоцикл, бер яктан икенче якка тайпылды да, бераздан буылып сүнде...

Бары тик шунда гына егет үзенең елга аръягындагы кечкенә аланлыкта икәнен аңлады. Артына борылып карады. Милиционер да, тыкрык та күренми, аларны елга буендагы таллык каплый иде. Шатлыгын уртаклашырга дип сөйгәненә борылды. Һәм кинәт катып калды. Кыз бензин багына капланган хәлдә тынып калган иде. Егет аны мотоциклдан шудырып чирәмгә яткырды. Бераздан үзе дә аның янына чүгәләде.

Сынган җире юкмы дип кызны капшап карады. Бәлки чигәсе белән бәрелгәндер?!. Күгәргән эз булмаса ни!..

– Җаным! Бердәнберем... Ник дәшмисең?!.

Кыз селкенеп тә карамады. Егет күңелен инде курку биләде. Ник туктамады ул?!. Милиционерга тоттырмавы баштарак егетлек кебек күренсә, хәзер ул куркаклык булып тоелды. Куркаклык, әлбәттә! Ул матаен югалтудан курыкты. Ул учетка бастыруларыннан курыкты. Курыкты... һәм сөйгәнен үлемгә дучар итте...

Үлем...

Әмма кыз үлгән кешегә бөтенләй охшамаган иде. Йөзендәге алсулык та, иреннәрендәге наз да шул килеш. Ә күзләрендәге якты нур ябык керфекләр аша да бөркелеп торган сыман.

– Юк... юк... Син үлмисең... – дип пышылдады ул, чирәмдә яткан гүзәлне үзенең исән икәненә ышанды-

PRESSA.RU



рырга теләгәндәй, һәм аның күкрәгенә капланып, җан ярсуы белән ялварырга тотынды. – Ташлап китмә мине, бердәнберем... ташлап китмә...

Аның җаны, бөтен галәмдә япа-ялгыз калган үксез җаны, дөньяның әле бер, әле икенче почмагына бәрелеп чәбәләнде. Аккош булса, җиргә ташланыр да котылыр иде. Тик ул беркая да ташлана алмады, ташланса да бәрелеп ватылмады. Ул үлемдә түгел, үксезлектә иде.

Кинәт нәрсәдер булды. Галәмнең чиксез караңгылыгына убылган тормыш кабат кайтты. Ул үләннең яшеллеген, җилнең ягымлылыгын кичерер хәлгә килде. Шунда гына кочагындагы кызның җылылыгын, аның җиңелчә генә кыбырдавын тойды. Һәм яңаклары буйлап агып төшкән тасманы йодрык сырты белән сөртеп, йөзен күтәрде.

Кыз күзләрен ачкан иде инде. Ул моңсу ягымлылык белән аңа карап тора иде. Шулай гына микән? Бу карашларда чиксез мәхәббәт тә, соклану да, кызгану да, үпкәләү дә, гафу үтенү дә – барысы да бар иде. Һәм кыз елмайды... Әллә нинди сихри елмаю белән...

– Ничек сине ташлап китим инде?!. Юләркәем...

* * *

Ир текәлеп озак карап торды. Акка төренеп яткан кызның күзләрен ачуын көтте. Йөзендә бер генә күзәнәк дерелдәп куйса да, ул моны тоячак иде. Тик кыз хәрәкәтсез калды. Бары тик ирнең колагында гына еллар аша татлы тавыш яңгырады.

– Ничек сине ташлап китим инде?!.

Бу тавышның ихласлыгына, сүзләренең хаклыгына беркайчан да, берничек тә шикләнерлек түгел иде. Һәм ул ышанды. Кызның аны беркайчан да, беркайда да ташлап китмәячәгенә ул бар күңеле белән ышанды.

Әмма кызның сүзләре хак булган кебек үк, аның үлеме дә хак иде.

Ир диванга чүгәләде. Кызның иреннән үбеп алды. Иреннәрнең салкын булачагын белә иде. Чәчләреннән сыйпады. Зур саклык һәм чиксез сөю белән. Күңелендәге бөтен сөю-назларын аңа тапшырырга теләгәндәй. «Иреннәремнең бар кайнарлыгын, җанымның бар назын үзең белән алып кит, синнән башка алар миңа кирәк түгел!..» – дигән кебек.

Карашларын кыздан аера алмый торып басты.

Бертын катып торды.

Һәм иреннәрен кымтып, ишеккә юнәлде...

Адымнары ешайган саен, күзләре ныграк дымланды, күзләре дымланган саен, адымнары тизләнде... Тик ул инде олы ир иде... Күз яшьләре дөньяның бар матурлыгын томалап дуладылар да, керфекләргә кунмыйча кайдадыр юл алдылар. Тозлы тамчы булып күңел ярасына тамдылар бугай...

– Ник болай булды соң? Болай булырга тиеш түгел иде бит... – дип пышылдады ул. – Озын гомерле булырга тиеш иде бит...

Шушы уй күңелен камчылады, миен бораулады. Дөрес җавап кына табылмады.

* * *

– Болай булырга тиеш түгел иде бит... – дип үкседе мәет яныннан чыккан хатын. – Озын гомерле булырга тиеш иде бит...

Түр як бүлмәдәге диван уртасында яткан яшь егет аның күз алдыннан китмәде. Чем-кара чәчләр... Кара кашлар... Чаялыгы чагылып торган йөз... Егет аңа тередер сыман тоелды. Аның мәетләрне күргәне бар. Мәетләр болай булмый. Ул менә генә сикереп торыр да сөйгәнен кочаклап алыр, сөякләре метердәп китәрлек итеп кысып кочаклар...

– Кысма, сантый... Үтерәсең бит... – дип пышылдар кыз. – Үте...

Әмма сүзен әйтеп бетерә алмас, кайнар иреннәр бер-берсен эзләп табар да дөньяның барлык вактөякләрен оныттырып мәхәббәт күгенә алып менәр...

Бераздан кыз, бу ләззәтнең үбешүләр белән генә тәмамланмасыннан куркып, егетне читкә этәрер. Йөрәгеннән өзеп алган сыман. Һәм сикереп торыр да киемнәрен төзәтергә тотыныр. Һаман хисләрдән айный алмый торган егетенә карап гаепле елмаер, аның башыннан сыйпар, янына чүгәләр, сүзне икенчегә борыр:

– Син ник туктамадың?

Егет бер мәл уйланып торыр.

– Белмим... – дияр ул гаепле тавыш белән. – Курыктым бугай...

– Нәрсәдән?

– Милиция учетына басудан...

– Руль артында мин идем бит...

– Син идең шул...

Бер мәлгә тын калырлар. Егет керфекләрен түбән кадар. Кыз уйланыр.

– Учетка бастырсалар да мине бастырырлар иде, – дип елмаер ул бераздан. – Мотоциклның документлары юк ич...

Егет аның чәчләреннән сыйпар:

– Ярый, узды бит инде... Бар да әйбәт...

– Әгәр әйбәт булмаса? Әгәр без бәрелеп үлгән булсак? Басманың нинди икәнен күрдеңме син!

– Үлмәдек бит...

– Әгәр егылып имгәнгән булсак? Әгәр мин гарипләнгән булсам?.. Син мине ташлар идең, шулай бит?..

Егетнең күзләренә шаян очкыннар кунар. Һәм ул иңнәрен сикертер:

– Белмим...

Һәм шаркылдап көлеп җибәрер. Ә кыз аңа ташланыр:

– Аһ, син мине ташларга җыенасыңмы әле!

Егет кызның һөҗүмен җиңел генә кире кагар да аны кысып кочаклап алыр һәм иреннәр иренгә, күзләр күзгә тия язарлык итеп якынаер да:

– Бел, кадерлем... – дип пышылдар. – Әгәр бер генә күзәнәгең исән булса да, мин сине ташламаячакмын.

Кыз бер мизгелгә тынып калыр. Бу сүзләрнең мәгънәсен аңлагач, күңелендә кайнар давыл кубар:

– Бергенәм минем, – дип пышылдар ул да. – Бердәнберем... Мин дә... Мин дә сине мәңге ташламаячакмын... Мин яратам сине!..

Бер мизгелгә икесе дә исәңгерәп калыр.

Кыз үзенең бу сүзне беренче булып әйтүенә, әйтер кыюлык табуына аптырагандай булыр. Ә егет башлап үзе әйтмәүгә үкенгән һәм кызның чаялыгына сокланган сыман күзләрен зур ачып сөйгәненә текәлер... Әмма тиздән икесен дә мәхәббәт өермәсе урап алыр...

Гомереңә беренче тапкыр «мин яратам сине» дию дә, аны ишетү дә сәер икән. Сәер һәм татлы. Мәңге онытылмый һәм мәңге кабатланмый торган бер халәт бу.

– Мин яратам сине...

Соңыннан да бу сүзләрне бик күп тапкырлар ишетте хатын. Үзе дә әйтте. Тик аларның берсе дә беренче тапкыр әйткәндәгедәй татлы булмады бугай. Хәер, кем белә... Һәркайсының кадере дә, бәясе дә, хаҗәте дә үзенчә булгандыр.

Әмма соңгы елларда ул сүзләр ничектер җиңел яңгырады... Җиңел әйтелде... Җиңел ишетелде... Хәтта «ахмак» яки «бар кит моннан!» дигән мәгънәне дә шушы сүзләр алыштырыр булды.

Ә кайвакытларда бөтенләй уйлап тормыйча, гадәт буенча да ычкынгалады... Ә тора-бара берни аңлатмаган, бернинди мәгънәгә ия булмаган үле сүзләргә әверелде. Югыйсә сугышып-талашып та яшәмәделәр ире белән. Эшләделәр, балалар үстерделәр, дөнья кудылар... Барысы да тәртиптә, барысы да уңай кебек иде... Тик әлеге сүзләр генә... Сүзләр генә... үлде...

– Болай булырга тиеш түгел иде бит...

* * *

– Ә ул бөтенләй дә мәеткә охшамаган...

Кинәт ишетелгән сүздәнме, иңенә сак кына кагылган кулларданмы хатын сискәнеп китте. Ялт итеп артына борылды. Ире икән. Аның алдында күз яшьләре түгүдән кыенсынып, учлары белән күзен сөртеп алды. Сер бирергә ярамый. Әмма моның ярдәме тимәде. Яңаклары буйлап агып төшкән тасма битенә таралды, керфекләрдәге тамчылар туктамады.

Ир аңа кулъяулык сузды. Хатын баш селкегәч, аның битен үзе сөртеп алды. Нәкъ менә яшь баланы көйләгән кебек. Хатын сәерсенеп иренә бакты.

– Ә ул бөтенләй дә мәеткә охшамаган... – дип кабатлады ир. – Йөзендәге җиңелчә алсулык та, тулышкан иреннәрендәге наз да, кыйгач кашларының шаянлыгы да шул килеш. Ә күзләрендәге якты нур ябык керфекләр аша да бөркелеп торган сыман.

Хатынның күзләрендә балкып киткән өмет чаткысы керфекләрдәге дымны шундук киптерде.

– Миңа да ул егет тередер сыман тоелды... – диде хатын. – Тик сулышын гына ишетмәдем... Һәм иреннәре дә...

Ир кинәт сәерсенеп хатынга карады:

– Егет?!.

Хатын акрын гына баш какты:

– Егет...

– Тукта, нинди егет булсын!.. Кыз ята иде анда...

– Егет иде, – дип үзенекен тукыды хатын. – Егет! Һәм ул синең яшь чагыңа тамчы судай охшаш.

Каршы сүз әйтергә дип авызын ачкан ир кинәт катып калды.

– Кыз да... – дип пышылдады ул. – Кыз да... синә... Тукта!..

Әмма туктап уйланып торырга вакыт бирмәделәр, өйгә чакырдылар.

* * *

– Ул мәеткә бер дә охшамаган...

Түр якның уртасына куелган диванда акка төренеп яткан яшь кызны күрүгә ир тагын шулай уйлады. Иреннәренең салкынлыгын ул белә иде. Сулыш алганы да сизелми. Бер генә күзәнәге дә тибрәнми... Тикшерәсе иде...

Әмма түр башында басып торган Аксакал моңа ирек бирмәде:

– Җәмәгать!

Аксакал сәер зат иде. Ул бу төбәкнеке түгел. Монысы көн кебек. Ул нindidер әкият иленнән килгән изге картка охшаган. Ап-актан киенеп, чәч-сакаллары да ак булгангамы, бар кыяфәтеннән сафлык, нур бөркелеп торган сыман.

Аксакал тамак кырган арада, ир мәеткә карап алды һәм бүлмәгә күз йөгертте. Моңарчы игътибар итмәгән иде, бүлмәдә алар үзләре генә икән. Ир, хатыны, балалары... һәм Аксакал. Башка беркем дә юк.

– Мәетне зиратка кадәр сез күтәреп барачаксыз... – диде Аксакал һәм, аңладылармы дигәндәй, һәркайсына күз йөгертеп чыкты. – Алдан ир кеше күтәрә, арттан – җәмәгате. Ә балалар ике як читтән аларга ярдәмләшеп бара... Барыгыз да аңладыгызмы? Сораулар юкмы?

Ир тагын мәеткә карап алды. Бая игътибары җитмәгәнме, аны инде ак носилка сыман нәрсәгә салып, алып чыгу өчен әзерләп куйганнар икән. Уртада ян-яклардан күтәрешеп бару өчен балаларга да тоткычлар бар. Барысы да аңлашыла бугай... Зиратка кадәр...

– Хәзрәт... Ә зиратка керү рөхсәтме соң? – дип сорады хатын. – Югыйсә...

Аксакал баш кагып куйды.

– Мәетне сез зиратка кадәр күтәреп алып барачаксыз, – дип кабатлады ул. – Кабергәчә...

Хатын баш какты. Әмма Аксакал, төгәллек кертүне кирәк тапты бугай, тагын өстәп куйды:

– Кабергәчә... Үз каберләрегезгәчә.

Бер мәлгә сәер тынлык урнашты. Аксакалның соңгы сүзе бар нәрсәнең астын-өскә әйләндерде. Әле генә бар да аңлаешлы кебек тоелса, хәзер инде берни дә аңларлык түгел иде. Шулай да ир күңелендә чәбәләнгән сорауны бирми булдыра алмады:

– Ә мәет... Ул кем?..

Хатыны аңа үтергеч караш ташлады:

– Егет дип торам бит инде... – дип пышылдады ул, һәм иренең тәртипсезлеге өчен аклангандай, аксакалга дәште. – Югалту аның аңын томалаган... Мәет аңа кыз булып күренә...

Балалар бер-берсенә сәер карашып алды, әмма өлкәннәр сөйләшкәндә сүз катудан тыелып калдылар.

PRESSA.RU



– Мәет чынлап та кыз кеше, – дип дәвам итте ир. – Ә хатыныма ул егет булып күренә... Минем яшь чагыма охшаган егет булып...

– Әйе... – дип Аксакалга төбәлде хатын. – Сез барысын да беләсез... зинһар, әйтегез... Кем ул?

Аксакал кызганулы да, ягымлы да карашларын берчә хатынга, берчә ирга күчерде. Аның карашлары ир белән хатынның кайгысын уртаклашкан, җаннарын юаткан шикелле иде. Әмма сүзләре хөкем карары кебек яңгырады:

– Ул – сезнең мәхәббәтегез.

* * *

Алар атладылар да атладылар. Таулар-ташлар да, күл-елгалар да очрый торды, артта кала торды. Башта сыеграк булып тоелган балалар инде буын ныгытты. Иңдәге йөкне шундый ныклы кешеләр белән күтәрү бик тә җиңел булырга тиеш кебек иде. Әмма алай булмады. Йөк авырайганнан-авырая гына барды.

Бераздан балалар үсеп җитте. Канатлары чыкты. Авырлыкның һәм әрнүләрнең үзләренә тиеш өлешен алып, алар далага очтылар. Үз балаң барысыннан да яхшырак, барсыннан да акыллырак, көчлерәк булып тоела. Аларның балалары да ныклы канатлары белән барысыннан да югарырак күтәрелер кебек иде. Әмма башкалардан уза алмадылар. Бәлки, иңнәрендәге йөк, күңелләрендәге яра ирек бирмәгәндер. Бәлки, башка сәбәп булгандыр. Кем белә...

Алар атладылар да атладылар...

Иңнәрен авыр йөк, күңелләрен тирән яра изде.

– Мин башкача болай яши алмыйм, – диде хатын көннәрнең берендә. – Син тудырдың ул мәхәббәтне. Иң беренче булып син яныма килдең. Бу йөкне дә син күтәрергә тиеш. Мин китәмен.

Ир дәшмәде. Бераз гына күңеле кителсә дә ул риза иде. Хатын хаклы. Аннан соң, акрын гына кузгалучы шушы бичә белән йөк тартканчы, аны ялгызың алып бару күпкә җайлырак иде.

Хатын китте.

Ул ирекле иде. Иңендәге йөктән азат булды. Җирдә яшәү нинди рәхәт икән! Аның адымнары җиңел иде. Адымнар җиңеллеге үзеңне канатлы итеп тоярга мөмкинлек бирә икән бит. Күңелендә бернинди әрнү юк. Тормыш тоташ бию сыман икән! Ул биеде... Җилләр белән вальс әйләнде ул, дулкыннарга кушылып дулкын булды... Шушы халәтнең ләззәтен тоеп беркадәр йөрде дә туктап калды. Нидер җитми иде...

Нидер җитми... Ул җил түгел иде... Дулкын да түгел иде... Һәм җилләр, дулкыннар тормышы белән яшәү дә – аныкы түгел... Ул үз тормышы белән яшәргә тиеш иде. Ул үз тормышы белән яшәргә тели иде. Ә үз тормышы юк иде. Күңелендә дә, тормышында да бушлык иде. Аның җаны сөю газаплары теләде. Газаплар юк иде. Җаны сөю ләззәтләре теләде. Ләззәт тә юк иде. Мәхәббәт юк иде. Мәхәббәттән ваз кичкән көннән соң, аның истәлекләргә дә, хәтта истәлекләргә дә хокукы юк иде. Бар дөньясы тоташ бушлык иде.

Һәм ул кире борылды.

Мәхәббәтнең мәете дә – мәхәббәт иде...

Ирен эзләп тапты.

Мәхәббәт йөген кабат иңендә тою белән, бар дөньясы кинәт балкып китте. Мең төсләргә, мең хисләргә кереп балкыды. Шушы балкыш авырлыкны бераз оныттырды. Тик бераздан бар да кабат кайтты. Авырлык та, газап та зур иде. Кайчакта ул чыдап булмас чиккә җитте.

Алар атладылар да атладылар...

Йөк бик авыр, ә юл ерак иде... Кабергәчә...

Алар инде иңнәрендәге мәхәббәт мәетен бирәр урында җирләп калдыру турында уйлый башладылар. «Кайда куйдыгыз мәетне?» – дип сораучы барыбер булмаячак. Чөнки аларны юлга озаткан сәер Аксакал нурга уралып юкка чыгу белән үк, мәхәббәт йөге дә күзгә күренмәскә әверелде. Дөресрәге, аны гаилә әгъзаларыннан башка беркем дә күрмәде. Тәүге мәлләрдә күкрәк киереп дәртләнеп йөргән ир белән хатынның бераз бөрешеп калуын күрүчеләр дә моңа артык әһәмият бирмәделәр: «Боларны да дөнья басты», – дип кенә куйдылар. Алар иңнәрендәге йөкне бары тик үзләре генә күрде, аның авырлыгын үзләре генә кичерде. Башка беркем күрмәде аны. Һәм ул башка беркемгә дә кирәкми иде. Шулай булгач, нигә җирләп калдырмаска әле?

Шушы уйлар белән ир Изгеләр тавының башында кабер казыды. Мәхәббәтне, кайчандыр үзләрен оҗмахның җиденче катына күтәрелергә мәҗбүр иткән тылсымлы хисне, башка урынга күмү мөмкин түгел иде. Ни генә әйтсәң дә, мәхәббәт бит ул! Хәтта үзе үлгән килеш тә ир белән хатынны бергә яшәргә, балалар үстерергә мәҗбүр итте бит. Бүгенгенең салкын көннәрендә алар үткәннәрдә яккан сөю учагында җылындылар. Шул учакның ялкыннары көч бирде. Гәүдәләре бүгенгедә йөрсә дә, күңелләре үткәннәрдә булды. Берсен-берсе өзелеп яратышкан чакларда. Һәркайсы үзе генә белгән юллар белән үткәннәргә кайтты да, җан сөйгәне белән очрашты, мәхәббәт утларында янды. Бәхетле булды. Шундый мәхәббәтне теләсә кайда җирләп буламыни!

Җир каты иде монда. Туфракның һәр бөртеген аерым күтәрергә туры килде. Шул рәвешле хәтсез вакыт үтте. Кабер әзер булды. Ир, маңгай тирен сөртеп, җиргә утырды. Һәм бер ноктага текәлеп катып калды.

Хатын аны бераз күзәтте дә тавыш бирде:

– Әй...

– Без аны җирли алмыйбыз... – диде ир чарасыз тавыш белән. – Мин шуңа төшендем.

– Ник?

– Белмим.

Тын калдылар.

– Аксакалны хәтерлисеңме? – диде ир бераздан. – Ул ни диде?

– Мәетне сез зиратка кадәр күтәреп алып барачаксыз. – Хатын Аксакалның сүзләрен хәтерли иде. – Кабергәчә...

– Үз каберләрегезгәчә! – дип төзәтте аны ир.

Тагын тын калдылар. Хатын авыр сулап куйды.

– Җирләп карыйк, – диде ир. – Тик бернәрсә дә килеп чыкмаячак.

Хатын урыныннан кузгалды.

– Кызганыч та әле ул... Ташлап калдырасы килми...

Хатын кабер читендә яткан мәеткә чүгәләде.

– Әллә җирләмибез генәме? Мин синнән китеп карадым бит... Беләм... Моны югалтсак, бушлык кына калачак...

– Без аны җирли алмыйбыз, – дип кабатлады ир. – Һәрхәлдә, җиргә... Мәхәббәт җирнеке генә түгел...

Хатын мәетнең йөзен каплаган чүпрәкне шудырды.

– Бу егет мәеткә бер дә охшамаган... – дип пышылдады ул. – Охшамаган...

Ир дәшмәде. Ул мәетнең кыз кыяфәтендә икәнен яхшы белә иде. Хатыныннан күз алмады. Таныш сыннар, таныш сызымнар эзләде. Ә хатынның күзе мәеттә иде. Йөзендә – чиксез сагыш, ярату, моң...

– Нинди асыл егет идең бит син!.. – диде ул, күңелендә кайнаган хисләрне тыя алмыйча, һәм иренә борылды. – Нинди асыл егет!..

Һәм катып калды... Ир үзгәргән иде...

Ир хатынының бөтен булмышыннан таныш сызымнар эзләде... Һәм тапты... Еллар, гомернең адәм күтәрмәстәй авыр мизгелләре үз эшен эшләсә дә, хатынында ул яраткан сызымнар һаман исән икән ич әле!.. Караган саен, ул сыйфатлар ачыграк төсмерләнә барды. Йөзендәге җиңелчә алсулык та... Тулышкан иреннәрендәге наз да... Кыйгач кашларының шаянлыгы да... Күзләрендәге якты нур да... Боларны хәтта авыр юллар, авыр еллар да үзгәртә алмаган! Ник элегрәк күрмәгән ир бу матурлыкны! Ник элегрәк игътибар итмәгән? Хәер, болай итеп яратып бакканы юк иде дә бугай... Ул хатынына карады һәм караган саен аның яшәрә баруын тойды.

– Ә син... Ә мин...

Ир тотлыгып калды...

– Нинди асыл егет... – дип кабатлады хатын, иреннән күз ала алмыйча. – Нинди асыл...

Бар булмышын соклану, дәрт, шатлык алышытырды...

Аның каршында инде тормыш михнәтләрен кичергән ир түгел, ә бая гына табутта яткан егет тора иде. Ә үзе чиксез наз белән тулган күзләрен аңа төбәгән дә:

– Ә син... Ә мин... – дип тотлыга.

Хатын елмайды. Нәрсәдер әйтергә теләде. Әмма өлгерә алмый калды.

– Мин яратам сине! – дип пышылдады егет. – Бердәнберем минем!

Һәм әйтеп бетергесез наз белән үзенә төбәлгән кызны куенына кысты. Сөякләрнең метердәве ишетелерлек итеп кочаклады.

– Кысма, сантый... Үтерәсең бит... – дип пышылдады кыз аңа ныграк сыенып. – Үте...

Әмма сүзен әйтеп бетерә алмады, кайнар иреннәр бер-берсен эзләп тапты да, дөньяның вак-төякләрен оныттырып, мәхәббәт күгенә алып менделәр...

Кабер читендәге носилка да, анда акка төренеп яткан мәет тә юкка чыккан иде. Ул урында сизелер-сизелмәс кенә нур торып калган...

* * *

– Әнә теге парны күрәсеңме?

– Әлбәттә! Аларга игътибар итмәү мөмкин түгел, егет белән кыз шикелле... Әнә, ире тагын үбеп алды...

– Ха!.. Ире!.. Үз хатыны белән килмәгән ул монда!

– Юктыр ла...

– Аларга ничә яшь! Ким дигәндә, егерме биш ел бергә яшәгән булырга тиешләр. Ә хәзер уйлап кара, шулкадәр бергә яшәгәннән соң...

– Ә бәлки, яңа гына өйләнешкәннәрдер...

– Юк инде! Алар өйләнешкән кешегә бөтенләй охшамаган. Үзең үк егет белән кыз кебек дидең ич.

– Шуннан?..

– Билләһи дип әйтәм, әмма бу ир сөяркәсе белән килгән. Әйдә, бәхәс!

– Белмим инде...

– Бәхәс!

– Ярый. Тик ничек беләбез соң?

– Үзләреннән сорыйбыз...

* * *

Чираттагы икәү киткәч, көлешеп алдылар да хатын иренә ныграк сыенды. Артларыннан йөргән чыш-пышларга алар беркадәр гадәтләнгән иде инде.


Бу мәхәббәт кебек үк табигый күренеш иде.

Башкаларга өлкән яшьтәге абый-апа булып күренсәләр дә, аларның үз сере бар иде.

Ир хатынын һәрвакыт беренче тапкыр «яратам» дип әйткән чагындагы кыз кыяфәтендә күрә иде.

Хатыны да шулай.

Бер-берсе өчен алар һаман егет белән кыз иделәр.



Рәсем: Наталья Васильева

PRESSA.RU





## *Әнкәй*

*Әнкәй безне Сөннән алып кайткан,*
*Сөн суында юган иң элек.*
*Бишек җыры көйләп төннәр буе,*
*Без үскәнне көткән тилмереп.*

*Без биш бала үстек – бер йодырык –*
*Тик үсмәдек иркә кочакта.*
*Без әнкәйнең биш шатлыгы идек,*
*Биш кайгысы булдык кайчакта.*

*Без үскәндә күпме борчылулар*
*Күргән әнкәй гомер эчендә.*
*Онытмабыз, әнкәй, мәңге сине,*
*Рәхмәт яусын барсы өчен дә.*

*Хәзер инде җиткән балалар без,*
*Кунак кына әнкәй янында.*
*Әнкәйләрнең олы йөрәгенә*
*Изгелекнең сыйган барсы да.*

*Санап кына бетерерлек түгел*
*Әнкәйләрдән күргән изгелек.*
*Әнкәй безне Сөннән алып кайткан,*
*Сөн суында юган иң элек.*

# СӨННЕҢ ҮЗЕ КЕБЕК...

«Әнкәй» шигыренең дә, Сара апа Садыйкова язган җырның да язмышы, Әнкәйнең үзенең язмышы кебек үк, шактый катлаулы да, четерекле дә, шул ук вакытта озын гомерле дә булып чыкты. Хикмәт шунда ки, мин ул шигырьне 1968 елны Казан университетына килеп укый башлагач ук язган идем. Студентлар белән оештырган концертларда укып йөргәнем истә. Яраталар иде, үзем дә яратып укый идем. Беренче тапкыр ул (әле архивымнан эзләп таптым) Илештә, үзем эшләп киткән «Маяк» газетасында басылып чыккан. 1969 елның 14 августында. Шигырь сигез юлга озынрак, дүрт юллык эпиграф та куйган булганмын:

Без, малайлар, бөтен игелеген
Кайтарырга тиеш анага.
Җәүһәрләр дә көннән алган нурын
Бише белән бирә яңадан!

Бик образлы итеп язарга тырышканмын икән. «Җәүһәр» дигәне

Әнкәем Гөлҗәүһәргә ишарә булгандыр инде. «Бише белән» дигәне биш баланы аңлатадыр, билгеле. Соңыннан ул дүрт юлны ни өчендер төшереп калдырганмын, бераз үзгәртеп, аерым шигырь итеп калдырганмын.

Өйрәткән ул безне
Көләргә дә,
Ничек итеп «әннә» диярргә,
Уңны-сулны бутамыйча ничек
Аяк киемнәрен кияргә...

Бар булганын Әнкәй бишкә
бүлгән,
Үзен генә никтер оныткан.
Авырлыктан курыкмаган Әнкәй,
Безнең өчен һәрчак курыккан...

Әлеге юллар да төшеп калган, башка беркайчан да басылмаган.

«Әнкәй»нең китапларымда басыла торган хәзерге варианты беренче тапкыр 1971 елның 15 маенда «Кызыл Таң» газетасында басылып чыкты. Шунысы кызык: мин ул шигырьнең ахырына тагын дүрт юл өстәгәнмен икән. Шуңа күрә дә ул «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан, Сөн суында юган иң элек» дип башлана да шул ук сүзләр белән тәмамлана. Шушы ук редакциядә ул шул ук елның 23 октябрендә «Татарстан яшьләре»ндә дә басылды. Хөрмәтлебез Сара апа Садыйкова аны нәкъ менә «Татарстан яшьләре»ндә басылганнан соң күреп кала да инде.

Сара апа, үзе дә шигырьләр язган кеше булгангадыр инде, шигырьләрне үзенә яраклаштырып үзгәрттерергә ярата иде. «Әнкәй»не дә шактый үзгәрттерде: бер өлешен алып ташлатты, тагын дүрт юл өстәтте. Нәтиҗәдә, әле җырлана торган вариант килеп чыкты. Дөрес, анда да кайбер сүзләрне һәрбер җырчы үзенчә үзгәртеп җырлый башлады. «Әнкәй» ноталары белән иң элек «Азат хатын» журналында басылып чыкты. 1977 елда «Татарстан яшьләре»ндә дә ноталары белән яңадан бер тапкыр басылды. «Әнкәйләрнең олы йөрәгенә / Яхшылыкның сыйган барсы да» дигән ике юл анда ни өчендер «Әнкәйләрнең олы йөрәкләре / Яхшылыкның җыйган барсын да» дип язылган иде. «Без биш бала үстек – бер йодырык» дип тә, «Без биш бала үстек Әнкәй белән» дип тә җырлыйлар. Җырласыннар гына, мин үпкәләмим...

Мин ул шигырьне «Идел» журналына да биргән идем. Ләкин аны печеп чыгардылар. Мөхәррир «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан» дигән сүзләрне ошатмаган. Шуңа күрә шигырьнең беренче дүрт юлын һәм соңгы дүрт юлын бөтенләй төшереп калдырганнар иде. Кычкырып еламадым гына... Шигырьне, җырны тотып торган нәкъ әнә шул юл өчен җырыбызны радионың худсоветыннан да шактый еллар үткәрмәделәр. Янәсе, хакыйкатькә туры килми. Әхсән Баянның минем хакта язылган бер мәкаләсендә шундый юллар да бар: «Композитор Сара Садыйкова язган «Әнкәй» исемле җырның аягы җиңел булды. Робертка ул шул жанрда эшләү өчен юл ачты кебек. Хәзер дә истә әле, Татарстан радиосының сәнгать советында җитәкче иптәшләрнең берсе: «Нишләп әле баланы судан табалар, инде безне дә, зурларны да алдап буламыни?» дип, «җитди» сорау куйган иде. Могтәбәр җитәкчегә шигъри шартлылыкның табигый икәнлеген шундый ук җитдилек белән аңлатканымны хәтерлим. Әсәр фондка кертелде һәм тиз арада танылып өлгерде». Җыр, чыннан да, халык арасында бик тиз таралып китте, татар белән башкортның яраткан җырына әверелде. Яшьрәк чагымда, очрашуларга баргач, мине һәрвакыт: «Менә бу шагыйрь «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан» дигән җырның авторы була инде!» – дип таныштыралар иде. Шулай да дигәч, мин инде, үземнең чыгышымны, бик рәхәтләнеп, әнкәй турындагы шул шигырем белән башлап җибәрә идем. Шактый еллардан соң миңа телевидениедә баш мөхәррир булып та эшләргә туры килде. Укучылар белән очрашуларда мин «Әнкәй»нең язмышы турында сөйләгәндә уенычыны белән шушы мисалны китерергә ярата идем. Партия җыелышларының берсендә партоешма секретаре торып бик җитди рәвештә: «Роберт Миңнуллин очрашуларда радиокомитетны хурлап, тәнкыйтьләп йөри икән, аңа выговор бирергә кирәк!» – дип сөйләгәнен һич кенә дә онытасым юк.

Шулай... «Әнкәй»не тәнкыйтьләүчеләр дә булды, мактаучылар да... Рәхмәт сүзләре дә күп ишеттем. Остазларым да, әдәбият галимнәре дә, минем турыда яза башласалар, сүзләрен иң элек җырга әйләнгән шушы шигыремнән башлыйлар иде. «Әнкәй» хәзер күптән инде үз язмышы белән яши. Сара апа да күптән гүр иясе, Әнкәем дә мәрхүмә булып куйды. Урыннары җәннәттә булсын! Ә җыр озын гомерле булып чыкты, әле дә яши: җырлыйлар, тыңлыйлар. Шигыренең дә, җырының да язылуына берничә елдан, Ходай кушса, ярты гасыр була икән инде... Аны ишеткән саен үземнең сөекле әнкәем Гөлҗәүһәр белән сөекле композиторыбыз Сара апа Садыйкова күз алдыма килә, аларның икесенә дә рәхмәтләремне укыйм! Күңелләр тула, эчемнән генә, үзем дә сизмичә, шул җырны җырлый башлыйм: «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан, Сөн суында юган иң элек...»

«Әнкәй» җыры, Сөннең үзе кебек, тын гына, моң гына ага да ага, агыла да агыла...

Роберт МИҢНУЛЛИН,
Татарстанның халык шагыйре.



PRESSA.RU

РУШАНИЯ. ГОМЕРЕ БУЕНА НУР ЧӘЧЕП, ДӨНЬЯНЫ ЯКТЫРТЫП ТОРСЫН ДИП, ӘТИ-ӘНИСЕ ШУНДЫЙ ЗАТЛЫ ИСЕМ САЙЛАГАНДЫР АҢА. ИСЕМЕНДӘ – ҖИСЕМЕ! КАЙДА ГЫНА БУЛСА ДА – ӨЙДӘМЕ, ЭШТӘМЕ, ГАИЛӘДӘМЕ, ЕРАК СӘФӘРДӘМЕ – УЛ САКЛАУЧЫ ФӘРЕШТӘ!

Фәйрүзә МӨСЛИМОВА

# РУШАНИЯ

Салихҗанга бәхет эзләп чыгып киткән дусты Фәһимнән хат килә. Казакъстаннан. Эш тә күп, түләве дә ярыйсы, дигән. Чирәм җирләр яңа үзләштерелә башлаган еллар бу. Салихҗан ул якларга кузгалганда, икенче бәбиләре – Рушания дә туган була инде... Әтисе сөйләгәннәрдән Рушания барысын да ап-ачык күз алдына китерә. Аның Павлодар шәһәренә китеп барулары, «Монда татарлар яшәмиме?» – дип сорашып йөреп, әйбәт бер татар гаиләсенә фатирга керүләр...

Берничә айдан гаиләсен дә алып килә Салихҗан. Хатыны Кафия белән үзләре фатир торган Мингалим агай белән Миңҗамал апалар өенә кушып, аерым куыш коралар. Бервакыт, уңайлыклары булган фатирлар бирергә дип, яшәр урыннары булмаган гаиләләрне исәпкә алып йөриләр. (Нинди заман!) Гаилә башлыгы шунда ук баш тарта: үз йортын салып керәчәк ул! Бераздан Алтай якларыннан шыңгырдап торган нарат бүрәнәләр кайтартып, йортны салып та куялар.

Рушан белән Рушания янына гаиләдә тагын бер малай – Сирин туа. Балалар рус мәктәбенә укыса да, өйдә татарча гына сөйләшәләр. Җәйге каникулларында әбиләре, анда калган туган-тумача ягына – Тәтешнең Келәшенә кайталар. Авылда кыр-бакча эшләре төгәлләнүгә, Келәшләр поезд белән Павлодарга килә. Казакъстан белән Татарстан арасындагы юлга тузан да төшми.

Тик... яхшы булса да торган җир, сагындыра туган җир, диюләре хак шул. Балаларын укытырга тырышкан Шәмгуновлар аларның туган якларга кайтып урнашуын тели. Рушаннары Новосибирскидагы югары хәрби-сәяси училищега укырга керә. Бәлки Рушания Казанда укыр? Тора-бара аның янына күчеп булыр?

Димәк, Казанга, мәдәният институтына документларын тапшырырга килгәндә, Рушания үз хыяллары янына әти-әнисе хыялын да сыйдырган булып чыга. Мәктәптә әйбәт укыган һәрьяктан сәләтле кыз югалып каламы соң инде? Имтиханнарын русча тапшырса да, «мастерство» дигәненнән Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры» әсәреннән өзекне русча яттан сөйләп керсә дә, аны татар төркеменә теркиләр. Атаклы режиссёр Ширияздан Сарымсаков төркеменә. Тик татарча аралашусөйләшү бер хәл, уку һәм язу бөтенләй башка икән шул. Беренче тапкыр пьесаны рольләргә бүлеп укыганда, төркемдәшләре рәхәтләнеп көлә үзеннән. Беренче һәм соңгы тапкыр. Рушания моннан соң нәрсә укыячакларын алдан өйрәнеп куя торган була.

Үзешчән театрлар фестивальләре дә булачак режиссёрлар игътибарыннан читтә калмый. Бервакыт шул фестивальгә Актаныш театры да килә. Спектакльне Фаил Ибраһимов – институтны Рушаниядән алданрак тәмамлап киткән Илфак исемле егетнең абыйсы куйган икән. Илфак та алар белән. Рушаниянең практикага кая барырга дип уйланып йөргән чагы. Абыйлы-энеле

Ибраһимовлар: «Бары тик безгә генә!» – дип чакыралар. «Ярый, сезгә тек сезгә...» Салкын февраль аенда ул, самолётта очып, беренче тапкыр Актаныш җиренә аяк баса. Нинди спектакль куячагы да билгеле инде. Атилла Расихның «Ике буйдак» романы буенча остазы Шириаздан Сарымсаков инсценировкасын сәхнәләштерә. Актаныштa сәнгать сөюче халык яши. «Артистлар» Рушания җитәкчелегендә бик яратып уйныйлар, үзе дә яраттыра белә шул. Фаил абыйсы да, укуыңны тәмамлагач, монда кайтырсың, дип тора. Ә Илфак... Рушаниянең чыгарылыш кичәсенә килә дә, шул көнне үк аны теплоход белән үзләренә алып кайтып китә. (Әйе, әйе, Актанышка самолёт белән очып та, теплоходта йөзеп тә барып булган чаклар!) Дербёшка пристанена төшкәч, Чалманарат авылына юнәләләр. Мөсәвәрәбианай да, туганнары да сөенеп каршылый аларны. Илфак өйләнеп кайткан икән, килен бигрәк яшь икән, дигән сүз тарала. Мөсәвәрә апа: «Буйга гына бәләкәй ул, укуын тәмамлап кайтты инде», – дип аңлата. Рушаниянең Актаныш тормышы әнә шулай башланып китә.

Яшь гаиләгә тулай торактан бер бүлмә бирәләр. (Тора-бара аларның үз фатирлары, аннары үзләре салып керәчәк бүрәнә йортлары да булачак, әлбәттә.) Инде армиядә дә хезмәт итеп кайткан Илфак җирле радиода эшли. Фаил абыйларының Рушанияне спектакльләрендә уйнатасы килсә дә, сабыр итеп торырга булалар: беренче кызлары Гөлназ туа. Ел ярым узуга инде малай алып кайта Рушания. Гадел дип исем куялар. Бераз көттереп Айсылу туа. Һәркайсы үзенчә яраттыра. Казан университетының татар әдәбияты һәм тарихы факультетын тәмамлаган төпчекләре укуын Төркиядә дәвам итәргә теләгәч, бер дә җибәрәселәре килми инде! Әмма бәндәне ризыгы йөртә, диләр. Айсылу Төркиядә яши хәзер. Айсылуга да әнисе кебек үк әти-әнисеннән еракта гомер итү язган, күрәсең.

Рушанияне дә язмыш үзе сайлаган сукмагыннан чыгармый. Төп эше белән беррәттән, Пионерлар сараенда (анысы да Мәдәният йорты бинасына сыйган) театр түгәрәге оештырып җибәрә. Иң элек А. Сент-Экзюпериның «Нәни принц» әсәренә нигезләнеп, «Чулпанның йолдызларга сәяхәте» дигән пьесаны сәхнәләштерәләр. Шигырьләрен яшь шагыйрә Эльмира Җәлилова, музыкасын Актаныш композиторы Инсаф Хәбибуллин иҗат итә. Куелыш тамашачыларга да, «артистларның» үзләренә дә бик ошый. Алабугада узган зона фестивалендә беренче урынны да алып кайталар.

«Шүрәлеләр үч алмый» дигән пьесаны аның авторы, шагыйрь Рөстәм Мингалим үзе бүләк итә. Басылып чыгарга да өлгермәгән килеш. Хәйрия максатында күрсәтелгән спектакльдән җыелган акча Колшәриф мәчете төзелешенә иганә ителә.

Илфакны Актанышның комсомол райкомына беренче секретарь итеп сайлыйлар. Эшләре бетмәс-төкәнмәс, туктаусыз командировкаларда йөри, әледән-әле килеп торган кунакларны да кабул итә. Ирең кеше арасында ким-хур булмасын дисәң, аңа фикердәш һәм ярдәмче булырга да кирәк. Бик кыен вакытлар булып, нервылар киеренкеләнсә, Рушаниянең серле бер чарасы бар – ул бәйләргә ярата. Ире белән улына пардан нинди матур жилетлар бәйләп кидерде! Илфак кая барса шуннан Рушаниягә җепләр алып кайта. Кайнанасы да, Рушаниягә дип, сарык йонын махсус нечкә итеп эрли. Илфаклар унбер туган, кайнанасы кайсына гына булышып өлгерсен югыйсә? Ә бит Илфак хатыны белән икесенә теплоходта ун көнлек сәяхәт тәкъдим ителгәнен әйткәч, әни кеше өч яшьлек Гөлназ белән ике яшьлек Гаделне берсүзсез алып кала!

Болар барысы да – тормыш прозасы. Әмма Ибраһимовлар иҗат дөньясыннан аерылмыйча яши. Күпмедер еллары район эчке эшләр бүлегендә кырыс тормыш мәктәбен узуга багышланса да, Илфакның күңеле шигырьләр белән тулып тора. Үзе дә район газетасы каршындагы «Агыйдел дулкыннары» иҗат берләшмәсенә җитәкчелек итә башлый. Шул чакта Илфакны район мәдәният бүлеге мөдире итеп, Рушанияне балалар сәнгать мәктәбенә эшкә билгеләүләре бик тә табигый кабул ителә. Иҗат белән шөгыльләнүчеләрнең берсе дә аларның игътибарыннан читтә калмый. Тукайның тууына 100 ел тулуга багышланган чарадан соң урамда шигырь бәйрәмнәре уздыру традициягә әйләнә. Барлык бәйрәмнәргә дә сценарийларны Ибраһимовлар яза, алар оештыра.

*Балалары һәм өч оныгы да күп яктан аннан үрнәк алырга тырыша.*

Илфак Казанга, Республика мәдәният министры урынбасары итеп билгеләнгәч, Рушаниягә балалар белән Актаныштa калып торырга туры килә әле. Ә инде Казанга күчеп килгәч, күңеленә хуш килердәй эш табыла: Казан театр училищесы студентларын актерлык осталыгына укыта башлый. Шул ук вакытта күренекле язучы-шагыйрьләрнең иҗат кичәләрен әзерли.

Өйләнеп карасаң, сынаулар да, үкенечләр дә булмаган түгел. Туган якка кайту турында хыялланган әтисе, кызы институтта укыган чакта ук яман чирдән Павлодарда вафат була. Кайнанасын да шул ук авыру алып китә. Олы яшькә җиткән әнисе инсульт кичерә. Рушания, Казакъстанга китеп, аны бер ай карый да, ире һәм балалары белән киңәшеп, Казанга алып кайта. Әни кешене вафат булганчы үзләрендә тәрбиялиләр.

...Авылда Рушания туган йортны сүтүләре турында әйтәләр. Соңгы елларда анда яшәүче дә булмаган инде. Ә йортның нигезеннән табылган бакыр тәңкәләрне һәм саргаеп беткән кәгазьдәге доганы Рушаниянең үзенә тапшыралар. Менә шулай. Кайчандыр (нинди максатлар хакына икән?) өр-яңа килеш ташлап кителгән йортның бүгенге көнгә килеп җиткән моңлы кайтавазы була ул.

Ә гомер дәвам итә. Рушанияне мин беркайчан да югалып калмый торган тәвәккәл, зирәк кеше дип беләм. Аның белән ерак сәфәрләргә чыкканым бар. Ул чыннан да ышанычлы юлдаш, аңа таянырга була.

PRESSA.RU



Фото интернеттан алынды

Әнием һәм дәү әнием белән яшим мин. Кечкенәдән бер минут буш вакытым булмасын дип, алар икесе дә тырышты: түгәрәкләргә йөрдем, музыка мәктәбендә укыдым – фортепианода уйнарга өйрәндем. Фәнни конференцияләрдә чыгыш ясадым. Миңа бөтен нәрсә кызык иде!
Холкым шундый – ирешелгәннәрдә тукталып калмадым. Хәер, монысы өчен иң элек әнигә рәхмәт: күңелем кая тартылганны үземнән дә алданрак аңлап, ул гел миңа юнәлеш биреп торды. Өйдәгеләрнең үземне яратуын тоеп үстем. Бар да әйбәт булгач, нәрсәгә язасың соң, дисезме? Игътибар иттегезме: әнием һәм дәү әнием белән генә торам дидем. Әтине телгә алмадым.
Юк, юк, аның белән бернәрсә дә булмады, ул исән-сау – бер шәһәрдә яшибез. Сирәк кенә булса да, без хәтта күрешәбез дә. Әмма мин аңа бөтенләй кирәкмим бугай...

# МИН ӘТИГӘ КИРӘКМИМ...

Минем әти хәрби кеше, рота командиры. Әни белән алар аерылыштылар. Теркәлгән никахларның яртысына якыны таркалган заманда яшибез – әллә ни зур яңалык түгел, диярсез. Анысы шулай... Әмма безнең аралар салкынаюга аның әнидән аерылуы гына гаепле түгел бугай. Әтинең үземне якын итүен, яратуын кечкенә чагымда да сизмәдем. Миңа тартылуын тойсам, мин моны берничек оныта алмас идем... Юк, ул мине кыерсытмады, какмады. Һәм шул ук вакытта, башка әтиләр кебек: «Балам!» – дип өзелеп тә тормады.

Без бабайлар белән күрше генә урамда яшәдек. Якын булгач, еш керә идем аларга. Әтине дә очраткалыйм. Аны анда күреп торгач, әни белән аерылышканнарын бик озак аңламадым әле. Биш яшьлек сабыйга соң! Әти бабайлар йортына кайтып керсә, куанып каршысына йөгерәм, кочаклап алам. Дус кызларымны әтиләре күтәреп ала, битләреннән, чәчләреннән үбә – мин дә шуны көтәм... Ә ул мине шунда ук читкә этә: «Булды, кызым, булды...»

Назлавын бик озак көттем мин аның. Хәзер туктадым. Әтинең күптән инде башка гаиләсе бар, улы үсә – ул анда бәхетледер дип беләм. Сирәк кенә әбиләрдә очрашабыз, әмма мин аңа хәзер элеккеге кебек ярату өмет итеп карамыйм инде.

Кыз балага бик тә кирәк булган ата назын тоймый үсүем бер нәрсә. Янымда әти дигән кешем булмавы мине тагынниләрдән мәхрүм итүен торып-торып аңлыйм. Әйтик, гади генә бер мисал. Бер танышымның туган көненә барган идем. Табын янында утырганда, әнисенә булышыйм, дип, кече якка чыктым. «Ир-ат күп ашый», – дигән сүзне миңа кем әйткәндер, белмим, әмма колагыма кергән – яхшы хәтерлим. Кыскасы, дустымның тәлинкәсенә тау кадәр итеп өйдем ризыкны! «Бу кадәрне кем ашасын?!» – дип, ул аның яртысын китереп кире кәстрүлгә бушатты...

Яки менә тагын бер очрак. Очрашып йөри башлаган егетем безгә килергә тиеш иде. Аш куйдым. Өйдә хатын-кызлар гына дип, башка вакытта да шулпа ашамыйча тормыйбыз инде – пешерәбез. Әмма без ашка итне бик аз салабыз икән. Мин моны егетемнең йөзенә карауга аңладым... Ул аны мин үпкәләмәсен өчен кызык бер мәзәккә әйләндерсә дә, бу миңа тагын бер сабак булды. Алай икән...

Минем моңарчы бер тапкыр да ир-атка нинди дә булса кием-салым сатып алганым булмады. Сыңар оек та! Кемгә алыйм мин аны? Шуңадыр егетемә беренче тапкыр бүләк сайлау куаныч та булды һәм... куркыныч та. Кибет уртасына басып, аптырап шактый басып тордым: «Ошатмаса? Яратмаса? Аңа туры килмәсә?»

Моңарчы ир-ат кулмәген үтүкләргә дә туры килмәде. Быел менә миңа үз гомеремдә беренче тапкыр: «Матурым, ә син кулмәгемне үтүкли алмассыңмы?» – диделәр. Бик батыраеп: «Үтүклим, нигә үтүкләмәскә?!» – дидем. Үзем уйлыйм: «Иң мөһиме – яндырмаска!» Яндырмадым анысы... Ул теләгәнчә үк килеп чыкмаса да, икебез дә бәхетле булдык: мин – шушы эшне башкарып чыкканыма, ә ул – аның өчен мин нидер эшләгәнгә.

Ә болай ир-ат эшеннән куркып торганым юк минем. Ярдәм күтәр җиребез булмагач, барысына да гел үзебез тотынабыз: җир дә казыйбыз, агач та кисәбез, утын да өябез, койма да тотабыз... Шәһәр җирендә үз йортың белән яшәгәч, мондый эшләр гел чыгып кына тора бит ул. Шулай яшибез: дәү әнигә – 80, әнигә – 40, миңа – 20 яшь. Олы булса да, дәү әнинең тик торган минуты юк әле аның: әле өчпочмак пешерә, әле бәлеш. Әни бюро җитәкчесе булып эшли. Эштә дә, гаилә дә аның өстендә җаваплылык зур. Шуңа кырысрактыр да ул. Әмма кирәк чакта баштан да сыйпый белә. Ә мин әлегә студент. Сезгә күңелемне бушаттым да җиңел булып китте менә...

Альбина.
Казан.



Айсылу НӘГЫЙМОВА, психология фәннәре кандидаты, социология фәннәре докторы, профессор:

Ата белән бала мөнәсәбәте... Беренче карашка бу өлкәдә берниндм проблема булмаска тиештер кебек. Хәтта бала инде күптәннән әтисе белән яшәмәсә дә... Әмма тормышта бөтенләй башкача килеп чыга шул. Кызганычка каршы, гаилә таркалуны күп ирләр хатыны белән генә түгел, ә бәлки үз балалары белән дә аерылышу дип кабул итә. Ә кайбер очракта моңа аларны хатын-кыз үзе этәрә – бала ир белән хатынның бәхәс үзәгенә әйләнә. Янәсе, минем белән яшәмисең икән, димәк, баланы да күрсәтмим, безгә синсез дә бик рәхәт! Ә баланың күңелендә нинәр барлыгы әни кешене аз кызыксындыра.

Баланың психик, эмоциональ яктан дөрес формалашуы өчен аның тулы гаиләдә, әтисенең дә, әнисенең дә мәхәббәтен тоеп үсүе зарур. Гомумән, тыныч мохиттә, дус-тату мөнәсәбәт хөкем сөргән гаиләдә үскән бала киләчәктә күп хәтәрләрне урап узарга сәләтле була, тормыш сынауларына да андый балалар бик бирешми.

Ир кешенең гаиләдә тоткан урыны ул әле матди якны кайгырту гына түгел, бәлки балаларында дөрес ир-ат образы формалаштыру да. Малай кеше әтисеннән ирләргә генә хас сыйфатларны үзләштереп, киләчәктә шул модельне тормышта кулланса, кыз балага әти белән аралашу, бигрәк тә булачак партнер образын формалаштыру өчен кирәк. Моннан тыш, әтиле гаиләләрдә балалар үзләрен якланган итеп хис итә, психик яктан тотрыклы, үз-үзенә ышанган шәхес буларак формалаша.

Әлеге язмадан күренгәнчә, кызыкай нәкъ менә әтисе белән уртак мөнәсәбәтләр булмауга, аның яратуын тоймауга үртәлә. Кечкенә кызчыкка әтисенең сөеп-иркәләүләре җитмәгән булса, инде буйга җиткән кыз үзенең ир-атлар белән мөнәсәбәтләр төзегәндә хәбәрдарсызлыгына борчыла. Тулы гаиләдә үскән кыз балага гаять табигый күренгән күп кенә нәрсәләр анда курку, үз-үзенә ышанычсызлык хисләре уята. Шундый ук хәлне үз башыннан кичергән балалар, үсеп җитеп, гаилә төзегәндә дә күптөрле каршылыкларга, проблемаларга тап булучан һәм еш кына хәлдән чыгу юлын да таба алмыйлар...

Гаиләсе таркалып бер ялгызы бала тәрбияләргә дучар булган ханымнарга берничә киңәш бирер идем.

■ Ирегез белән мөнәсәбәтләрегез бозылуга балалар гаепле түгел. Баланың әтисе белән дә, әнисе белән дә бер дәрәҗәдә аралашырга хакы бар. Ирегезнең балагыз белән аралашуына каршы килеп, сез беренче чиратта балагызга начарлык кыласыз, аның, тулы мәгънәсендә, камил шәхес булып формалашуына киртә куясыз.

■ Ирегез бала белән аралашырга теләмәгән очракта да үзегез күпмедер дәрәҗәдә инициатива күрсәтеп, балагызның әтисе белән мөнәсәбәтләрен җайларга тырышыгыз. Аңлыйм, күп очракта моны эшләү үтә дә кыен мәсьәлә булырга мөмкин, шулай да балагызның киләчәге өчен бу адымның бик тә мөһим икәнлеген онытмасагыз иде!

■ Ата белән бала мөнәсәбәтләрен тергезү яки саклау мөмкин булмаган очракта янигызда бала өчен ир кеше образын формалаштырырга сәләтле кеше кирәк: баланың дәү әтисе, еш аралаша торган туганнар, дуслар... Шунысы әһәмиятле – ул ир-ат бала тормышына чын мәгънәсендә уңай йогынты ясый алсын, бала өчен хөрмәткә лаек шәхес булсын иде.

PRESSA.RU



# «АМЕРИКА ӘКИЯТЕ»



Айбикә ФӘТТАХОВА

## САМОЛЕТ ТӘРӘЗӘСЕНДӘ НЬЮ-ЙОРК УТЛАРЫ БИЕШӘ.

**Ә йөрәк әкияткә килеп эләгәчәк мизгелләрне саный: аэропорт залында безне көтеп торучы чибәр егет, кабриолет, пальмалар, бер якта – шау-шулы шәһәр; икенче якта – океан... Фильмнарда шулай тасвирлана лабаса!**
**Тик бу картина хыялда гына кала. Америка безне борынын җыерып, теләр-теләмәс кенә каршылый. Аэропорт залында «Айбикә» дигән язу тоткан чибәр егет тә, башка берәр каршылаучы да күренми...**

### Билгесезлеккә карап...

Студентларның «Work and Travel» программасы буенча Америкага килергә уйлавыма шул чакта беренче тапкыр бик үкендем кебек. Хәер, Казан–Мәскәү поездына утырып сәфәрне башлаганда ук бар иде ул үкенү хисе. «Нәрсәгә кирәк инде бу сиңа, Айбикә?! Студент буларак соңгы каникулыңны рәхәтләнеп Казаныңда, әти-әниең янында гына уздырырга ярамаганмыни?!» – дип, юл буе үземне битәрләп бардым бит. Самолетка утыруга үкенүем юкка чыкты. Озакка булмаган икән.

Без икәү: мин һәм юлдашым Лиана. Аның да «Американы яуларга» дип килүе. Көчкә автобус табып, Бостонга кузгалабыз, аннан икенче транспортка утырып, билгеләнгән ноктага – Массачусетс штатының Уэлфлит шәһәрчегенә барып җитәбез. Монда эш бирүчебез каршы ала. Без инде йончыган, кәеф тә кырылган, кая алып барсалар да риза. Ятып йокларга урын гына булсын!

Бер йортка килеп керәбез. Шушында яшиячәкбез икән. Бездән кала анда тагын Тайландтан килгән өч кыз торачак. Танышабыз, тик исемнәре шундук баштан чыгып оча. Җитәкчебезнең: «Иртәгә иртәнге 8 дә күрешербез!» – дигән сүзе дә аңга барып җитми әле. Ул чыгып китүгә, караватка авабыз. Бу мизгелдә безгә бернәрсә дә кирәкми...

Әлбәттә инде, иртән уяна алмыйбыз. Менә шул чакта әкият башлана да инде. Ишек шакыйлар. Йокылыуяулы хәлдә барып ачабыз. Ә анда бер чибәр егет басып тора! «Сәлам, кызлар! Мин бүген сезне озатып йөрермен», – дип елмая. Йокы ачыла. Тиз генә җыенып, егеткә ияреп чыгып китәбез.

Без яшәячәк йорт урман эчендә икән. Документларны теркәү озакка сузылмый. Эшне бетергәч, чибәр егет шәһәрне күрсәтергә алып китә. Уэлфлит зур һәм бай авылны хәтерләтә. Ике катлы җыйнак йортлар агачлар эчендә посып утыра. Шәһәрнең машина төтене белән агуланмаган саф һавасын күкрәк тутырып сулыйбыз. Кул сузымында гына океан җәйрәп ята. Чү, тюленьнәр дә күренә түгелме?! Менә монысы



безнең хыялдагы Америка! Оҗмахка эләктек бугай, дип шатланырга да өлгерәбез әле... Их, нигә әкиятләр шулай кыска соң синдә, Америка?

### «Качарга кирәк!»

Ә икенче көнне эш башланды. Америкада үткәрәчәк өч ай ярым вакыт эчендә мин хаускипер булачакмын (аларда «җыештыручы» димиләр, шушылай матурлап әйтәләр). Акча эшләүне төп максат итеп куймадым, минем өчен иң мөһиме сәяхәт итү: илне күрү иде.

Тик эш без уйлаганнан күпкә катлаулырак булып чыкты. Уэлфлиттагы йортларның күпчелеген арендага алып яшиләр. Әйтик, бер гаилә килеп бер атна яшәп китә. Икенче гаилә килеп урнашканчы, без йортны ялт иттереп җыештырып чыгарырга тиеш. Хаускиперлар килгәнче, хуҗабикәләр үзләре үк җыештырып куйган була – беренче гаҗәпләнү шул булды. Тик барыбер: «Монда чиста бит инде», – дип утыра алмыйсың. Килешүдәге «хаускиперның бурычлары» дигән бүлектә нинди эшләр күрсәтелгән, барысын да үтәргә тиешсең. Җитмәсә, тиз-тиз эшләргә кирәк. Минем алай җентекләп хәтта үз өемне дә җыештырганым булмады! Беренче йортны җыештырып чыкканда эт булып арган идем. Ә көненә барлыгы биш-алты йортка бару каралган.

Беренче көн дә, атна да, икенчесе дә бик авыр үтте. Физик яктан гына түгел, рухи яктан да кыен иде. Эштән бушап, ял итәргә утыргач, күз алдына өй, әти-әни, Казан килеп



баса. Сагынуга чыдап булмый башлый. Без килгән май аенда Уэлфлитта әби-бабайлар гына иде. Башка шәһәрләрдә укучы яшьләр әле кайтып җитмәгән. Шуңа күрә бернинди күңел ачу чарасы да оештырылмый. «Ял көне монда кая барып була?» – дигән сорауга өлкәннәр: «Чиркәүгә», – дип җавап бирә. Чөнки шәһәрдә башка барыр урын да юк.

*Бездә адым саен күгәрчен булса, анда тиен икән. Курыкмыйлар да, рәхәтләнеп йөриләр.*

Мин мондый тормышка әзер түгел идем. Җитәкчемнән сорап, өч көнгә ял алдым һәм Нью-Йоркта яшәүче дус кызым янына чыгып киттем. Нәкъ Сабан туе оештырылган көнгә туры килдем. Мин белгән уен-гадәтләр, миңа таныш тел, миңа якын кешеләр – болар барысы да Америка уртасында! Рәхәтләнеп күңел ачып, кире Уэлфлитка кузгалганда, ныклы карарым әзер иде инде: качарга! Бу кечкенә күңелсез шәһәрдән качарга да кайнап торган Нью-Йоркка килеп урнашырга. Яңа тормыш башларга!

Тик җитәкчемә бу карарымны әйтә алмадым. Күпмедер вакыт эшләргә дә, ял алган булып, Нью-Йоркка китеп барырга, дип план кордым. Эш таба алсам, шунда урнашып та калырмын янәсе.

PRESSA.RU









Ләкин Уэлфлит үзгәргән иде. Каникул башланган, шул сәбәпле шәһәрчек яшьләр белән тулган, җанланган. Яңа дуслар барлыкка килде, күңел ачу чаралары оештырыла башлады. Баштарак авыр тоелган эш тә ничектер җиңелрәк, хәтта яратып башкарыла иде. Алган билетым әрәм булмасын, дип, теләмичә генә чыгып киттем Нью-Йоркка. Бу мегаполисны үз итәр өчен биш көн вакытым бар иде.

*Кечкенә шәһәрдә бөтен кеше бер-берсен белә бит, «аның өе пычрак» дигән сүз тарала күрмәсен!*

### *Кунакка – карабодай боткасы*

Нью-Йоркның үз кагыйдәләре икән. Мин аларны кабул итә алмадым. Официант булып урнашып карадым, тик ул эшем барып чыкмады. Карыйсын – карап, күрәсен күреп бетердем дә, дус кызыма ахыргы карарымны әйттем. Кире кайтып китәм! Шушы вакыт эчендә үз өемә әйләнгән Уэлфлитка! Кайсы шәһәрнең йөрәгемә якынрак икәнлеге чагыштыруда беленде.

4 июль – Америка Кушма Штатларының бәйсезлек алган көне. Бөтен кеше бәйрәм итә. Ә мин коеп яуган яңгыр астында көч-хәл белән такси тотып, Уэлфлитка кайттым. Безнекеләр дә ял итәргә киткән, ишек бикле. Телефоным юк. Кухня тәрәзәсеннән керергә туры килде. Караватыма аудым да: «Өйдә ничек рәхәт!» – дип уйлап куйдым. Менә шул көннән минем өчен рәхәт тормыш башланды.

Без яшәгән Массачусетс штатында законнар бик көчле иде. Өч ай ярым яшәдем – шул вакыт эчендә бер генә тәртип бозу очрагы да күрмәдем. Әйтик, безнең шәһәрдә кешеләр көндез өй ишекләрен бикләми дә иде. Кемгә телисең, шуңа барасың да керәсең. Күпчелек рестораннарда – ике ишек: берсенә «Керү», икенчесенә «Чыгу» дип язылган. Бервакыт «Чыгу» дигән ишектән кергәч, миңа бөтен халык аптырап карады. «Кайсыннан керсәң дә барыбер түгелмени?» – диюемне дә аңламадылар. Ничек язылган, шулай эшләргә күнеккән шул алар. Безнең төнлә океанда коенуыбызны да кабул итә алмадылар. Алар өчен бу бөтенләй кыргый күренеш иде.

Америкада закон каршында барысы да бертигез. Анда хезмәтнең ояты юк. Әйтик, безнең белән бергә хаускипер булып бай балалары да эшләде. Әти-әни биргән акчага эшләмичә яшәү дигән нәрсә юк анда. Без ул бай балаларының йортында җыештырсак, алар үзләре күршедәге икенче йортта җыештыра иделәр.

Беркөнне килдем дә менеджерга арыдым дип зарландым. «Башка алай димә, арыганыңны кычкырып әйтә күрмә», – ди. Анда эш изге санала. Көндәшлек зур, шуңа күрә кешеләр эш урыннарына теш-тырнагы белән ябышып ята. Арыдым дип зарлану эшеңне хөрмәт итмәү булып санала икән. Баштарак без: «Эшкә килербез дә, вакыт үтсенгә селкенеп тик йөрербез инде», – дип уйлаган идек. Кая эләккәнебезне аңлагач, бу уй бик тиз онытылды.

Без Америкага үзебез белән күп итеп ярмалар һәм... шампунь алып килгән идек. Шампуньнар бик кыйммәт, ә ярмалар бөтенләй юк, дип кисәттеләр бит. Бактың исә, анда да нәкъ бездәге бәяләр икән. Бөтен ярма диярлек бар, карабодай гына юк. Үзебез белән алып килгән карабодай америкалыларны шаккаттыру өчен бик ярап куйды әле. Кунак килсә, гел шуны пешерә идек. Баллы ризык дип уйлаучылар да, берәмтекләп ашап утыручылар да булды аны. Америкада чәй эчмәүләренә озак күнектек. Без, татарлар, утырган саен чәй эчәбез бит. Ә анда салкын тиеп авырып китсәләр генә эчәргә мөмкиннәр.

Бервакыт Россиядән килгән дүрт кыз бер американ дустыбызның йортында кундык. Иртән торып чыксак, ашап утыра болар, ә безгә бернәрсә әзерләмәгәннәр. Аларда кешене кунак итү гадәте юк. Үзебез белән булган ике йомырканы дүрткә бүлеп ашарга туры килде.

Эшләргә тиешле өч ай ярым вакыт үткәч, тагын ике атна Америка буйлап сәяхәт иттек әле. Бу илгә килгәндә: «Нәрсәгә кирәк инде бу миңа?» – дигән уйның әсәре дә калмаган иде. Аның урынына күптән: «Мин, һичшиксез, сиңа тагын киләм әле, Америка!» – дигәне тәгаенләнгән иде инде.



НИЗАМЕТДИНОВА Рәхилә

Казан коммуналь хуҗалык һәм төзелеш колледжы

Кияүдә, ике бала анасы.

Тормыш шигаре: «Яхшы йөрәк – бакча, яхшы уй – тамыр, яхшы сүз – чәчәк, яхшы гамәл – җимеш ул. Үз бакчаңны кайгырт, чүп үләннәреннән сакла, яхшы сүз һәм яхшы гамәлләр нурына күм».
Генри Уодсворт ЛОНГФЕЛЛО.

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

## Безнең балалар сынатмаячак!

Бер ай буе мәктәпләрдә барган тикшерүләр укытучыларны гына түгел, безне – әти-әниләрне дә ялыктырды. Соңгысы – татар теленнән узган мониторинг бөтенләй көтелмәгән сынау булды. Шәһәр баласының татар телен ни дәрәҗәдә белүе беребезгә дә сер түгел... Ата-аналар җыелышына килгәч тә иң беренче шул хакта сүз кузгаттык. Сыйныф җитәкчебез, укучыларына «дусларым» дип кенә эндәшүче Рәзинә Шайдулловна Кәлимуллина, бездән аермалы буларак, күпкә тыныч икән! «Рәхәтләнеп эшләп чыгабыз, без бит сыйныфта гел татарча сөйләшәбез», – ди.


## Аны хәзер Европа да таный!

Яшел Үзәндә яшәүче бармаксыз пианист Алексей Романовны Финляндиягә – Хельсинкида узучы «Nordic Business Forum-2016» дигән дөньякүләм форумга чакырганнар. «Җитешсезлекләр һәм өстенлекләр» темасы буенча чыгыш ясау өчен оештыручылар меңәрләгән кеше арасыннан аны сайлаган. 5 меңнән артык тамашачы утырган залда чыгыш ясаган Алексей. Дулкынланса да, сынатмаган якташыбыз! Бу уңыш егетне канатландырган. Ул тиздән Ник Вуйчич белән бергә чыгыш ясарга хыяллана. Берничә Европа илендә концерт программасында катнашырга да исәпли – килешүләр инде төзелгән.

## «Ризыкны ташлаганчы – бүлешегез...»

Мину Полин – Һиндстанның Коти шәһәрендәге бер ресторан хуҗабикәсе. Мохтаҗларга ярдәм итүнең яңа бер юлын тапкан ул. Ризыкны күп алып, кагылмыйча өстәлдә калдыручылар бар, көн азагына сатылып бетмәгән ризык та җыела – мәрхәмәтле ханым барысын ресторан ишек төбендәге махсус суыткычка тутыра. Хәзер теләгән һәркем, тәүлекнең теләсә кайсы вакытында килеп, аннан ризык алып ашый. «Акчасына һәркем үзе хуҗа, әмма азык-төлек, башка ресурслар барлык кешелек җәмгыятенең милке. Аларны әрәм-шәрәм итәргә берәүнең дә хакы юк», – ди Мину Полин.

сөендерде





көендерде

сөендерде





көендерде

сөендерде





көендерде

## Гаепле кеше үзебез ләбаса!..

Үземнең мәктәптә укыган чагымны искә төшерәм. Безнең өчен мәктәптә татар теле бервакытта да икенче, өченче урында тормады. «Кошларның һавада эзләре генә басып калды», дип инша язмадык инде без! Бүгенгеләр шулай сөйләшә, шулай яза... Моңа хәзерге мәгариф системасы да, без – әти-әниләр дә гаепле. Бала чит телне өйрәнсен өчен барысын эшлибез: өстәмә дәресләр алабыз, репетитор яллыйбыз. Туган телебезгә игътибар гел иң азакта... Ә аннары: «Балалар татарча белми», – дибез... Кашык белән генә тамызгач, чүмеч белән чумырып алып буламы?!

## Бозыклык нигә арта соң?!

Казанның Киров районында бер ир-ат 11 яшьлек кыз баланы көчләгән. Бала белән подъездга ияреп кергән, аннан өйгә... Ярый, тиз кулга алдылар үзен. Әмма бу очрак ул кылган әлеге пычрак гамәлнең беренчесе дә, соңгысы да булмаган икән шул... Көн туган саен, шундый яңа бер хәбәр. Безнең балаларга кайдан, нинди генә куркыныч янамый?! Ничекләр барысыннан аралап, яклап бетерергә аларны?! Нигә мондый мөртәтләр гел күбәя? Чүп үләне кебек тоела алар миңа. Чүп үләнен утасаң, бакчаң чистарып китә, төбе-тамыры белән ала алсаң – мәңге чыкмый. Үсемлекләр дөньясында шулай, тик кешелек җәмгыятендә түгел...

## Сораулар күп – җавап юк...

Сүриядә, ядрә яңгыры астында калып, ике аягын да югалткан 10 яшьлек Сидра Заарурны быел язын дәваларга Россиягә алып килгәннәр иде. Куркудан, авыртудан мөлдер-мөлдер яше агып торган бу кызчык гел күз алдында торды... Бик озак дәвалаганнан соң, Мәскәүдә аңа протезлар куйганнар (иң мөһиме: бала үскән саен бу протезны яңага алыштырырга кирәкми, кайбер өлешләрен үзгәртү дә җитәчәк), ул инде йөрергә өйрәнгән. Елмая башлаган! Инде менә өенә дә кайтып киткән, дип хәбәр иттеләр. Исемә төшкән саен, үзәгем өзелә: туган җирендә аны тагын ниләр көтә? Кабат ут эченә озаттык лабаса без аны...

PRESSA.RU





## ӨЙГӘ КАЙТЫШЛЫЙ ПОЧТА ӘРҖӘСЕН АЧКАНДА, ГАДӘТТӘ, АНДА СЕЗНЕ НИ КӨТӘ?

**Исәп-хисап кәгазьләре, квитанцияләр, реклама битләреме? Газета белән журналга язылгансыздыр, бәлкем. Ә бит почта тартмасы бер хәзинә сандыгына әйләнергә дә мөмкин.**

# ТАРТМАДАГЫ СӨЕНЕЧ

Галия ГЫЙМАДИЕВА

Компьютерлаштыру заманы – кешеләр кулга каләм тоту турында онытып бара хәзер. Әле нибары 20-30 ел элек почта аша хат, открытка алышу гадәти бер күренеш иде. Татар телендә дә күптөрле матур һәм кызыклы открыткалар, тәбрикләү карточкалары бастырылды ул чакта. Ләкин дөньяда интернет таралган саен, бу гадәт үткәнгә күчә бара. Яшәеш тизлеге хәзер кешеләрдән җитез генә хәбәр алышуны таләп итә: «смс», электрон хат җибәрү, социаль челтәрләр аша язышу... Ә кая соң мондый элемтәдә җылылык, ихласлык? Кулдан язып кемгәдер открытка салу яки почта тартмасыннан башка берәүнең сиңа юллаган җылы сәламен алу – бу бит берни белән дә чагыштырып булмый торган искиткеч бер кичереш...

Һәм ни кызык, бүгенге көндә нәкъ менә интернет челтәре бу традицияне яңадан тергезергә ярдәм итә! Аны Португалиядә яшәүче, гади почта аша аралашуга зарыккан Паоло Могалес исемле студент башлап җибәрә. Мавыгу гына булып башланып киткән бу шөгыль тиз арада дөньякүләм зур проектка әверелә. Аңа посткроссинг дип исем кушалар (ингл. postcrossing, тулысынча postcard crossing яисә открытка алышыну). Ун ел эчендә посткроссинг сайтында 620 меңгә якын кеше теркәлгән һәм аның ярдәмендә 36 миллионнан артык открытка алынган!

Бу проект ничек эшли соң? Очраклы рәвештә сайланган бер кешегә открытка җибәрәсең: ул открытка аңа барып җиткәч, синең адресың шулай ук очраклы рәвештә башка берәр кешегә эләгә. Һәм ул кеше сиңа җавап яза. Иң кызыгы: син аның кем икәнен бөтенләй белмисең! Шулай итеп, гади почта тартмасы бер сюрприз сандыгына әверелә: бүген сиңа кем, кайдан, дөньяның кайсы почмагыннан сәлам юллар... Килгән

открыткаларның төрлелегенә сокланасы гына кала: алар арасында моңарчы очратмаган формада булганнары, пазл кебек җыела торганнары, хәтта агачтан һәм металлдан ясалганнары да очрый! Открыткаларга ябыштырылган маркалар аерым бер игътибарга лаек. Филателистлар (почта маркалары, штемпельле һәм маркалы конвертлар коллекциясен җыючылар) өчен бу проект – зур бер бәйрәм. Хәзинә! Төрле илләрдә открытка җибәрү бәясен, ул илләргә хас булган флора, фаунаны, аның күренекле шәхесләрен, иҗатын, мәдәниятен – боларны барысын да маркалар аша өйрәнеп була.

Шул ук вакытта посткроссинг открыткалар һәм маркалар коллекцияләү генә түгел ул. Күпләр аңа аралашу өчен килә. Бу очракта открыткада язылган сүзләр кеше өчен рәсемнән дә әһәмиятлерәк була. Дөньяның син булмаган, белмәгән, күрмәгән башка бер почмагында кем ничек яшәгәне, бүген нишләгәне, нәрсә турында хыялланганы турында уку искиткеч кызык! Шул күз күрмәгән җирләрне үзең өчен ачарга, өйрәнергә ярдәм итә дә инде посткроссинг. География белән якынрак танышу өчен дә бу мавыгу зур бер этәргеч була ала: открыткаң кайсы илгә, кайсы шәһәргә сәяхәт итүен, синең кулга кайдан килеп җитүен картадан карап беләсең. Ул гына түгел: ерак җирләр белән аралашу өчен чит телләрне белү кирәк, бигрәк тә инглиз телен. Шул җәһәттән бу проект мәктәп балалары өчен бик файдалы, чөнки ул географияне дә, телләрне дә кызык, иҗади, тормышчан рәвештә өйрәнергә мөмкинлек тудыра. Кайбер укытучылар исә посткроссинг ярдәмендә аерым мәктәп проектлары оештыралар – аларда открытка алмашуда бөтен сыйныф катнаша.

Мин үзем посткроссингка ике ел элек килдем. Нәкъ менә бер инглиз теле укытучысының блогында посткроссинг турында мәгълүмат күрдем дә кызыксынып киттем!

Беренче открыткамны мин Тайваньга җибәрдем. Ә үземә беренче булып Голландиядән сәлам килде. Ул открытканы мин өч ай дәвамында дулкынланып көткән идем. «Сәлам! Минем исемем Герда һәм мин Нидерландның көньягында торам, Бельгия чигендә. Бу открытканы мин Португалиядә ялда булганда сатып алган идем, анда йортларны шулай чынаяк кирпеч белән бизәү киң таралган. Ул сиңа охшар дип ышанам. Исән бул!» – дип язган иде миңа Герда. Хәзер коллекциямдә 500 гә якын открытка бар, аларның барысын кадерләп махсус альбомнарда саклыйм. Бу вакыт эчендә миңа 50 илдән сәлам килде, алар арасында Куба, Коста-Рика, Молдова кебек сирәкләре дә очрый. Ул открыткаларда миңа нинди генә рәсемнәр ясамадылар, аларны ничек кенә бизәмәделәр, аларга нинди генә маркалар ябыштырмадылар?! Хәтта бер тапкыр Голландиядән чәчәк орлыклары белән марка да килде.

Үземә дә төрле кешенең кызыксынуларын күз алдында тотып, открыткаларны сайлау һәм бизәү ошый – бу бик иҗади процесс. Бигрәк тә кешеләрне татар мәдәнияте, сәнгате, гореф-гадәтләре белән таныштыру җан рәхәте китерә. Мин посткроссингка килгән вакытта сатуда татар открыткалары бөтенләй юк иде диярлек, ләкин аларны хәзер интернетта, почта бүлекләрендә, кибетләрдә дә табып була. Татарларга, Татарстанга кагылышлы маркалар да бар: әмма кызганыч, алар бик аз. Сәхифәмдә: «Татарлар турында ишеткәнегез булдымы?» – дип сорау биргән идем. Дөньяда татарлар турында кемнең ни-нәрсәләр белүе,ниләр уйлавы турында җаваплар килә менә. Берәүләрнең әби-бабалары татар булып чыкты, икенчеләре кайчандыр татарлар белән аралашкан, өченчеләр безнең милләттәшләр белән тулай торакта бергә торган... Шулай да күбесенең моңарчы татарлар турында бер дә ишеткәне булмаган, ишетсәләр дә, «татар» дигәч алар күчмә кабиләләрне, «тартар» соусын, йә чи иттән булган ашамлыкны күз алдына китерә.

## *Җибәргән открыткаларым Җир шарын инде 26 мәртәбә урап чыкты!*

Гомумән, посткроссерлар – белемгә омтылган, дөньяга үз карашларын даими киңәйтергә тырышкан һәм һәр яңа мәгълүматка шатланган кешеләр. Алар һәр мөмкинлектән файдаланып, фикердәшләр табарга, аралашырга, үзләре белгәнне башкалар белән бүлешергә омтыла. Шуңа да бу проектта катнашучылар җир шарының төрле почмакларында посткроссинг очрашуларын оештыра башладылар. Безнең Казанда да уза алар. Хәзер инде бу бер традициягә әверелеп бара. Катнашучылар җибәрер өчен үзләре белән открыткалар алып килә, аларны алачак кешеләргә матур теләкләрен белдереп, ул открыткаларга имзаларын куя, тулыланган коллекцияләре белән мактана, яңалыклар белән бүлешә һәм ахырдан җыелышып почтага юнәлә... Мондый очрашулар гел якты, куанычлы бер вакыйгага әйләнә. Чөнки, әйткәнемчә, посткроссинг бик ачык һәм зирәк кешеләрне берләштерә.

Йә, ничек, мавыктыра алдыммы? Кызык өчен матур маркалар ябыштырып, бизәп, почта аша бер якын кешегезгә открытка җибәреп карагыз әле. Посткроссинг проектына кушылмасагыз да, мондый аралашу, һичшиксез, ике якның да кәефен күтәрерлек гамәл булыр!

### *БЕЛМӘСӘҢ БЕЛ*

- Посткроссинг (www.postcrossing.com) 2005 елда барлыкка килә;
- открытканың уртача барып җитү вакыты – 23 көн;
- Россия буйлап открытка җибәрү бәясе – 14 сум;
- чит илләргә открытка җибәрү бәясе – 31 сум;
- посткроссинг кысаларында күптөрле яңа проектлар барлыкка килә. Алар арасында «ДоброПочта» (www.dobro-pochta.ru.) исемле бер башлангычка аерым тукталасы килә. Бу проект авырып киткән йә катлаулы хәлдә калган кешеләргә открытка, хатлар аша таяныч һәм ярдәм күрсәтүгә багышланган: «Яхшы сүз – җан азыгы» дип атала ул;

PRESSA.RU



16+

# МИН БИТ ГАШЫЙК БУЛДЫМ!



Равил ГАЛИЕВ, җырчы,
Татарстанның атказанган артисты;
гаилә стажы – 13 ел;
улы Сәйдәшкә – 12,
кызы Әминәгә 8 яшь.

**Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...**
**Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.**

**1 Иң элек хатын-кызның Сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...**

– Буй-сынынадыр, мөгаен. Ә бәлки алай да түгелдер... Күңелгә ошаган хатын-кыз башкалардан бар ягы белән дә аерылып торадыр ул, миңа калса.

**2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?**

– Диңгез кебек әледән-әле «дулкынланып» алуын. Бер дә юкка борчылуын, һәм сине дә, һичшиксез, борчуын, начар төш күрсә, төн уртасында уятып сөйләвен, бик тиз кызып китүен һәм бер сәбәпсез үпкәләвен...

**3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?**

– Әлбәттә, хыянәтне кичермәс идем. Һәм моны, миңа калса, бер генә ир-ат та кичерә алмый торгандыр.

**4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?**

– Бер үк хатын-кыз бу рольләрнең икесенә дә туры килсә, әйбәт булыр иде дә ул. Юк икән, ир-ат өчен, билгеле, икенчесе мөһимрәк. Хатын-кызның комфорт тудыручы хуҗабикә булуын телибез инде без.

**5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?**

– Ничек инде дус була алмасын? Шунсыз яхшы гаилә төзү мөмкин дә түгелдер. Бергә нәрсәдер эшләү өчен ике кешенең, кимендә, бер-беренә яхшы мөнәсәбәттә булуы кирәк бит. Ә гаилә тормышы – гомер буе бергә яшәү, балалар үстерү, бергә хуҗалык алып бару... Ир белән хатынга сөйләшергә, киңәшләшергә, уртак карарлар кабул итәргә туры килә. Димәк, һичшиксез, дус без...

**6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?**

– Ландыш үзе, үпкәсез генә, билгеле: «Син миңа тәкъдим дә ясамадың бит!» – дияргә ярата. Ә мин, әбибабайдан кыз сорарга кайткач, тәкъдим ясауны күңелемнән генә шул «кыз сорау процедурасына» кушканмын да куйганмындыр, дип уйлыйм... Аннары сүзләр артык та булгандыр инде, бәлки, ул чакларда.

**7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?**

– Минем очракта – юк. Чөнки мин өйләнер өчен кыз сайламадым, мин бит гашыйк булдым!

**8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?**

– Бик авыр сорау инде бу... Хуҗалык эшләре белән күбрәк шөгыльләнергә тиештер, бәлки. Көндәлек тормышта алыштыргысыз кеше булырга омтылырга. Чөнки күп акча эшләгән эшлекле хатын-кызның йорт мәшәкатьләренә чыннан да вакыты калмаска мөмкин. Әмма ничек кенә булмасын, ир кеше бу уңайсыз вазгыятьне үзгәртергә тырышырга тиеш, миңа калса. Һәм аннан соң... ир кешенең үзен ничек тотуы ул кадәр мөһимме соң мондый вакытта? Гаиләне саклап калу өчен хатын-кызның үзен ничек тотуы мөһимдер.

**9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?**

– Бу миңа ошамас иде, дип уйлыйм. Гашыйк булуны никадәр яшерергә тырышсаң да, сизелә инде ул анысы. Әмма моның телдән әйтелүе, хатын-кызның үзе башлап мәхәббәт аңлатуы булган кызыксынуны да сүндерергә мөмкиндер.

Бу хакта сүз башлагач, Ландыш белән ничек танышуыбыз искә төште әле. Без, бер төркем егетләр, кызлар, Яшьләр көненнән соң Чаллының «Энергетик» мәдәният йорты каршында очрашкан идек. Бергәләп каядыр барырга җыендык, һәм шунда Ландыш (бер Ландыш кына бит!) әнисенә рөхсәт сорап шалтыратты. Әнисе рөхсәт итмәгәч, безнең белән саубуллашты да кайтып китте. Кыскасы, күрештек тә, аерылыштык. Танышырга өлгерә алмый калдык без ул көнне. Әмма мин инде Ландышның үзен дә, ул иптәш кызына әйткәндә генә отып калынган телефон номерын да оныта алмадым. Берме, икеме ел узгач булса да, шалтыраттым.

Без гаилә корганда Ландышка – 25, миңа – 35 яшь иде. Мин ул вакытта шәһәрдә инде танылып килә торган

җырчы булганмындыр, кызлар да игътибарсыз калдырмагандыр, әмма башкалардан аерылып торган шул матур кыз, әйткәнемчә, барыбер онытылмаган, хәтта телефон номеры да ниндидер могҗиза белән, күңелдә сакланган. Язмыш!

**10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?**

– Кыюлык, тәвәккәллектер, минемчә. Һәрхәлдә, байлык һәм буй-сын түгелдер инде... Түгелдер дип ышанам. Чөнки миндә байлык та, буй-сын да юк.

**11 Хатын-кызлардан үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүен көтәсез?**

– Мин үземне ышанычлы кеше дип саныйм. Бу ир-атларга да, хатын-кызларга да иң кирәкле сыйфат.

**12 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?**

– Ихтимал. Ир-ат үзе йомшаграк табигатьле икән, чыннан да, көчлерәк хатын-кыздан читтәрәк йөрергә тырыша инде ул. Ә мин үзем хатын-кыз акыллы булса, аның чибәр һәм көчле булуыннан зыян юк, дип саныйм. Чөнки акыллы хатын-кыз гаилә мәсьәләләрен хәл иткәндә барыбер иреннән беркайчан да алга чыкмаячак, һәм хәтта кайбер мәсьәләләрдә аның сүзе өстен булып калса да, моны иренә сиздермәскә тырышачак. Иң мөһиме: ирен балалар алдында авторитет итеп күрсәтәчәк, әти кешенең дәрәҗәсен югары тотачак. Бу, беренче чиратта, аның үзе өчен кирәк бит. Балалар тәрбияләү җиңелрәк булсын өчен кирәк. Әниләр безне шулай үстерде бит инде. Мин үзем Азнакай районы Камышлы Күл авылыннан. Безнең әти 30 елдан артык рәссам-бизәүче булып Актүбә эшчеләр бистәсенә йөреп эшләде. Дөресен әйткәндә, без аны рәтләп күрмәгәнбездер дә. Әмма «Атагызга әйтәм!» дигән сүзне бик күп ишеттек инде.

Балаларны икәүләп ачуланырга ярамый, дип саныйм мин. Әти-әнинең берсе кырыс икән, икенчесе, һичшиксез, йомшаграк мөнәсәбәт күрсәтергә, ягъни баланс сакланырга тиеш. Шунсыз булмый, чөнки аларда да, нәкъ безнеке кебек, яраланырга гына торган күңел бит.

**13 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар. Алар, сезнеңчә, бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?**

– Ир кеше хатынының ниндидер сыйфатларга ия булуын тели (әмма теләүдән ары уза алмый!), ә хатын-кыз, һичшиксез, таләп итә.

**14 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.**

– Без Ландыш белән нинди дә булса мәсьәләне икәү уртага салып сөйләшәбез, инде азаккача хәл итеп тә бетерәбез. Син хаклы, диешәбез, гафулар үтенешәбез. Тик күпмедер вакыттан соң кире шуңа ук әйләнәбез дә кайтабыз. Нәкъ элеккеге эчтәлектә була ул, нәкъ шундый ук зурлыкта. Теге сөйләшү бөтенләй дә булмаган кебек!

**15 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.**

– Дөресен әйткәндә, мин бөтенләй бәхәсләшә белмим. Шаккатып тыңлап утырам, бу кадәр хаксызлыкны күреп, хәтта күпмедер дәрәҗәдә стресс та кичерәм. Әмма бәхәсләшмим. Соңыннан, барыбыз да тынычланып беткәч кенә, позициямне яхшылап, дәлилләп аңлатып бирәм.

Ландыш ул кечкенәдән «командир» булып үскән. Һәм бу «командирлык», дөресен әйткәндә, беркая да китмәгән. Ул «Эврика» Чаллы шәһәр мәдәният үзәгенең директоры булып эшли башлаганда, бу үзәк торак йортның беренче катында гына урнашкан иде. «Авыл клублары» дигән Президент программасы буенча, шәһәрнең төрле урыннарында бүген инде өченче филиалы төзелә үзәкнең. Ландыш, директор буларак, бу төзелешләрнең барысын да башлап йөрде. Кыскасы, ул бик актив кеше. Һәм аның, бәлки нәкъ менә шуңа күрәдер, еш кына өйдә дә лидер буласы килә. Әмма артыкка китә башласа, мин аны, яратып кына, туктатырга мәҗбүр булам инде: «Монда мин командир!»

**16 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән...**

– Минем үземнең дә пешерүем мөмкин. Икебезнең дә бергә җәһәт кенә нәрсә дә булса әзерләп ашавыбыз да мөмкин. Әмма ничек кенә булмасын, өйдә ашарга пешмәгән булу миңа, билгеле, ошамый. Һәм моны Ландыш та яхшы белә. Без бит авыл балалары. Әниләрнең барысына да өлгерүен күреп үскән. Хәзер, билгеле, тормыш шартлары үзгәрде. Вакыт та чагыштырмача тизрәк уза. Балалар да игътибарны күбрәк сорый. Хөкүмәт эше дә бар. Ир белән хатынның икесенең бер вакытта өйгә кайтып керүләре табигый. Шуңа күрә хатын-кызның хәленә керергә тырышмый булмый. Әмма дә ләкин...

Балалар, дигәннән, балаларны дәрес әзерләтү дигән тагын бер бик зур эш тә бар бит әле хәзер бездә. Аның монысы да, дөресен әйткәндә, күбрәк хатын-кыз өстендә. Өстәмә шөгыльләрне дә игътибарсыз калдырып булмый. Сәйдәш инде сәхнәгә чыга башлады. Шәһәрдә уза торган «Татар малае» бәйгеләрендә катнашып, җиңүләр яулап килә.

**17 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар соңга калучан.**

– Хатын-кыз, әлбәттә, озак җыена. Һәм моңа каршы көрәшүне мин бөтенләй файдасыз дип саныйм. Әмма шунысы да бар – Ландыш озак җыенганнан безнең бер генә мөһим эшкә дә соңга калган юк әле! Хатын-кызда зирәклек зур. Гаилә мәнфәгатьләренә беркайчан да зыян китерми ул.

**18 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?**

– Ошамаганын хәтерләмим. Иң ошаганы – Ландыш миңа алтын йөгертелгән кул сәгате бүләк иткән иде. Ул, гомумән, минем нәрсә яратканны, нәрсә яратмаганны яхшы белә. Һәм бу, минемчә, очраклы түгелдер. Бу – бер-берең туры килүдер.

Аннан – акыллы хатын-кыз ир-ат өчен үзе дә зур бүләк ул. Язмыш бүләге...

PRESSA.RU





# ЯЛГАНМЫ, ЧЫНМЫ?

**Геммология – асылташларның химик составын, физик үзлекләрен, шулай ук зәркән эшләнмәләрнең сыйфатын өйрәнә торган фән. Геммолог кыйммәтле ташларны ачыклау һәм сертификацияләү белән шөгыльләнә.**

Күптән түгел АКШта халыкара җәнҗал килеп чыга язды. Беренче леди, Обаманың хатыны Прагада (Чехия) гранат ташлы зәркән бизәнү әйбере сатып ала. Чөнки коңгырт-кызыл таш чех зәркән эшләнмәләренең символы санала. Әмма бераздан ташның чын түгеллеге ачыклана.

Бу җәнҗалдан соң Чехиянең барлык зәркән кибетләрендә зур тикшерүләр үткәрелә. 15 кибетнең 13 ендә ялган ташлар белән сәүдә итеп яталар икән.

Шуларны ишеткәч, булган кадерле асылташларымны тикшереп карарга булдым. Якыннарымның бүләкләре чын таштан булмавы да ихтимал бит. Ә алар зиннәтле әйбер өчен әллә никадәр акча түккәннәрдер. Хәзер никах һәм туй мәҗлесләрендә бриллиант йә башка кыйммәтле ташлар белән бизәлгән зәркән әйберләр бүләк итәләр. Күз алдына китерегез: кияү егете кәләшенә ярыйсы гына суммага бүләк ала, ә андагы асылташ ялган булып чыга! Бер дә күңелле түгел инде, зәркән бизәнү әйберсен алмаштырып йә кире тапшырып та булмый бит әле.

Күптән түгел кыйммәтле ташлар буенча эксперт белән таныштым. Регинаның геммолог тәҗрибәсе аз әле, шулай булуга да карамастан, ул Казандагы иң яхшы белгечләрдән санала. Ә бит ул һөнәрнең бүтәнен сайлаган була. Инженер дипломы алган кыз үз белгечлеге буенча эш табалмый йөри. Дуслары, өстәмә белем алып, геммология белән шөгыльләнергә киңәш итә. Казанда геммологлар бармак белән генә санарлык икән. Ахирәтләренең җиңел кулыннан ул геммолог булып китә.

Геммологлар һәм зәркәннәр – башлыча ир-атлар. Ул урынга хатын-кызлар керә башлавын ирләр авыр кичерә. Шулай булуга да карамастан, Регина Казанда геммо-

логлар арасында лаеклы урынын алган инде.

Геммологлар бик күп кызыклы, көлкеле һәм гыйбрәтле хәлләр турында сөйләргә мөмкин. Күптән түгел бер ханым, үзе сатып алган таш белән мактанасы килеп, шул ук вакытта аның сыйфатын тикшертеп кайту нияте белән, геммологка килә. Кыйммәтле җәүһәрнең тиешле күрсәткечләргә туры килмәвен ачыклагач, ничек аптырап калганын күрсәгез икән! Регина ташның чын бәясен һәм ничә карат икәнен ачыклый, аның ярдәме белән дөреслек ачыла. Зәркән бизәнү әйберен үз хакына туры килмәслек зур суммаларга саткан салон гаебен танырга мәҗбүр була, акча иясенә кире кайтарыла.

Чит илләрдә сатып алынган зәркән бизәнү әйберләрен тикшерү буенча һәр көзне раут уздырыла. Ни өчендер, безнең хатын-кызлар чит илләрдән, аеруча Һиндстан, Кытай, Таиланд, Вьетнам, Малайзия, Корея кебек илләрдән арзан гына бәягә асылташлар алып кайтып була дип ышана. Кагыйдә буларак, экспертиза нәтиҗәләре гел киресен күрсәтә. Бу илләрдә югары сыйфатлы ясалма әйберләрне чын ташлар дип сатып җибәрәләр.

Шулай да була: күпләр якут сыман кызыл кашлы алкайөзекләрне әбием мирасы дип йөртә. Ә бит узган гасырның 30 нчы елларында Советлар Союзында ачык кызыл ясалма сапфирны чын якут дип сатып җибәрә торган булганнар. Кызганычка каршы, совет чорында илдә халык ихтыяҗын канәгатьләндерерлек асылташлар булмаган. Мөселманнар күпләп яши торган Урта Азия республикаларында зәркән бизәнү әйберләренә аерым бер игътибар күрсәткәннәр. Барыннан да бигрәк якут, фирүзә, мәрҗән, ахак кебек асылташлар затлы саналган, аларны күпләп сатканнар, тик күбесе ясалма булган. Регина ул ташларның сыйфатына үзе дә гаҗәпләнә: «Алар югары сыйфатлы, тик барыбер чын таш түгел», – ди.

**Киңәш:** кыйммәтле ташлы зәркән бизәнү әйберен үзегезгә аласыгыз йә кемгәдер бүләк итәсегез килсә, иренмәгез, сатучыдан сертификатын сорап, сыйфаты белән кызыксыныгыз. Затлы товарны белгеч белән киңәшеп алсаң яхшырак. Ул асылташның чынмы-ясалмамы икәнен әйтеп бирә, кайсы бизәнү әйберсенә тукталырга кирәген киңәш итә.

Геммологик экспертиза асылташларның үзенә тәңгәлләрен, аларның синтетик аналогын һәм имитациясен билгели. Болар эксперт булышлыгы белән махсус геммологик җиһаз ярдәмендә ачыклана, ташның метрик, микъдар һәм сыйфат бәяләмәсе тикшерелә.

Зәркән эшләнмәнең геммологик экспертизасы вакытында аның нәрсәдән эшләнгән булуы ачыклана, ягъни материалларга диагностика ясала, кыйммәтле ташларның авырлыгы, аларның төсе, сыйфаты, эшкәртелү эзләре күрсәтелә. Тамгасы булса, бу хакта мәгълүмат бирелә. Зәркән эшләнмәләрдәге кимчелекләр дә өстәп языла.

Рәмзия КАШАПОВА


- Блог в инстаграм @gemexpertkzn,
- советы в выборе камней,
- диагностика подделок.
- информация о драгоценных камнях и их свойствах.
- выдача сертификатов.
- сопровождение покупки/продажи ювелирных изделий.
- Консультации по телефону: +79196894459

РЕКЛАМА


## «ИГЕЛЕКЛЕ УЕНЧЫКЛАР»

Журналыбызның быелгы сентябрь санында без, Казандагы «Роналд Макдоналд йорты» белән бергәләп, «Игелекле уенчыклар» дигән мастер-класс оештырган идек. Республика балалар клиник хастаханәсендә каты авыру белән көрәшүче балаларга ярдәм итү йөзеннән оештырылган бу игелекле акциядә катнашырга чакыруыбыз җавапсыз калмаган. Редакциябезгә уенчыклар тулы бер әрҗә килеп төште. Казанның 186 нчы «Нәүрүз» балалар бакчасы хезмәткәрләре һәм андагы сабыйларның әти-әниләре җибәргән икән аны. «Балаларда кешелеклелек, бердәмлек, тирә-юньдәгеләр кыен хәлдә калганда ярдәмгә килә белү, игелек кылу, яхшылык эшләү кебек матур сыйфатлар тәрбияләү белән беррәттән, әниләребезне дә «Игелек акциясенә» катнашырга чакырдык. «Тамчыдан күл җыела», – ди бит. Язмыш сынаулары белән көрәшүче шул батыр йөрәкле, көчле рухлы балаларга һәм аларның әти-әниләренә ярдәм итүдә әз генә булса да өлешебез керер дибез», – дип яза «Зурлар һәм мәктәпкәчә хәзерлек төркеме»ндәге тәрбиячеләр Илзирә Садыйрова һәм Алия Сәлахиева.



PRESSA.RU





«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА әзерли

# КЕРӘНЛЕ МАНТЫ

**Берәр мастер-класс күрсәтмәссеңме, дигәнебезне: «Әйдәгез, манты пешерик», – дип күтәреп алды Татарстанның атказанган артисты Гөлназ САФӘРОВА. «Безнекеләр манты ярата. Рецепты да күптәннән сыналган», – дигәч, җыендык та, үзләренә кунакка киттек. Гөлназны «Татар радиосы»нда кызыклы тапшырулар авторы буларак та беләбез, телевидениедә «Тамчы» тапшыруын алып барган яшүсмер чагын да хәтерлибез, «Татар җыры» фестиваленең алып баручысы булуыннан да хәбәрдар. Зәвыгы, яшьләргә хас үткенлеге, өлгерлеге белән дә үзенә җәлеп итүче Гөлназ уңган хуҗабикә дә икән! Мастер-класс вакытында аның тагын да кызыклы якларын ачып кайттык, алары белән сайтыбызда таныштырырбыз.**

***Кирәк:***

- 1 кг майлырак ит;
- 4 баш суган;
- 2 бәрәңге (бәрәңге урынына кабак та тәмле була);
- 2-3 тырнак сарымсак;
- кечкенә генә кисәк керән яки имбир тамыры;
- тәменчә тоз, кара борыч;
- үсемлек мае.

***Камыр өчен:***

- 500 г он (2 стакан);
- 1 йомырка;
- 200 мл кайнаган салкын су (1 стакан).



***Эш барышы:***

■ иң элек камыр ясыйк, чөнки аның бераз суыткычта торасы була әле. Онны зуррак җамаякка иләп (камыр яхшы, үзле булсын өчен, онны иләргә кирәк), уртасын чокырлыйбыз да 1 йомырка сытабыз. Аннары аз-азлап кына су өсти барып, кул белән камыр басабыз. Суның барысын берьюлы салып бетермәгез, кайсыбер сорт онга азрак кирәк – онның дымлылыгына бәйле ул.

■ Манты өчен әзерләнгән камыр пилмән камырыннан йомшаграк булырга тиеш, тотып караганда колак яфрагы кебек булса, манты өчен шул әйбәт камыр санала. Эчлек әзер булганчы аны суыткычка куеп торабыз.

***Эчлек ясау:***

■ итне бераз гына җебетеп (суле акканчы җебетергә кирәкми), вак кына итеп турыйбыз. Суганны да шулай ваклыйбыз, анысы ваграк булган саен яхшы. Чиратта – бәрәңге, анысын да вак-вак шакмаклап турыйбыз.

■ Керән тамыры һәм сарымсакны чистартып, вак угычтан уабыз. Зур табакка ит, суган, бәрәңге, керән белән сарымсакны салып, тоз һәм борыч сибәбез, барысын бергә кул белән яхшылап болгатабыз. Суган белән бәрәңге йомшарып китәргә тиеш. Итегез коры булса, 2 аш кашыгы чамасы туңмай эретеп сибегез. Туңмай булмаса, атланмай яки үсемлек мае да ярый. Шулай да туңмай белән тәмлерәк.

■ Камырны куна тактасына төшереп, зур җәем итеп җәябез. Бик бирелеп китеп, артыгын юкартмагыз, токмач камырыннан калынрак булсын. Камырны 10х10см булган шакмакларга кисәбез.

■ Һәр шакмакның уртасына 2 аш кашыгы эчлек салып, камырның дүрт почмагын кара-каршы китереп бөрәбез, «койрык» очларын берберсенә ябыштырабыз.

■ Манты казанының тәлинкәләрен майлап, мантыларны тезәбез. Пешкәч, алар җәелеп китә, бер-берсеннән кубарып алуы кыен була, шуңа күрә araларын бушрак калдырыгыз. Гөлназ исә мантыны мультиваркада пешерә. «Парда пешерү» режимына куйсаң, 40 минуттан әзер була икән.

■ Әгәр дә манты казаныгыз да, мультиваркагыз да булмаса, мантыны табага тезеп, газ мичендә дә пешерергә була. Алай озаграк пешә: 1 сәгать тә 10 минут чамасы. Өсте кызаргач, бераз шулпа сибеп, тагын 15 минутка газ миченә тыгып торырга кирәк.

■ Әзер мантыларны аштәмләткеч үләннәр белән бизәп, табынга каймак белән бирәбез.

Ашларыгыз тәмле булсын!

PRESSA.RU

**3-5 яшьлек кызчыкларга тәгаенләнгән бу бишмәтне бәйләп чыгу өчен шактый мәшәкатьле булыр. Аның каруы, бәйләп бетергәч, кызыгыз бик шатланыр. Салкынча җәйге кичләрдә, язгы-көзге тымызык көннәрдә кию өчен дә бик уңайлы ул. Үзе затлы һәм матур күренә. Юка күлмәк өстеннән киеп кую өчен дә менә дигән инде. Әллә соң, тәвәккәлләп, тотынабызмы?**



**Мастер-классны Марина ДМИТРИЕВА үткәрә.**




*Кирәк:*


- бәйләм җебе: 60% йон, 40% акрил, 200м/100 г, 6 йомгак;
- 3,5 санлы бәйләм энәләре;
- эчлек өчен алсу төстәге ныкча һәм сузылучан (стрейч) тукыма, иңе 140 см булса, 1 м җитә (башка төсле тукыма да ярый);
- тукыма төсендәге тегү җебе;
- матур төймәләр (диаметры 1 см).

# КӨЯЗКӘЙЛӘР БИШМӘТЕ


**Аран**



**Толым**



**Ромб**



I уң күз;
– сул күз;
2 күз сулга авыштырып уң белән бәйләнә;
3 күз уңга авыштырып, уң белән бәйләнә;
3 күз сулга авыштырып, уң белән бәйләнә;
3 күз уңга авыштырып, 2 күз – уң, 1 күз сул белән бәйләнә;
3 күз сулга авыштырып, 1 күз – сул, 2 күз уң белән бәйләнә;
4 күз сулга авыштырып, уң белән бәйләнә;
4 күз уңга авыштырып, уң белән бәйләнә;
4 күз сулга авыштырып, 2 күз – сул, 2 күз уң белән бәйләнә;
4 күз уңга авыштырып, 2 күз – уң, 2 күз сул белән бәйләнә.

## Эш тәртибе:

■ Бәйләмне итәктән башлыйбыз. Алтакта белән арттакта тоташ бәйләнә. Алай бәйләүне катлаулы дип тапсагыз, алдын аерым, артын аерым бәйләргә була.

■ Энәгә 333 күз җыеп, 8 рәтне уң күзләр белән генә бәйлибез (шәл бәйләме).

■ 9 нчы рәттән бизәкләр бәйләү башлана. 7 күз уң, 1 күз сул, 6 уң (үрем – жгут та диләр), 1 сул, 2 күз «энҗеле бизәк» («дөге» бизәк – путанка дип тә әйтәләр, 1 күз – уң 1 күз – сул. Икенче рәттә уң күз – сул, сулы – уң була), 1 сул, 9 уң (калын толым), 1 сул, 2 күз «энҗеле бизәк», 36 күз аран үрнәге белән бәйләнә, 2 күз «энҗеле бизәк», 1 сул күз, 9 уң күз (калын толым), 1 сул күз, 2 күз «энҗеле бизәк», 1 сул күз, 14 күз «кыек шакмак» (ромб) схемасы белән, 1 сул күз, 5 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 6 күз уң (үрем), 1 сул, 8 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 6 уң (үрем), 1 сул, 8 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 6 күз уң (үрем), 1 сул, 8 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 6 уң (үрем), 1 сул, 8 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 14 күз «кыек шакмак», 1 сул, 8 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 6 уң (үрем), 1 сул, 8 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 6 уң күз (үрем), 1 сул, 8 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 6 уң күз (үрем), 1 сул, 8 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 6 уң күз (үрем), 1 сул, 4 «энҗеле бизәк», 1 сул, 14 күз «кыек шакмак» схемасы белән, 1 сул, 2 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 9 уң күз (калын толым), 1 сул, 7 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 26 уң күз (оек бәйләме, ягъни уң як – уң; сул як сул белән бәйләнә), 1 сул, 5 күз энҗеле бизәк», 1 сул, 6 уң күз (үрем), 1 сул, 6 уң күз. Алга таба бизәкләрне схемаларга нигезләнеп бәйлибез.

■ 20 рәт бәйләгәч, 2 күзле «энҗеле бизәкләрдән» тыш, калган «энҗеле бизәкләрне» һәр яктан да берәр күзгә киметәбез. Киметүне һәр 14 рәт саен кабатлыйбыз, ахыр чиктә «энҗеле бизәк» 2 генә күзгә калырга тиеш. («оек бәйләменең» ике ягыннан баручы «энҗеле бизәкләр» 3 күзгә кала). «Энҗеле бизәк» белән бергә алгы яктагы «оек бәйләме» белән бәйләнгән өлешне дә – 30 нчы рәтне бәйләгәч, ике яктан да 1 күзгә киметәбез, аннары күкрәкчә (кокетка) өлешенә кадәр һәр 18 рәт саен киметә башлыйбыз.

## Җин уемын калдыру:

■ Итәк очыннан башлап, 28 рәт бәйләгәч, башта беренче ике үрем арасындагы – 4 күзне, аннары икенче ике үрем арасындагы 4 күзне ябабыз. Хәзер инде арткы якны – аерым, алгы якны аерым бәйләп бетерәбез.

## Арттакның өске ягы:

■ Бәйләмне бизәкләр белән бәйләүне дәвам итәбез, әмма һәр икенче рәтне бәйләгәндә ике тапкыр 2 күз, ике тапкыр 1 күзне ябабыз. Итәк очыннан исәпләгәндә 44 см бәйләгәч, муен уемы өчен уртадагы 22 күзне ябабыз. Аннары, ике яктан да һәр икенче рәтне бәйләгән саен, ике тапкыр берәр күзне киметәбез. Калган өлешне туры гына бәйләп, итәк очыннан 46 см булгач, барлык күзләрне дә ябабыз.

## Алтакның уң як өлешен бәйләү:

■ Бәйләмне бизәкләр белән бәйләүне дәвам итәбез. Шул ук вакытта һәр ике яктан ике тапкыр икешәр күзне, ике тапкыр берәр күзне ябабыз. Җиң уемын башлап, 4 рәт бәйләгәннән соң, күкрәкчәгә керешәбез. Ул болай бәйләнә:

PRESSA.RU



7 уң күз, 1 сул күз, аннан чираттагы 71 күзне икешәрләп, өчәрләп сул белән бәйләп алып, 27 күзгә калдырабыз. Калганнарын бизәк белән бәйлибез. Күкрәкчә «энҗеле бизәк» белән бәйләнә. Кокетканың 10 рәтен бәйләгәч, 2 төймә тишеге ясыйбыз. Аларның арасы 6,5 см (15 күз). Инде 24 рәт булгач, янә ике тишем ясыйбыз. Тагын 6 рәт бәйләп, муен уемын башлыйбыз. Рәт башында 27 күзне ябабыз, аннары һәр 2 рәт саен башта 3 күз, аннары 2 күз, аннары тагын 2 күз, аннары 1 күз ябып, 46 см булганчы, турыга гына бәйләп, күзләрнең барысын да ябабыз.

■ Күкрәкчәнең сул як өлеше дә уң якныкы кебек үк бәйләнә, фәкать төймә тишекләре генә ясалмый. Бу якта да 27 күздән тора.

## Җиң:

■ Энәгә 87 күз җыеп, 8 рәтне шәл бәйләме белән бәйлибез. Алга таба бизәкләр белән бәйләнә: 6 күз «энҗеле бизәк», 1 сул күз, 6 уң күз (толым), 1 сул, 6 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 10 күз «кечкенә ромб» схемасы белән, 1 сул, 6 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 9 күз уң (калын толым), 1 сул, 6 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 10 күз «кечкенә ромб» (ул нәкъ 14 күзәнәкле ромб кебек үк бәйләнә, уртадагы күзләр саны гына кимрәк), 1 сул, 6 күз «энҗеле бизәк», 1 сул, 6 күз уң (толым), 1 сул, 6 күз «энҗеле бизәк». Бизәкләр башланганнан соң, 16 рәт башлагач, беренче һәм ахыргысыннан кала, «энҗеле бизәк» белән бәйләнә торган урыннарны ике яктан да берәр күзгә киметәбез. Тагын 16 рәт бәйләгәч, киметүне шул рәвешле кабатлыйбыз. Җиң озынлыгы 17 см булгач, һәр 8 нче рәттә ике яктан да берәр күз өстибез («энҗеле бизәк» белән бәйләнгән урыннарга). Моны дүрт тапкыр кабатлыйбыз. Җиң озынлыгы 27 см булгач, уемнарны бәйли башлыйбыз. Моның өчен һәр яктан да 2 рәт саен башта 3 күз, аннан 2 күз, аннан 1 күзне, тагын 1 күз һәм тагын 1 күзне ябабыз. 10 рәт турыга гына бәйләнә. Аннары һәр 2 рәт саен башта 3 күз, аннан, 4 күз, аннан 5 күз, аннан 6 күз, аннан 7 күз ябабыз да, соңгы рәттә калган барлык күзләрне ябып бетерәбез.

## Эчлек:

■ Алтакта, арттакта һәм ике җиңне эчлек тукымасына салып, эзен төшерәбез һәм кырый-кырыйлардан 1,5 см тегү өлеше калдырып (аскы итәктә бөгү өлеше өчен 4 см калдырабыз), тукыманы кисәбез. Игътибар: эчлек тукымасыннан пәлтәнең арткы ягын кискәндә, 5-6 см киңрәк итәргә кирәк. Теккән вакытта артык өлешне кыл уртада бөкләп, бөкләм ясап калдырабыз.

■ Эчлекне җыю: иң элек иң башындагы җөйләр тегелә, аннары ике кырый җөйне салабыз. Җиңнең дә ике читен машина җөе белән тегеп тоташтырабыз. Җиңне урынына утыртабыз. Җөй салырга керешкәнче, башта аны энәләр белән җиң уемына чәнчеп чыгабыз. Култык асты җөйләре бер-берсенә туры килергә тиеш. Машина белән бастырганда, җиң ягы аста булырга тиеш. Ахыргы эш итеп, эчлекнең итәген бөгәбез.

## Пәлтәне җыю:

■ Башта иңбашлары тоташтырыла, аннары кырый җөй тегелә. Җиңне тегеп, җиң уемына утыртабыз, төймәләрне тагабыз. Пәлтә белән эчлекне бер-берсенә сул ягы белән кидереп, алгы яктан – өстән һәм җиң очларыннан кулдан гына беленми торган җөй белән тегеп тоташтырабыз. Теккәндә эчлекнең читен эчкә таба бөгеп калдырабыз. Эчлектә дә төймә тишекләрен билгеләп, кечкенә кайчы белән шул эздән ерабыз, кырыйларын эчкә таба бөкләп, кулдан гына атламалы җөй белән тегәбез.

## Муен уемы:

■ Муен уемы тирәли энәгә күзләр эләктереп, 8 рәт оек бәйләме белән бәйлибез дә күзләрне ябабыз. Аны сул якка кайтарып, муен уемына беленми торган җөй белән тегеп куябыз.

## Яка:

■ Яка бәйләү өчен ике яктан да 6 см ара калдырып, муен уемы тирәли энәгә күзләр эләктерәбез һәм яканы «энҗеле бизәк» белән бәйлибез. 14 рәт бәйләгәч, һәр яктан да икешәр рәт саен башта 1 күз, аннары 2 күз, аннары 3 күз, аннары 4 күз ябабыз. Яканың түгәрәкләнеп ябылган урыннарында энәгә күзләр күтәреп, аны башка күзләр янына кушабыз һәм бәйләмне оек бәйләме белән бәйләп, 4 рәт чыгабыз. Аннары энәнең 6 нчы номерлысына күчеп, тагын бер рәт бәйлибез. Кабат энәнең 5 нче номерлысына күчеп, тагын 4 рәт оек бәйләме белән бәйлибез дә күзләрне ябабыз. Оек бәйләме белән бәйләнгән өлешне урталай бөкләп, читен яканың арткы ягына кулдан беленми торган итеп тегеп куябыз.

## Арткы тасма:

■ Арткы якта бил турысында энәгә 11 күз эләктереп, 36 см тасма бәйлибез. Күзләр тәртибе түбәндәгечә: 2 уң күз, 7 «энҗеле бизәк», 2 уң күз. Тасманың икенчесе дә нәкъ шулай ук бәйләнә.

## Үрем (жгут) бизәге:

■ 6 уң күздән бәйләнә. 2 рәт бәйләгән саен, 3 күзне ярдәмче энәгә төшереп торып, баштагы арттагы 3 күз, аннары ярдәмче энәдәге күзләр бәйләнә.




***Кучкар.*** Күбрәк үз тормышыгызга, шәхси эшләрегезгә игътибар бирерсез. Кәефләр күтәренке булыр. Ялгыз Кучкарларга Яңа ел алдыннан могҗизага ышанырга туры килер, аларның насыйп ярларын очрату ихтималы бик зур.


***Үгезбозау.*** Үзегезне күрсәтер, хөрмәт яулар өчен яхшы вакыт. Шулай да тормыш ритмын бераз тыя төшсәгез яхшырак. Узып баручы ел ниндидер хыялыгызның тормышка ашуы белән истә калыр.


***Игезәкләр.*** Кызыклы вакыйгалар вәгъдә итә торган ай. Дус-ишләрегезне шаккаттырган берәр гамәл кылырсыз яисә үз кулларыгыз белән искиткеч берәр нәрсә ясарсыз. Бу исә дәрәҗәгезне тагын да арттырып җибәрер.


***Кысла.*** Әллә нәрсәләр эшләрлек көч-куәткә ия булырсыз. Бу – Марс планетасының тәэсире. Моңа кадәр вакытыгыз яки көчегез җитмәгән эшләрне тагын бер кат кузгатып карагыз әле – уңышлы башкарып чыгачаксыз.


***Арыслан.*** Уңышлы ай. Бөтенесе җиңел киләчәк. Шулай да бер-бер уңышка ирешим дисәгез, барлык мөһим эшләрегезне 19 декабрьгә кадәр эшләп өлгертегез. Аннан соң инде яңа эшләр башламый торуыгыз хәерле.


***Сөмбелә.*** Иҗади мөмкинлекләр ае. Креативлык күрсәтү өчен менә дигән форсат чыгачак. Бу эшкә генә түгел, шәхси тормышка да кагыла. Дөньяга башка күзлектән карый башларсыз.


***Бизмән.*** Эшлекле очрашулар, яңа килешүләр өчен бик шәп вакыт. Барысын да бер дигән итеп башкарып чыгарсыз. Моның өчен көч тә, мөмкинлек тә булачак. Хыялларыгыз тормышка ашар.


***Чаян.*** Иҗади эшчәнлек белән шөгыльләнүчеләр өчен иллә дә уңышлы чор. Бернигә карамый, үз юлыгыздан барыгыз. Бернидән дә шикләнмәгез – уңыш сезнең якта булачак. Моңа кадәр уйлап та карамаган яңа эшкә тотынырсыз.


***Укчы.*** Ел ахыры уңыш һәм якты халәт бүләк итәчәк. Киләчәккә планнар кору өчен яхшы вакыт. Бер-бер артлы өерелеп килгән уңышларга алданып, шулай да үзегезгә бик күпне йөкләмәгез.


***Кәҗәмөгез.*** Казанышлар ае. Күңелегезгә рәхәтлек кенә түгел, финанс ягыннан тотрыклылык та бирүче шөгыль табарсыз. Ел ахырында яңа эшләр башламый торыгыз, ниятләгәннәрне ай уртасына төгәлләгез.


***Сукояр.*** Уй-гамәлләрегездә тулы ирек тоярсыз. Иң кыю фикерләрне, тормышка ашмастай ниятләрне дә чын итәр вакыт. Уңыш сезнең якта, нәрсәгә генә тотынсагыз да, булдырырсыз.


***Балык.*** Тормышыгызда күңелле вакыйгалар көтелә. Күңелегезне шатландыра торган бүләк алырсыз, бу хәтта мактаулы исем дә булырга мөмкин. Тырыш хезмәтегезнең яхшы нәтиҗәләрен күрер чор якынлаша.

## *Ноябрь дә кабынган йолдызлар*

### *Татарстан*



**Сара Садыйкова** (1.11.1906–7.06.1986) – **татарларның беренче хатын-кыз композиторы, опера җырчысы, драма артисты.**

Казанда туа. Фатиха Аитованың кызлар мәктәбендә укый, аннары педагогика техникумына керә. Укытучысы Солтан Габәши аны Мәскәү консерваториясенә укырга җибәрә (1922–1928). 1934–1938 елларда Мәскәүдә татар опера студиясен тәмамлый, «Эшче» театрында эшли. 1942 елда беренче әсәрен – «Көтәм сине» тангосын яза. 1925 елда беренче татар операсы «Сания» аның сопраносы өчен иҗат ителә. Сара Садыйкова 400 җыр, 30 спектакльгә көй, 2 музыкаль комедия, инструменталь әсәрләр язган композитор. 1939 елда Татарстанның атказанган артисты, 1977 елда халык артисты исемнәренә лаек була. Соңгы әсәрен – «Идел суы ага торыр»ны 1986 елда яза. 1990 елда аңа, вафатыннан соң, Тукай премиясе бирелә.

### *Россия*



**Маргарита Назарова** (26.11.1926–25.10.2005) – **Россиянең халык артисты.**

Царское Селода туа. 1941 елны әсирлеккә эләгеп, Германиягә озатыла. Сугыштан соң Латвиягә кайтып, Даугавпилс театрына эшкә урнаша. 1954 елда дрессировка остасы Константин Константиновскийга кияүгә чыга, 1960 елда уллары Алексей туа (ул да хайваннар өйрәтүче була, гастрольләрнең берсендә Франциядә яшәп кала). Уңыш Назаровага 1961 елда – «Полосатый рейс» фильмыннан соң килә. Константин 50 яшендә яман шештән вафат булгач, ерткычлар Назаровага буйсынмый башлый, фәкать Пурш кушаматлы юлбарыс кына аны үзенең хуҗасы итеп саный. Әмма ул да тиздән үлә. 1983 елгы чыгышы Назарова өчен соңгысы була, аренада аңа юлбарыслар ташлана.

### *Чит илләр*



**Софи Марсо** (17.11.1966) – **киноактриса, режиссер, җырчы.**

Парижда эшче гаиләсендә туа. 1980 елда модельләр агентлыгына эшкә урнаша. «Бум» фильмының кастинг-директоры Франсуаза Вик роленә кандидатура эзләп, шушы агентлыкка мөрәҗәгать иткәч, алар Софины тәкъдим итәләр. Әнә шулай Софиның актерлык карьерасы башлана. Фильм искиткеч уңышлы килеп чыга, тиздән аның дәвамы булган «Бум 2» төшерелә. 16 яшендә үк инде шактый танылган актриса Жерар Депардье һәм Катрин Денев белән «Форт Саган» фильмында уйный. 1985 елда үзенең беренче һәм соңгы альбомын яздыра. Дөнья тамашачысына исә аны «Шальное сердце» фильмы белән режиссер Мел Гибсон таныта.

PRESSA.RU







# АЛТЫН БИЗӘКЛЕ ТАРИХ

Рәссам Юрий ПАВЛОВ – лаклы миниатюралар остасы. Ул алар белән Лениногорск сынлы сәнгать училищесын тәмамлагач ук кызыксынып караса да, нибары 1990 елда гына шушы юнәлешне сайлап алган. «Иң беренче әйберләремне совет чоры шкатулкаларыннан күчереп эшләдем. Менә 25 ел дәвамында лаклы буяу белән генә эшлим. «922 ел. Болгар. Идел буе Болгар дәүләтенең илтабары Алмыш ханның Багдад илчеләрен кабул итүе» дип аталган шкатулкам әзер булугa ук Италиягә китте», – ди Юрий Павлов. Аның әсәрләренең туксан проценты Көнбатыш Европадагы һәм Төньяк Америка илләрендәге шәхси тупланмаларны бизи. Әлеге затлы эшләрнең берсен эшләүгә генә дә җидесигез ай китә. Сурәтләр агачка төшерелми, чөнки агач вакыт үтү белән чатный, яргалана. Ул папье-маше куллана. Катыргыны унбиш тапкыр лак белән каплагач, папье-маше суга салсаң да берни булмас чыдамлыкка, ә берничә мәртәбә шомарткач, гәрәбәдәй ялтыравыклы, үтә күренмәле матурлыкка ия була. Бу – гаять катлаулы кул хезмәте. Уйдагы композиция темпера белән язылып, соңрак алтын белән бизәкләнеп тулыландырыла. Һәм янә берничә кат лак белән каплатыла. Ул бу эшкә уникешәр сәгать вакыт сарыф итә. «Кайбер көннәрне мин үтә нечкә кылкаләм тоткан бармакларымны бер-берсеннән көч-хәл белән аерып алыр халәткә җитәм», – дип аңлата рәссам.


Лаклы миниатюраларның яңа төре барлыкка килүе хакында дәлил булырдай әсәрләре турында ул бик теләп сөйли: «Үземнең һәрбер иҗат эшемне «Казан» сүзе белән тамгалыйм. Минем һәр шкатулкамның диярлек үзгә атамасы бар: «922 елының маенда Илтабар Алмыш – Җәгъфәр ханның Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүе», «Сөембикә ханбикәне һәм аның улы Үтәмешгәрәйне Казаннан озату», «Сабантуй», «Кабан күле риваяте», «Елга буйлап та, Казансу буйлап», «Меңьеллык Казан»...

Шкатулкалардан кала, Юрий Павлов миниатюралы брошь, кулон, йөзек, алкалар кебек зиннәтле ювелир әйберләре, өстәл һәм камин өстенә куелучы сәгатьләр, бәләкәй сандыклар да ясый.

Соңгы вакытта рәссам Г. Тукайга багышланган серия: шагыйрь портретын, тугыз кырлы зур сандык һәм берсеннән-берсе кечкенә биш тартма иҗат итә. Ул – ихлас, эрудит һәм үткән тарихны яхшы белүче шәхес. Мактау сүзләрен Сочидагы I Бөтенроссия халык мәдәнияте фестивалендә дә, Мәскәү күргәзмәләрендә дә чын осталарга хас тыйнаклык белән тыңлый белә. «Насыйп булса, берничә елдан соң Коръән китабы өчен махсус шкатулка ясармын һәм аны кабатланмас бизәкләр белән бизәрмен дип уйлап йөрим».

Юрий Павлов әсәрләренә төсләрне нечкә тоемлау, катлаулы күп фигуралы композицияләрне чишкәндә декоратив элементларны оста файдалану хас. Аларда сынлы сәнгатьнең яктылык эстетикасы бар. Юрий Павлов – сәнгатьнең бу юнәлешен татар мәдәнияте һәм тарихы тематикасы белән баеткан, татарлардагы милли хисне кабул итеп ала алган бердәнбер рус рәссамы!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА









«Гөлчәчәк»

«Казансу буйлап»
«Печән өсте»
«Очрашу»
«Уңыш»
«Таң батыр»

## ЮРИЙ ПАВЛОВ

PRESSA.RU

# Язып һәм телевизор от!




**1 Языл**
**30.12.2016** кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

**2 Җибәр**
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

**3 От**
Телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр!

**БҮЛӘКЛӘР**
**2017 елның 17 февралендә**
**УЙНАТЫЛАЧАК**





Акцияне үткәрү вакыты: 20.10.2016 - 20.03.2017

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84 өстәмә номер - 1261

16+
Реклама